Безнең МИРАС

01
гыйнвар 2016

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

МИРАС №01 / 2016

Узган елның 3 декабрендә «Татарстан һәм Идел-Урал төбәге халыкларының мәдәният һәм тарих мәсьәләләре» дип аталган Бөтенроссия фәнни-гамәли, тарихи-төбәкне өйрәнү конференциясе булды. Татарстан АССРның 95 һәм Татарстан Республикасының 25 еллыгына багышланган әлеге мәртәбәле җыенны ТР Фән һәм мәгариф министрлыгы, Казан педагогия көллияте, ТР ФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты, аның татар-болгар цивилизациясе тарихы бүлеге, Алтын Урда комплекслы тарих-археология экспедициясе, БТК Башкарма комитеты каршындагы төбәкне өйрәнүчеләрнең Бөтентатар җәмгыяте оештырды.

Без тарихта эзлебез...



Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
1(48)
гыйнвар 2016

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

24

8 СУГЫШЧЫ САТЫШ ӘФӘНДЕ. *Фазыл Туйкин*

60 КЫЙССАИ ТАҺИР ИЛӘ ЗӨҺРӘ

ЭЧТӘЛЕК

3 БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

4 *Ф.Әмирхан*

ТАРИХИ МИРАС

6 Болгар. Успение чиркәве. *Н.Шәйдуллина*
8 Сугышчы Сатыш әфәнде. *Ф.Туйкин*
19 Каләмнең кальбе — милләт язмышында! *Л.Гобәйдуллин*
21 Төрек телен гадиләштерү хәрәкәте һәм Гаяз Исхакый. *Ф.Тамир*
24 Тукай — ядкярләрдә. *Р.Исламов, Җ.Миңнуллин*
31 Якты өмет — остазыбыз! *А.Борһанов*

ТАТАР ГАМЕ

36 Ирек Шәрипов: «Татарның көче — дусларында»
41 Туган йорт. *Х.Ибраһим*
48 Гыйлем ияләре илләрне һәм дәверләрне гизә. *А.Гәрәева*

ПЕДАГОГИК МИРАС

52 Гаилә дәресләре. *Ф.Сөләймания*
55 Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре

ХӘТЕР САНДЫГЫ

56 Сүз һәм сурәт. *А.Филиппов*
58 Шәхесләребез: Иркә Сакаева. *А.Дубин, Т.Миңнуллин*

ӘДӘБИ МИРАС

60 Кутадгу билик (Котайткыч белем). *Й.Баласагуни*
64 Кыйссаи Таһир илә Зөһрә
70 «Фатих ага исеменә дә тел тидергән чакларыбыз булгандыр...» *Х.Туфан*
73 Зәгъферән. *Ә.Зарипов*
78 Кайтаваз. Җәлилнекеме соң алар? *А.Сөнкишев*
81 «Элек дәресләрдә уку шигырь әйтү белән башлана иде...»

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

86 Тукай энциклопедиясе. *Ф.Галимуллин*

ӘДИП АВЫЛЫ

88 Нугайбәкләр шәҗәрәсе. *Р.Зарипов*

ТАБИГЫЙ МИРАС

92 Көмеш күзле чишмәләр... *И.Кыямов*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

100 Кояш кына күктә мәңге йөзәр.... *Р.Мөхәммәтша*
103 Очты дөнья читлегеннән... *Һ.Такташ*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

108 Миллият сүзлеге. *А.Тимергалин*
110 РАЯлашмагыз! *Ә.Кәримуллин*

ХӘТЕР САГЫНДА

112 Көзге. *Г.Җәләлева*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 «Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның гыйнвар ае. *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 Көлке куа килә...

119 Мирасворд
120 «Безнең мирас» елъязмасы. *Гыйнвар*

Заказ №О-3695. Тираж — 1500 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 30.12.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда А.Дубин, Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Казан күренеше. Мәрҗани мәчете». 1994. Киндер, майлы буяу. *З.Батраев рәсеме.*

БЕЗНЕҢ МИРАС – ТАТАР ИЛЕ!

Бер фәкыйрь карт үлем түшәгендә ята икән. Соңгы сулышын алыр алдыннан улын янына чакырткан да болай дигән:

— Улым, зинһар, ачуланма. Мирас итеп сиңа берни дә калдыра алмыйм инде. Үзең күреп торасың: бер байлыгым да юк!

Улы әйткән моңа:

— Әти, борчылма, — дигән. — Бар синең байлыгың. Ул — без: улың, оныкларың... Без — синең мирасың! Безгә биргән тәрбияң, үгет-нәсыйхәтләрең, файдалы киңәшләрең, кылган игелекләрең, күршеләргә, башка кешеләргә күрсәткән ярдәмең, җылы, дустанә мөгамәләң — болар мирас түгелмени?! Синнән миңа — улыңа, миннән балаларыма — синең оныкларыңа күчкән туган телебез — үзе олуг бер мирас бит, әти!

Ата кеше, сөекле улының әлеге җавабыннан канәгать калып, күзләрен мәңгегә йомган, ди...

Әйе, дөнья шулай корылган: һәр кешедән, аның кайсы кавемнән булуына, күпме эш-гамәл кылуына карамастан, нинди дә булса мирас кала.

Мирас дигәнең, беләбез ки, күптөрле була: рухи, мәгънәви, әдәби, язма, тарихи, дини, әхлакый, сәнгати, табигый һ.б., һ.б...

Без — мираслы халык. Бу сүзне горурланып, күкрәк кагып, авыз тутырып әйтә алабыз.

Безнекедәй бай тарихлы мирас тагы кайсы халыкта бар икән?!

Язма мирасыбыз төрле кыйтгаларда чәчелеп ята, төрле ил-мәмләкәтләрдәге архивларда никадәр байлыгыбыз халкыбыз хозурына кайтуны көтә. Аларны без, кадерле укучыбыз, бергә эзләмәсәк, барламасак, берәмтекләп-бөртекләп булса да җыйнамасак — бу изге эшне, игелекле гамәлне тагы кем башкарыр?

Безнең мирас — Татар иле. Яклыйк без аны, бергә күз карасыдай саклыйк, дәвамчыларыбызга бөтен килеш тапшырыйк мирасыбызны:

Тарих үзе гасыр ташларына
Һич җуелмас сүзләр уйгандыр:
Безнең мирас — газиз Татар иле,
Безнең мирас — гүзәл туган җир!

Фатих Әмирхан
(1886-1926)

***

Мәктәп, мәктәп вә мәктәп — бу заманыбызның иң әүвәлге вә иң зарур ихтыяҗыдыр.

***

Китаплар, китаплар вә китаплар — бу мөмкин кадәр җитди вә тиешенчә ачылырга кирәк мәсьәләнең икенчеседер.

***

Бер милләтнең теленең җуялуы әдәбиятының җуялуы димәек улып, әдәбиятының җуялуы да рухының бетүе дигән сүздер.

***

Бер халыкның телен, әдәбиятын белмичә, аның рухани тормышына белешләнмичә хезмәт итү, димәк — бик әсассыз (нигезсез) бер сүздер.

***

Ганганәи мәдәнияләре (мәдәни традициясе) нык булган милләтләрдәге гыйбта ителерлек (кызыгырлык, көнләшерлек) бик күп хәлләрдән берсе — алардагы һәр берәм-берәм фәрднең (шәхеснең) үз урынын яхшы тануы вә бөтен милләтнең дә үзенең аерым-аерым фәрдләренең урынын яхшы тәгаен итә белүедер.

*****

Капитал көчсез милләтләрне көчлеләрдән йоттырып интернационал ясамакчы була. Хезмәт исә зәгыйфь вә мазлум милләтләрне алдынгы милләтләр сәвиясенә (дәрәҗәсенә) күтәреп, матди һәм мәгънәви тигез хокуклы, тигез дәрәҗәле милләтләрдән тәрәккеб иткән (оешкан) бер бәни адәм букеты вөҗүдкә китерүне үзенә вазифа итеп куя.

*****

Гыйлем вә фәнсез һичбер адәм гаммәгә (массага, гавамга) эш эшли вә файда китерә алмыйдыр, мәгыйшәтән чыккан иң мөһим мәсьәләләрне хәл итәргә көче җитми гаҗиз каладыр.

*****

Фәкать фән генә кешеләргә үзләренең хәятенең серләрене ача ала, фәкать ул гына дөньяны баета, ислах итә вә сәгадәткә ирештерә аладыр.

*****

Фәкать фән генә яңа вә яхшы мәгыйшәт, яңа вә яхшы кеше ясый ала вә аны җәфалардан коткара аладыр.

*****

Мәгариф кешене бәни адәм файдасына хезмәт итәргә өйрәтә, ләкин бу хезмәттән хаклыча әһле мәгариф үзе файдалана, дияргә мөмкин түгелдер.

*****

Яңа ел! Һәр яңа нәрсә яңа өмидләр биргәнлектән, өмид белән генә дөньяда хәят сөрә торган бәни адәм яңа нәрсәне, яңа халәтне сөяләр, аннан әллә нинди нәрсәләр көтәләр, үзләрен юаталар, бер-берсенә әллә нинди бәхетләр, әллә нинди сәгадәтләр теләшәләр.

Безнең шикелле искелек эчендә күп яшәгән вә ялыккан милләткә бу яңалык, яңа халәтләр бигрәк тансык, безнең көтә торган нәрсәләремез бигрәк тә күп, чөнки башка халыкларда булып беткән вә искергән нәрсәләр дә бездә вөҗүдкә чыкканы юк, фәкать көтелеп кенә торыладыр.

Үткән елымыз, үзеннән әүвәлгеләре шикелле үк, бер дә хәрәкәтсез, яхуд бик аз хәрәкәт, аз файда белән генә үтте, мәгыйшәтемез һаман шул иске эзеннән тәгәрәп, хәлләремезнең бик күбесе шул әүвәлге килешләрендә үк дәвам иттеләр: шул ук фәкыйрьлек, шул ук наданлык, шул хокуксызлык! <…>

Менә шуның өчен дә, ягъни безнең иске нәрсәләремез бик күпкә күрә дә, безгә яңа халәтләр бик кадерле, шуңар да безгә киләчәктә көтә торган нәрсәләр бик күп. Безгә яңа ел яңа гайрәт бирергә тиеш, без дә, ул яңа гайрәт белән, искергән заманымызда гасырлары күптән узган нәрсәләрне аударып, урыннарына яңаларын вөҗүдкә китерергә тиештер.

Без әле һәрнәрсәгә мохтаҗ, безгә әле бик аз куәт вә мәшәкать белән вөҗүдкә китерелә торган нәрсәләр дә бик кадерле! <…>

Шуңар күрә безнең яңа елда лозунгымыз: «никадәр вак булса да — эш; сүз белән генә ерак китеп булмый икән» булырга тиештер. <…>

Шуңар күрә әгәр бу эш вөҗүдкә чыга калса, безгә яңа елдан бик күп яңа вә якты нәрсәләр өмид итәргә мөмкин булачактыр. ■

БОЛГАР. УСПЕНИЕ ЧИРКӘВЕ

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

1732-1734 елларда төзелгән Успение чиркәве — биредә булган шул исемдәге монастырь корылмаларыннан сакланып калган бердәнбер гыйбадәт бинасы. Храм — Казан сәүдәгәре Иван Афанасьевич Михляев акчасына, чиркәү манарасы дин тотучылар акчасына төзелгән. 1841 елда чиркәү манарсы сүтеп алынган һәм 1862 елда бүгенге манара төзелгән. Чиркәүне төзегәндә аның нигезенә Болгар ядкярләре хәрабәләреннән алынган кабер ташлары салынган. Алар өстендәге гарәп һәм әрмән язмалары зур фәнни кыйммәткә ия.

Провинциаль барокко стилендәге чиркәү XYII-XYIII гасырларда киң таралган «дүртлек өстендә сигезлек» тибына карый. Храмның төп өлешләре — ярымтүгәрәк абсидалы (архитектура формасының бер төре — бинаның ярымтүгәрәк рәвешендә чыгып торган өлеше) төп күләме, трапезная һәм чиркәү манарасы — бер күчәрдә, «кораб» рәвешендә урнашкан. Успение чиркәвендәге куб формасына охшаш зур төп күләмнең һәм дүртлекнең пропорцияләре гади, алар Урта Азия корылмаларын хәтерләтә. Бизәлеше тыйнак. Архитектура бизәлешенең төп элементлары — кәрниз һәм тәрәзәләрнең ярымбаганалы, сынык фигуралы сандриклы кысалары. Төзүчеләр элеккеге корылмаларның — мәчет белән манара һәм төрбәләрнең композициясен күздә тотып, сәнгати бердәмлек принцибында эш иткәннәр.

1965, 1977, 1982-83 елларда чиркәүгә реставрация ясалган. 2010-2011 елларда фундаменты ныгытылды, идән яңабаштан, таштан түшәлде, түбә яңадан ябылды, тәрәзә блоклары, җылыту системасы алмаштырылды. Янгыннан саклау сигналы системасы, видеокүзәтү җайланмалары куелды. Биредә «Болгар авылы һәм Спас өязе тарихы» экспозициясен оештыру буенча эш алып барыла.

БОЛГАР ТАШЛАРЫНА

Наис Гамбәр
(1946-2005)

XYIII йөздә Болгар кабер ташлары
Успение чиркәве нигезенә салына.
Газетадан

Хак Тәгаләм!
Хак сүз!
Тел иңдер дә Болгар ташларына,—
Баш орыйм бер кабер ташларына, —
Тыңлап торыйм... Юкса ничә еллар
Сүз табалмыйм сөйли башларыма.

Чал тарихның тимер капкаларын
Ач та (ташлап нахак япмаларын!) —
Ташка сүз бир... Хак тәгаләм, бер сүз —
Соңгы сүзен үксеп ятканнарның.
Сөйләсеннәр яуда җиңелгәннәр,
Болгар туфрагына күмелгәннәр;
Җимергәннәр генә теллемени,
Хаклымыни «аксак тимерләннәр»?!

Юкса, Иблис-кәлтә һаман алдый,
Коерыгын өзеп ялгый-ялгый;
Ялгыша ул: «Имеш, тарих — тузан,
Ташлар — үле, ташлар сөйли алмый».
Ләкин...
Килә дә көн, актарыла сулар,
Өскә калка Бөек Болгар, Суар;
Тирәннәрдән калка язулы таш —
Тамгалы таш...
(Дөнья шундый чуар!)

Язулы таш — Болгар илчеседер,
Алласыдыр Болгар ташларының;
Һәм ул хәтерлидер кара көнен —
Гарасатның ничек башлануын.

Безгә килеп җиткән бу догадыр,
Ташка суеп язылган бу сүзләр;
Ташлар елый белми...
(Нык булырга кирәк!
Таштай нык булырга!!!)
Яшьле күзләр...

Кеше гомере Җирдә мизгел генә,
Халык гомере дә акмый тигез генә, —
Ташка күчә дә җан,
Сөйли үз телендә,
Салсалар да чиркү нигезенә! ■

ЯЗУЧЫДАН БЕР-ИКЕ СҮЗ

Бер милләтнең тарихы никадәр киң һәм ачык булса, ул милләтнең тәрәккыйсенә шулкадәр хезмәт итүе күз алдыбызда күренеп торганлыктан, мин аннан бәхәс итәргә тиешсенмәсәм дә, милли тарихыбызның караңгы бер хәлдә буларак әһәмиятсез ташланып калуына тәәссеф итүемне аз гына булса да язып китәргә телим.

Көррәи әрызда түгел, безнең кеби бөек милләтләрнең, хәтта бик вакларына кадәр, милли тарихлары никадәр ачык һәм никадәр парлак булуы өстенә, халыкның фикеренә һәм тәрәккыйсенә хезмәт итү касд илә бөек мөхәррирләре тарафыннан язылган тарихи романнары һәм тарихи театр рисаләләре белән матбугатлары тулмыштыр.

Без бичаралар исә милли тарихыбыздан шулкадәр ерак бер мәсафәдә торамыз, гүя аннан һич хәбәребез юк кеби, аны белергә дә теләмибез; бәгъзе мөхәрриребез тарафыннан язылган бер-ике кечкенә тарихи рисаләбездән башка матбугатыбызда һичнәрсәбез юклыгы моңар бик ачык бер дәлилдер.

Мин исә шул юлда аз гына булса да хезмәт итү касды илә шушы кечкенә генә рисаләмне мәйданга куярга җөрьәт иттем. Тасвиры килешсез булса да, яшь мөхәррирләребезгә үрнәк буларак алар тарафыннан тәэсирле рәвештә язылачак тарихи романларыбызга бер мөкаддимә кабиленнән язылган шул рисаләчегемне мәйданга куюым өчен укучылардан гафу итүләрен үтенәм.

Фазыл Туйкин

СУГЫШЧЫ САТЫШ ӘФӘНДЕ

Фазыл Туйкин

I

Бетмәс-төкәнмәс һөҗүмнәр сәбәпле Болгар дәүләтенең шәүкәте шактый гына кими башлаганлыктан, Болгар халкында әллә нинди бер өметсезлек сизелә башлаган иде. Гүя аларны алларында әллә нинди куркыныч бер фәлакәт көткән шикелле, һәркем эчпошыргыч күңелсез бер хәлгә төшкәннәр, һичбер нәрсәгә күңелләрен утырта алмыйча, үлемгә әзерләнгән кеше төсле һәрнәрсәгә өметсезлек күзе белән карап, рухлары сүнгән, гайрәтләре дә яхшы ук сүрелгән иде. Халыкның инкыйразга әзерләнгән төсле бу ямансу кыйланышларыннан Дәүләт авылы да тәэсирсез калмаганлыгы бик ачык күренә иде. Дәүләт халкы да күңелләрендә бертөрле курку заһир булганлыкны сизенәләр, «ай, заманалар әллә ничегрәк» диеп, халыкның күңеле тынычсызланганлыктан, шикләнүләрен үзара аптырашып сөйләшәләр; тора торгач, сугышчы Кармыш агайның йортына җыелып, замананың барышы бозылудан зарланалар, яшь вакытларындагы тынычлыкларын сагынып куялар, Кармыш агайны да төрле сөальләр биреп йөдәтеп бетерәләр иде. Кармыш агай, беркадәр сугышларда булып, сугышчы Кармыш абзый исемен күтәргән, сугыш вакытында күргән мәшәкатьләрен, анда

Aidarov. 1998.

йөргәндә җыйган мәгълүматларын, башлыкларына иткән хезмәтләрен, алардан ишеткән рәхмәтләрен сөйләп, халыкка төрле гакыллар биреп, белекле һәм булдыклы исемен дә алып, авылларында игътибарлы санала торган бер карт булганга, аңардан төрле вакыйгалар хакында сорашалар, аңарга киңәшләр, аның сөйләгән сүзләренә төрле мәгънәләр биреп, үзара даулашалар, шулай итеп күңел ачарга, хәсрәт таратырга юллар эзләп карыйлар иде.

Кармыш агай исә, бер дә каушамаган рәвештә, һичбер нәрсә булачак түгел кебек итеп сөйли, хәзер генә һөҗүмнәр, сугышлар булу ихтималы юклыгын да үзенчә төрле дәлилләр белән күрсәтә, халыкның болай күңеле төшеп йөрүләрен яратмый, кулыннан килгән кадәр аларны юатырга тырыша иде. «Сугыш булса да борчылырга кирәк түгел, без инде дошман җиңә алудан үткән, менә фәлән сугышта да без җиңдек, ул сугыш нинди куркыныч иде, анда да ирек бирмәдек, аның өстенә никадәр малларын алдык», — диеп мактанып та куя иде.

Кармыш агайның бу сүзләре, төрле куркыныч хәбәрләр белән күңелләре төшеп беткән халыкка бик зур юаныч бирә алмаса да, үзенең егерме биш яшьлек улы Сатыш әфәндегә ялкын кебек тәэсир итә иде.

Аның атасы кебек гаюр сугышчы буласы килә һәм, атасы шикелле үк, башлыклар тарафыннан рәхмәтләр ишетеп, бүләкләр аласы килә, замандашларына да тегеләй йөрдек, болай сугыштык дип, төрлечә мактанып, гайрәтле сугышчы Сатыш исемен ишетәсе килә иде. Сатыш әфәнденең шундый тәмле хыяллар белән башы катып беткәнгәме, әллә яшьлек сәбәпле, халыкның тынычсызлыгыннан хәбәре аз булгангамы, ул башкалар кебек рухсызланмаган, алар төсле үк күңелсезләнмәгән иде. Бәлки: «Әй, берәр сугыш булса, атам белән бергә мин дә барыр идем дә, дошманнарны җиңеп кайтыр идек», — дип тели һәм шуңар әзерләнә иде. Ул һәркөн диярлек аштан соң, болгар сугышчылары кебек кыскача ак чикмәнен киеп, билен бәйли, башына да җылы эчле тирән бүреген кия, аягына күн итек киеп, кылыч, сөңге кеби коралларын ала, үзенең ярата торган кечкенә генә гәүдәле йөгерек кара атын иярләп атлана. Әлхасыйль, читтән караганда тәмам бер болгар сугышчысы рәвешенә кереп, Дәүләт авылының болыннарына чыга иде. Анда аты белән чабып, төрлечә кыйланып, сугышчы сыйфаты белән йөри, кичке аш вакыты җиткәч кенә, йортларына кайта иде.

Сатыш әфәнденең анасы Әрнәби карчык, Кармыш картның сугышларда йөргән вакытларында ачык кайгылы хәсрәтләр чигеп утырудан артык туйганга күрә, улының болай юк хыялларга керешеп йөрүенә җаны ачып, аны төрлечә үгетләп, куркытып караса да, Сатыш әфәнденең сугышчы булу хыялы белән тулган башында анасының әрнешеп сөйләгән сүзләренә урын калмаган кеби, улының сугышчы булу дәрте белән рухланганына куанып, аны төрлечә өйрәтеп ләззәтләнә торган Кармыш карт тарафыннан да Әрнәби карчыкның аһлары игътибарга алынмый иде.

Киләчәкне күңел сизә, дигән шикелле, болгар халкының да бу тынычсызланганлыклары бушка чыкмады, һич көтелмәгән бер тарафтан Болгар дәүләтенә катыкаты һөҗүмнәр башланды. Шәһәрләр, авыллар әллә нинди куркыныч хәбәрләр белән тулды. Халык та нишләргә белми аптырап кайнаша башладылар. Ул арада сугышчылар бик тизлек белән Болгар шәһәренә җыелырга башлыклар тарафыннан әмерләр дә тараттылар. Сугышчылар җыелып Болгар шәһәренә китә башладылар, авыллар кызганыч бер хәлгә керде, хатыннарның аһ-ваһлары, балаларның чыр-чу килеп кычкырышулары, еглашулары, сугышчыларның Алладан ялварып ярдәм сораган тавышлары белән кушылып, һәркемнең күңелен селкетә башлады. Кармыш агай да никадәр гаюр кебек күренсә дә, карт башы белән сугышта чигәчәк куркынычлы мәшәкатьләрне уйлап тынычсызлана, артык тирән уйларга чумып, салкын гына әзерләнә иде. Сатыш әфәнде исә бөтенләй башка бер хәлдә иде. Бу

куркынычлы вакыйгалар аңарга гүя бер бәйрәм кеби күренеп, шатланган һәм бөтенләй башка бер дәрт берлән дәртләнгән иде. Анасының сүзләренә никадәр илтифат итмәсә дә, аның мондый вакытларда кызганыч бер сурәткә кереп еглавын күрергә теләмәвеннән, Болгарга җыелырга әмер таратылгач та, тавышсыз-тынсыз гына гадәтенчә киенеп, анасыннан яшеренеп, төн урталарында атына атланып, әллә кайчан Болгар шәһәренә чапкан иде.

II

Түбәләре калын урманнар берлән капланган биек-биек таулар арасына корылган Так шәһәренең караңгылыгына туймаган шикелле, аның гаять биек таш коймалар белән уралганлыгы дөньяның якты йөзен күрүдән мәхрүм булган бәдбәхетләр өчен әзерләнгән бер урын икәнлеген күрсәтеп тора иде. Шулай ук аның эчендә дә азмы-күпме һәрвакыт шундый кызганыч хәлле адәмнәр буларак шунда бикләнеп, газиз гомерләрен үткәргәнлекләре, кайвакытта шәһәр тышына чыгарылсалар да, иркен һава сулап, киң дөньяның рәхәтеннән ләззәт алу өчен булмыйча, таулар арасына барып, каты эшләр белән хафаланып керү өчен генә чыгарылганлыклары шәһәрнең, төнгә каршы, капкасыннан кулларына көрәкләр күтәреп чыккан ике кешенең хәлләреннән билгеле иде. Ул бичаралар кылычлар, озын сөңгеләр тоткан каравылчылар белән каршыларындагы биек тауларга таба юнәлделәр. Бу адәмнәрнең берсе утыз биш яшьләр чамасында гына булса да, иптәше чәч-сакаллары агарып беткән карт булып, ничә еллардан бирле авыр эшләр белән изелеп, ватылып беткәнлекләре кыяфәтләреннән, йөрешләреннән билгеле иде. Бичараларның ачы кайгылар, каты хәсрәтләр белән янып беткәнлекләре каралып кипкән йөзләреннән, моңлы күз карашларыннан, билгеле, һәркемне кызгандырырлык сурәттә күренеп тора иде. Ачык һава вөҗүдләренә беркадәр куәт биргән булса кирәк, тиз генә атлап, калын урманнарның каршындагы тауга барып туктадылар. Бераз гына утырып ял иткәч, акрын гына атлап менә башладылар. Тауның текәлеге менәргә уңайсызласа да, туктый-туктый, көч-хәл белән менә торгач, тауның өч өлештән ике өлешен менеп беттеләр дә каравылчыларның әмере белән шул урында туктап эшкә керештеләр. Эшләре исә зур-зур ташларның тирә-ягын тазартып, ничек кирәк алай кузгатып, түбәнгә таба тәгәрәтүдән гыйбарәт иде. Алар, шулай мең төрле мәшәкать белән берничә ташларны төшергәч, эштән тукталып, каравылчылар тарафыннан бирелгән икмәкне ашарга утырдылар. Шул арада яшьрәге гаять моңлы көй белән ватанын сагынып, шул җырны җырларга башлады:

Сагынам, түзә алмыйм, туган илне,
Әллә кай төшләре ямьле иде.
Илебез, син икәнсең кадерле җиребез.
Яшел болыннардан шаулап аккан
Сулары да татлы, тәмле иде.
Илебез, син икәнсең кадерле җиребез.
Урманнары матур әллә нинди,
Кошлар килеп анда сайрый иде.
Илебез, син икәнсең кадерле җиребез.
Яланнарга чыгып йөргән чакта
Таныш иде кырның бар җире.
Илебез, син икәнсең кадерле җиребез.
Кайтасым да килә туган илгә,
Йөрәккәем шунда ашкына.

Илебез, син икәнсең кадерле җиребез.
Башларымны алып ничек китим,
Кая карасам да, гел таш койма.
Илебез, син икәнсең кадерле җиребез.

Аның хәсрәт ялкыннары белән янган, ачы кайгылары белән капланган күңелендәге кайнар сулышларына төрелеп чыккан моңлы «Зали көе» әллә кемнәрнең йөрәкләрен селкетерлек, тыңлаучыларның да иң нечкә тамырларына кадәр йөгереп, бөтен вөҗүдләрен калтыратырлык иде. Каты күңелле каравылчылар да моның җырын тыңлап, моңлылыгыннан хәйран булып, урыннарында катып торалар иде. Аның моңлы болгар көе белән гаять ләззәтле болгар җырын җырлавы, саф бер болгар кешесе булып, сугышларда әсир ителепме яисә башка берәр сәбәп беләнме, ничек булса да бер бәхетсезлеккә каршы ят кешеләр кулына төшкәнлеген аңлата иде. Ул беркадәр җырлагач «аһ» итеп сулады да: «Әй, бабай, сагынам ла, туган-үскән илебезгә кайтып, кардәшләремне күрергә Ходай язган микән?» — диде.

Карт иптәше дә, авызына капкан икмәкне көчкә генә чәйнәштереп йоткач:

— Минем хәлем зәгыйфьләнеп, артык куәтем юклыктан, ул кадәр еракта калган илебезгә кайта алуыма ышана алмыйм; әгәр синең урыныңда булсам, кайтыр идем, — диде.

— Ничек кайтыр идең? Кайтыр идең дә шул, җибәрмиләр.

— Алардан кем сорап тора, синең кебек яшь вакытым булсамы, әллә нинди хәйләләр корыр идем дә бик шомалап кына качар идем. Бер иреккә чыккач, Ходай юл бирер иде әле, — диде дә, — картайдым шул, картайдым. Миңа үземнең туган-үскән илемне күрү насыйп түгелдер инде, — дип бичара карт елап та җибәрде. Бу вакытта яшь иптәше, башын түбән салып, бик тирән уйга чумган иде. Чөнки аның уена келт итеп качу фикере төшкәнлектән, аның башына әллә нинди хыяллар тулган иде. (Менә ул җай табып качып китә, аны күрәләр дә куа башлыйлар, аны тоталар да кыйный-кыйный тагын шул таш коймалар эченә кертеп биклиләр. Ул, йөри торгач, тагын бер уңайлы вакыт табып кача, аны һичкем күрми, ул үзенең матур да, ямьле дә күренә торган иленә кайта, туганнары, кардәшләре аны каршы алалар. Ул алар берлән кочаклашып күрешә, аның янына күп кешеләр җыелалар, аңардан әлләниләр сорашалар, ул барын да ярата, барының да сораганына бер дә читенсенмичә генә җавап бирә.) Ул, шундый очсыз-кырыйсыз хыяллар белән бөтенләй үзенең кайда икәнлеген онытып, тагын әллә никадәр утырган булыр иде, ләкин каравылчыларның: «Эшкә керешегез!» — дигән тавышлары аны, татлы хыялыннан аерып, эшкә керешергә мәҗбүр итте. Алар тагын эшкә тотындылар, беркадәр вакытлар зур бер ташның тирә-якларын казып, түбәнгә таба тәгәрәтергә тырышканда таш кинәт кузгалып, тәгәрәп китүе белән кара бәхетле картны да эләктереп китте. Бичара карт ташның бәреп җибәрүе белән әллә кая кадәр чәчрәп барып төште дә таш артыннан түбәнгә таба тәгәри башлады. Аның «Алла, Алла!» диеп кычкырган тавышыннан исән икәнлеге беленсә дә, тауның текәлеге аны түбәнгә кадәр тәгәрәтәчәк булуыннан исән калу ихтималы беткән иде. Каравылчылар да, бу хәлне күреп, картка таба атылдылар. Алар, артларына карамастан, картны коткару өчен тырышып төшсәләр дә, ул бик тиз тәгәрәгәнлектән, аны тота алмыйча, түбәнгә кадәр аның артыннан төштеләр. Мондый көтелмәгән куркынычлы вакыйгадан бөтенләй аптырап катып калган картның иптәше исә, каравылчыларның аны коткару касды белән тәмам түбәнгә кадәр төшеп киткәнлекләрен күргәч, аларның тиз генә менеп җитә алмауларын төшенде дә, башына гакылын җыеп, тиз-тиз тау башына таба

омтылды һәм шунда ук бар куәте белән тау өстендәге очсыз-кырыйсыз калын урманга кереп йөгерде.

Бу качучы адәм исә югарыда сөйләгән Сатыш әфәнде иде. Укучыларның хәтерендә булса кирәк, ул башлыклардан Болгарга җыелырга әмер таратылгач та, тавышсыз-тынсыз гына киенеп, анасыннан яшеренеп, төн урталарында атын атланып, Болгар шәһәренә чапкан иде. Төн дә бик караңгы булу өстенә, аның юлы күбесенчә урман эчләреннән барырга булганлыктан, ул, күңеленең кызулыгы белән чаба торгач, әллә нинди сукмакларга кереп адашты. Төн буенча арлы-бирле чабып йөрсә дә, караңгы урман эчендә билгеле бер юл да таба алмыйча аптырап калды. Бары таң беленеп көн яктыра башлагач кына, кая булса да барып чыгармын диеп, бер тарафка карап китсә дә, бәхетсезлегенә каршы, Болгарга һөҗүмгә килеп, Волга суы буена урнашкан куәтле дошман гаскәренең өстенә килеп чыкты. Ул тиз генә борылып аннан качарга теләсә дә, аны атлы дошманнары бик тиз әйләндереп, урап алдылар. Сатыш әфәнде, мондый бәхетсезлеккә төшүенә аптырап, шашып калып, җан ачуы белән аларның өстенә һөҗүм кылып, берничәсен яралап ташласа да, аны дошманнары, тизлек белән тотып алып, аягын-кулын бәйләп, әсирләр ябар өчен әзерләнеп куелган махсус урынга озаттылар. Бу вакытта Сатыш әфәнденең дәрте сүрелгән, күңеле төшеп, башын кайгы чолгап алган иде. Ул хәзер үзенең нинди хәлгә төшкәнен уйлады да анасы Әрнәби карчыкның әйткән сүзләренә төрле мәгънәләр биреп, аның сүзләрен тасдыйк итәрәк, күзләреннән берничә тамчы гына булса да яшьләре тәгәрәп төште.

Берничә көннәрдән соң Сатыш әфәнде янына тагын беркадәр әсирләр китереп яптылар. Сатыш әфәнде алар белән туйганчы сөйләшә дә алмый калды. Боларның барысын да, кулларын бәйләп, куәтле каравыл белән артка таба озаттылар. Юлда вакытта бер-берсе белән сөйләштермичә, катыштырмыйча аерым-аерым каравыллап, берничә көннәр алып киткәннән соң, югарыда сөйләнгән таш коймалар белән уралган караңгы Так шәһәренә илтеп керттеләр. Ул бичаралар юлда ачлыктан, юксызлыктан җәфаланып, хәлдән таеп шәһәргә килеп кергәндә тәмам эштән чыгып ялыксалар да, аларга ял итәргә вакыт бирмичә, икешәр-өчәр таратып, төрле эшләргә куштылар. Аларның, якты ватаннарыннан аерылып, ачы кайгылар йотып коллыкта яшәүләре ничә елларга кадәр сузылса да, бичаралар «бүген азат итәрләр, иртәгә коткарып җибәрерләр» диеп, киләчәкләреннән өметләрен өзмичә, шунда картаялар иде. Алар күбесенчә ялгыз-ялгыз торганлыктан, бер-берсе белән дә бик аз сөйләшергә туры килә, бары шәһәр тышына чыгып эшләгәндә генә икәү-өчәү бергә туры килеп сөйләшәләр, зарланышалар иде.

Үзләрен коллыктан коткарып җибәрерләр, диеп өмет итеп йөргәнгәме, әллә каравыл бик каты булганлыктан, андый эш мөмкин булмагангамы, араларыннан качарга да уйлаучы юк кебек иде. Барыннан да бигрәк ул фикер Сатыш әфәнденең башына килгәне юк иде. Бары бервакыт шәһәр тышына эшкә чыкканда гына карт иптәше тарафыннан ул фикер аның башына салынган иде һәм, шул картның таудан тәгәрәп төшеп үлүеннән файдаланып, урманга кереп качканлыгы укучыларга мәгълүмдер. Дөресе дә ул шулай, урманга кереп йөгерде.

III

Хәтфә шикелле яшел үләннәр белән капланып, әллә нинди аллы-гөлле чәчәкләр белән чуарланган гаять матур төз болынның бер тарафы куе яшел яфракларга бөркәлгән зур калын әрәмә булып, икенче тарафыннан киң Волга суы үтә иде; әрәмәдәге сандугачларның өзеп-өзеп сайраулары, андагы кошларның әллә нинди гүзәл тавышлар чыгарып әрәмәне яңгыратулары, һавадан тезелеп-тезелеп килә торган аккошларның, Волга суына төшеп, моңлы тавышлар белән куанышулары

бу болынга шулкадәр гүзәллек, шулкадәр матурлык бирә иде. Әгәр Волга ярындагы балыкчы болгар картының ташлардан, агачлардан кормаштырып ясаган куышы, ярга чыгарылып каплаган зур-зур иске көймәләре, киптерергә элгән балык аулары булмаса иде, бу болынны күргән кеше, һичшиксез, «җәннәт шушы икән», дияр иде. Ләкин балыкчы карт күргән кеше хәйран булып, үзенең кая икәнен онытып торырлык гүзәл болынга күтәрелеп тә карамый иде.

Ул үзенең куышы янына ике казык каккан да шуңар аркылы агач белән бер чиләк элеп, астына дөрләтеп ут яккан, үзе, ут янына утырып, кулындагы пычагы белән нәрсәдер кискәләп, бер болгар көе сызгырып утыра иде. Шулвакытта әрәмә арасыннан, бик яхшы атка менеп, кулына кылыч тоткан тулы гына гәүдәле бер сунарчы килеп чыкты да күзенә чалынгач та туп-туры балыкчы карт янына китте. Балыкчы карт баштарак бу адәмне күрмәгән иде. Янына килеп туктагач кына күрде дә кинәт кенә янында ат менгән бер кеше булуыннан сискәнеп, сикереп торды. Мәзкүр кеше нычкыл гына тавыш белән:

— Нихәл, бабай, исәнме? Изге тереклек, — диде.

Карт:

— Син кем? Кайдан килдең? Миндә ни йомышың бар?

— Бабай, мин монда адашып килеп чыктым. Болгар шәһәренә бара идем.

Карт гаҗәпсенеп:

— Болгар шәһәренә бара идем?! Анда ник барасың?

— Менә, шәһәргә ник баралар, димени! Шәһәр күрергә барам!

— Егет, син минем белән уйнап сөйләшмә. Миндә йомышың булса, атыңнан төш, кил, утыр, менә хәзер ашым пешә, кунагым бул. Әгәр йомышың булмаса, мине шаяртма, бар, юлыңны кара. Ходай сиңа ак юл бирсен. Мин инде алтмышка җиткән карт, уйный торган чагым артта калган.

— Юк, бабай, уйнамыйм, ачуланма әле. Зинһар, миңа юл гына күрсәтеп җибәр әле.

— Уйнамасаң, әллә кайчан көле күккә очып югалып беткән Болгар шәһәренә кирәк нәрсәләр алырга барам, диеп, юл сорашкан булып тормас идең.

Мәзкүр кеше бик аптыраган кыяфәттә калтыраган тавыш белән:

— Сөбханалла, нинди көле күккә очкан? Ни эшләп югалган? Кайчан шулай булган?

— Егет, син, ахры, бик ерактан килгән ят ил кешеседерсең. Йә мине мыскыл итә торгандырсың. Югыйсә, ул кыямәт шикелле сугышта Болгарның ватылып, яндырылып, харап булып беткәнен бу тирәдә ишетмәгән бала да калмагандыр инде. Син генә ишетми калмас идең.

— Юк, бабай, һич ишетмәдем. Дөрес, бик ерактан киләм килүен, синең сүзләреңә ышанырга да белмим, ышанмаска да.

— Ышанмасаң, атыңнан төш тә аны ашарга җибәр. Менә хәзер ашым өлгерә. Ашагач та мин сине көймә белән Болгар юлына кадәр илтермен, аннан соң, берәр тәүлек барсаң, гөрләп тора торган Болгарның ни эшләгәнен күрерсең дә ышанырсың, — дип чәй кайнатырга коры-сары чыбыклар җыеп килер өчен әрәмәгә таба китте. Мәзкүр сунарчы да, тәмам хәйран булып, аптырап калган кайгылы бер кыяфәт белән, атыннан төште. Атына, аркасыннан сыпырып, ашарга кушты да үзе Волга суының ярына төшеп юынырга башлады.

Мөхтәрәм укучылар! Бәлки, бу сунарчының кем икәнен белергә тели торгандырсыз. Бу сунарчы исә безнең әсирлектән качкан Сатыш әфәнде иде. Ул качканның соңында, байтак нәрсәләр күреп, ничә көннәр урман араларында качып йөри торгач кына шушы балыкчы карт янына килеп чыккан иде.

Сатыш әфәнденең, тауга эшкә баргач, иптәш картның очраган фәлакәтеннән

файдаланып, урманга кереп качканлыгын укучылар онытмаганнардыр. Ул, бичара, тотылудан куркып, тәмам хәлдән таеп егылганчы бер тарафка карап, куе агачлар арасыннан йөгерде. Көн дә караңгыланып килә иде. Хәле беткәч, азрак ял итү касды белән утырса да, артык тәкате беткәнлектән, үзен-үзе тота алмыйча йоклап китте. Ул йокысыннан сискәнеп торган чакта, кояш, тәмам югары күтәрелеп, агачлар өстенә карап тора иде.

Сатыш әфәнде артык ачыкканлыктан хәлсез иде. Янында ашарлык бер кисәк нәрсәсе дә булмаганга хафаланып китсә дә, үзенең куркынычлы әсирлектән котыла алуына куанып, үзен-үзе юатты. Як-ягына каранып, беркадәр тыңланып торды да урмандагы кош тавышларыннан башка бертөрле дә тавыш ишетмәгәч, тынычланып, агач арасыннан төрле үләннәрне алып, чәйнәп карый башлады. Эзләнә торгач, бер үләнне яратып, шуны җыеп ашагач азрак хәл кергән төсле булып, саклана-саклана гына тагын алга таба йөгерде. Кич булып, төн караңгылана башлагач, Сатыш әфәнде, арганлыгын сизеп, беркадәр ял итмәкче булды. Ул хәзер артыннан килеп таба алмауларына яхшы ук ышанган иде.

Алай да бик озак утырырга куркып, тагын акрын гына кузгалып китте. Ләкин, төн караңгылыгында әллә нинди ерткыч хайваннар өстенә барып чыгуыннан куркып, бер агач башына менеп йоклады.

Таң беленгән вакытларда аны бер карга кычкырып уяткан иде. Ул тыңланып кына агач башыннан төште дә, кичәге үләннәрне җыеп ашаштыргач, тагын алга таба китте. Ул, байтак вакытлар баргач, бер ят тавыш ишеткән кебек булып сискәнеп китте һәм туктап, тирә-якларын бик текәлеп карый-карый тыңлана башлады. Менә ерак та түгел алдында бер яктан кара нәрсә күренде. Сатыш әфәнде, байтак вакыт күзен алмыйча аңар карап торса да, ул нәрсә һич кыймылдамагач, акрын гына атлап, аңар якынрак килде һәм аның йөзләре умырылып, канга батып үлгән бер кеше икәнлеген таныды. Ул үлгәннең өстендә шул заманның сунарчылары кия торган махсус хайван тиресеннән ясалган кием булуы аның бер сунарчы икәнчелеген ачык күрсәтә иде. Сатыш әфәнде бу сунарчының гаять вәхши сурәттә яралануыннан, кулына канлы хайван йоннары ябышып калганлыктан, бу адәмнең нинди дә булса берәр ерткыч хайван тарафыннан үтерелгәнен аңлап, андый һәлакәтнең үз башына килүен уйлап, куркып тора иде. Үлгәннең янында ерак та түгел урталай сынган бер сөңге сабы белән бик яхшы бер кылыч күренде. Сатыш әфәнде бик тиз генә кылычны барып алды да, үзенең уйламастан мондый коралга малик булуына куанып, тагын алга атлаган гына иде, баягы куркынычлы тавыш тагын ишетелде. Сатыш әфәнде, куркынып, беркадәр тыңлап торгач, ачыргаланып кычкырган бер адәм тавышы икәнен аңлады. Аның да берәр ерткыч хайван һөҗүме астында калган сунарчы булуына хөкем итеп, тавыш килгән тарафка атылды. Тавышка якынлашкач, ни күзе белән күрсен, сунарчы киемендәге бер адәм гаять зур бер аю тарафыннан кочакланган. Бичара бар куәте белән котылырга тырышса да, аюның тырнагыннан һич котылырга мөмкин түгел, аю тәмам бәхетсез сунарчыны үтерергә әзерләнгән. Бу хәлне күреп, Сатыш әфәнде, бар куәте белән аюга кылыч күтәреп, аюга һөҗүм итүе белән, залим аю урталай бөкләнеп җиргә егылды. Үлем тырнагыннан котылган сунарчының, җәрәхәтләнгән җире булмаса да, куркуыннан бер сүз әйтергә дә хәле калмаган иде. Алай да куанычыннан Сатыш әфәндене кочаклап алды.

Сатыш әфәнде, бер кешене үлемнән коткаруына сөенеп, Аллага шөкер итте. Сунарчы, беркадәр хәл алгач, Сатыш әфәндегә карап байтак сүз сөйләде. Сатыш әфәнде, аның сүзләрен бөтенләй үк аңлап бетермәсә дә, үзен үлемнән коткарганлыгына рәхмәт укыганлыгын аңлады. Чөнки аның теле болгар теленә бөтенләй башка бер тел булса да, Сатыш әфәнде ун ел әсир булып торган заманында

аларның телен беркадәр өйрәнгән иде. Сунарчы, тагын сүзгә керешеп, икәү сунарга чыкканлыгын, бәхетсезлекләренә каршы, аю очрап, иптәшен үтергәнлеген, үзенең дә, качарга өлгерә алмыйча, аю кулына төшеп, Сатыш әфәнде коткармаса, әрнешеп үләчәген сөйләп, аның зур хезмәтенә каршы ни эшләргә белми аптырап калып, әгәр кабул итсә, йортына алып кайтып, кунак итеп, теләгән нәрсәсен биреп озатачагын аңлатты да Сатыш әфәнденең үзенең нинди кеше икәнлеген сөйләвен үтенде. Сатыш әфәнде, үзенең кем икәнен тәмам сөйләргә шикләнсә дә, бер болгар кешесе булып, анда кайтырга чыкканлыгын һәм туры юл белмәгәнлегеннән шулай юлсыз барганлыгын аңлатты. Ләкин, сунарчы йортына кайтса, яңадан кулга төшү ихтималын уйлап, аның йортына барырга күнмәячәген белгертте.

Сунарчы исә, аның үзе белән кайтмавын аңлагач, Сатыш әфәндегә Болгарга барырга туры һәм тыныч юл күрсәтмәкче булып, үлгән иптәше янына алып килде. Анда беркадәр уйланганнан соң, үзенең яхшы сунар киемнәрен Сатыш әфәндегә кияргә кушып, өстеннән салып бирде дә, үзе күзләреннән яшь аккан хәлдә, иптәшенең канлы киемнәрен алып киенде. Аннан кузгалып, беркадәр вакытлар баргач, бер ялан сыман җиргә чыктылар. Анда бәйләнгән бик яхшы ике ат тора иде. Сунарчы, атларны чишеп алып, берсен Сатыш әфәндегә биреп: «Һичбер якка бармыйча туры барсаң, берничә көннән Болгар шәһәренең өстенә генә барып чыгарсың», — диеп, төн тарафына карап китәргә кушты. Үзе, Сатыш әфәндене озата барып, беркадәр киткәч: «Хәерле, тыныч юл булсын, синең күрсәткән хезмәтеңә каршы биргән нәрсәләрем бернәрсә дә түгел, әгәр йортыма барырга күнсәгез, башкачарак хөрмәт иткән булыр идем», — диеп, рәхмәт укый-укый күрешеп, озатып калды. Сатыш әфәнде, үзенең сунарчы киеме белән ярып-ярып кешни торган ат өстендә булуын күреп, шулкадәр куанган иде. Аның гомерендә болай куанган чагы да юк дисәң дә, ялган булмас иде. Ул, гүя хәзер Болгарга кайтып җиткән кебек булып, куанычыннан яшен кебек оча иде. Ул, шулай берничә көннәр төнгә каршы барганнан соң, югарыда сөйләп үткәргән Волга ярындагы балыкчы карт янына барып чыкты.

IV

Сатыш әфәнде Волга суының ярыннан йөзеп менүгә, картның ашы әзерләнгән иде. Сатыш әфәнде никадәр ашыкса да, аның башын башка нәрсәләр чолгап алганга күрә, ул ашарга утыргач та, комсызланып ашарга тотынмыйча, балыкчы картка карап:

— Бабай, андый зур сугыш кайчан булды? Ничек алай Болгарны җимереп киттеләр? Безнең башлыклар, ханнар ни эшләде? Алар исәнме?

— Ай, Алла, бөтенләй генә бернәрсә дә белмисең икән, син кем соң? Кайда йөрдең? Каян киләсең?

— Бабай, мин кем икәнемне сөйләсәм, бик озак вакыт кирәк булыр, мин Ходайның бәхетле дә, бәхетсез дә бер бәндәсе инде. Зинһар, шуларны тизрәк сөйләсәнә, ничек булды?

— Менә ул ничек булды: шулай моннан сигез-тугыз еллар элек әллә каян бер дошман килеп чыкты да үзенең көчле явы белән шәһәрләрне ватып, яндырып, юлына туры килгән авылларны кырып-себереп, малларны җыеп алып китте. Алар бик кинәт килеп чыкканлыктан, безнең яуларыбыз рәтләп җыела да алмый калды. Башлыкларыбызны да, ханнарыбызны да тотып алып киттеләр. Хәзер инде без шул үзебезне җиңгәннәрнең кул астында торабыз. Хәзер бик тыныч инде, безнең белән берәү дә килеп сугышмый. Безнең күп кешеләр урман араларына качып беттеләр. Монда калып, алар кул астында торырга риза булганнарга тимиләр, риза булмаганнарны ни эшләтә торганнардыр? Менә, алайса, сиңа, ишетмәсәң.

Бу вакытта Сатыш әфәнде сулыгып-сулыгып елый иде. Балыкчы карт сүзеннән туктагач, аңарга бер-ике сүз әйтергә теләсә дә, тамагына әллә нәрсә килеп тыгылганлыктан, бер сүз дә әйтә алмады. Карт аңар утын әзерләргә кушып, үзе зур бер көймәсен көйләргә тотынды. Көймә көйләнеп бетүгә Сатыш әфәнде атын алып килгән иде, аны юмалап, сыпырып, көймәгә китереп керттеләр дә акрын гына калын әрәмәләр эченнән ага торган Волга суының агымына каршы менеп киттеләр.

Кояш агач башларына төшеп, озын-озын агач күләгәләре су өстенә төшкән вакытта, әрәмә арасыннан чыгып, су буе белән менеп китә торган үләнле киң сукмак янына карт көймәне туктатып, Сатыш әфәндегә төшәргә кушты һәм шул сукмакның Болгарга бара торган ташландык юл икәнен сөйләп, исәнләшеп китте.

Сатыш әфәнде дә, моңланып кына атына атланып, юлга төште дә карт күрсәткән тарафка карап китте. Аның башын әллә нинди төпсез уйлар чолгап алганлыктан, аты да, төнге кош тавышларын тыңлап, акрын гына үз көенә атлап бара иде. Сатыш әфәнде үзенең кайда икәнлеген бөтенләй онытып, хыялга чумып, күңеленә әллә ниләр кереп чыга, күз алдыннан әллә нәрсәләр үтә иде. Ул уйлый иде: менә Болгарга кайтып керә, Болгар шәһәре гөр килеп тора, анда һәр тарафтан төрле нәрсәләр төягән кәрваннар керәләр, урамында төрле кешеләр йөриләр, алалар, саталар, шау киләләр. Ул арада Болгарны ут чолгап алган, яна, дөрли, әллә нинди тавышлар ишетелә, кычкырышалар, еглашалар; менә Болгар кинәт югалып китә; бернәрсә дә калмый, аның урынында әллә нинди бер тавыш кына колакка чыңлап ишетелеп тора. Менә яңадан Болгар шау килә, аңар бернәрсә дә булмаган, ул һаман искечә тора, һаман иске Болгар. Ул шундый караңгы хыяллар белән таң беленеп яктыра башлаганчы барды, ул арада кояш чыгып бөтен дөньяны нурландыра башлагач, Сатыш әфәнденең уйлары да кояштан оялган сымак булып таралып киттеләр. Менә ул шулвакытта гына, үзен аңлап, атын куа башлады. Аңарга Болгар шәһәре утырган болыннар күренә башлагач та, әллә ни булган кебек, йөрәге шау итеп китте. Озак та үтмәде, ул дүрт күзе белән көтеп һәм никадәр хафалар чигеп кайткан Болгарга килеп җитте. Бичара ни күзе белән күрсен, ул киткәндә гөрләп тора торган Болгар бөтенләй эштән чыгып беткән. Ул килгән чакта зурлыгына, әллә нинди төрле-төрле нәрсәләрнең күплегенә хәйран булып йөри торган, адашырлык зур базарларның урыннарыннан җилләр исә, анда тузан кадәр булсын бернәрсә калмаган. Аның элгәре бөеклегенә, матурлыгына исе китеп йөри торган шәп йортлар, хан сарайлары, биек-биек манаралар берсе дә юк, бар да уалып төшкән, урыннарында өем-өем ташлар гына тора; хан мәсҗеденең ике манарасы белән аларның янында берничә таш биналар исән калсалар да, аларның янында да һичбер җан әсәре юк, бөтен нәрсә тып-тын, бары аларның ватылган, тишелгән җирләреннән җил сызгырып, әллә нинди ямансу, моңлы тавышлар гына ишетелеп тора. Сатыш әфәнде, үзен көчкә генә тотып, боларны тамаша кылып йөрде дә, исән калган биналар янында туктап, бик каты тавыш белән: «Кайда сез? Кая китеп беттегез?» — дип кычкырды. Билгеле, Сатыш әфәндегә каршы бер җавап бирүче дә булмады, ул үзен-үзе тота алмады, үксеп-үксеп егларга тотынды, беркадәр еглагач, эче бушаган кебек булып китте. Ул арада туган-үскән авылы исенә төшеп, тиз генә атын шул тарафка борды да Болгар күмелгәнче артына карый-карый китте.

Калын урманнар эченә кереп, Болгар күренмәс булгач кына аны тагын әллә нинди уйлар чолгап алды; аның бара торган сукмагы ташланып беткән иске сукмак булса да, Дәүләт халкының Болгар шәһәренә килә торган юллары булуыннан Сатыш әфәндегә таныш иде. Ул сукмак аңар тагын әллә ниләр исенә төшерде, ул тагын уйлый башлады, аның күз алдына Дәүләт авылы күренде: әнә Дәүләтнең болынында атлар йөри, хатын-кызлар болыннан сыерлар алып

кайталар, менә ул авылга кайтып керде, аны танымыйлар, очраган кешеләр «бу кем икән?» диеп калалар, Сатыш әфәнде аларга җавап бирми, бары көлеп кенә китә. Менә ул мәсҗед янына җитә, карт, озын таяк тотып, мәсҗедкә кереп бара, кешеләр аңар юл биреп торалар, әнә аларның йортлары күренә, аның сеңлесе, суга барырга хәзерләнеп, капкадан чыгып килә, ул кайтып керә, аның картаеп беткән атасы белән анасы каршы чыгалар, алар сагынганнар, балаларын кочаклап күрешәләр, аларга кешеләр җыелып, Сатыш әфәндене урап алалар: «Исәнме? Исән кайттыңмы? Менә син, югалган Сатыш, исән булгач, кайтып та килде», — диләр.

Сатыш әфәнде шундый татлы хыяллар белән ләззәтләнеп барганда, кинәттән аның исенә Болгар шәһәре килеп төшә, ул куркып йокыдан уянган сымак булып сискәнеп китә дә, як-ягына каранып, атын сызгыртып куалый башлый. Көн кичкә авыша башлаган чакларда ул Дәүләт авылына якынлаша, бары кечкенә генә бер тау сыман нәрсә менә дә, аннан соң Дәүләт авылы ялтырап күренеп торачак; ул, бик ашыгып атын куалап, шул кечкенә тауны менә дә башына суккан кебек булып катып кала. Дәүләт авылы юк, урынынннан җилләр исеп тора, ул үзенең күзләренә ышанмый башлый, күзен йомгач, Дәүләт авылы күренгән кебек була. Ул, бичара, бөтенләй ни эшләргә белми аптырап, Дәүләт авылының урынына чабып кайтып җитә. Шулай, дөрес, Дәүләт авылы әллә кайда югалып киткән, урынында һичнәрсә юк. Бары аның ат ашата торган болыны гына исән, ул һаман искечә тора. Сатыш әфәнде ул болынга барып: «Дәүләт авылы кайда?» — дип сорамакчы була, ләкин булдыра алмый, атыннан егылып җиргә төшә. Ул «аһ» диеп бер кычкыра да тормакчы була, тора алмый. Аның күзенә Дәүләт авылы күренеп китә. «Коткарыгыз мине», — диеп кычкырмакчы булса да, тавышын чыгара алмый. Ул арада анасы килгән кебек була. «Тор, балам», — ди. Торып анасын кочакламакчы була да кузгала алмый. Анасына нидер әйтмәкче була, ләкин теле кыймылдамый. Ул тагын «уф» диеп каты бер сулый да киерелеп җан бирә.

1912

Бәгъзе — *кайсыбер.*
Вөҗүд — *гәүдә.*
Гаюр — *кыю, гайрәтле.*
Заһир — *ачык булу, күренеп тору.*
Инкыйраз — *бетү, юкка чыгу.*
Кабил — *кебек.*
Касд — *теләк, максат.*
Көррәи әрыз — *Җир шары.*
Малик — *ия.*
Мәзкүр — *югарыда әйтелгән.*
Мәсафә — *ара.*
Мөкаддимә — *сүз башы.*
Парлак — *якты, данлыклы.*
Сөаль — *сорау.*
Тасдыйк итү — *раслау.*
Тәәссеф — *кайгыру, ачыну.*
Фәлякәт — *бәла, бәхетсезлек.*
Әлхасыйль — *кыскасы.*

Узган 2015 елның 20 ноябрендә КФУның социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты, «ТАТМЕДИА» АҖ Матбугат йорты (хәзер «Ногай» кунакханәсе) бинасында урнашкан Тукай клубында Гаяз Исхакый истәлегенә багышланган «Төрки телле мәгълүмати мәйданда татар журналистикасының роле һәм урыны» дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция уздырды.

КАЛӘМНЕҢ КАЛЬБЕ – МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫНДА!

Халкыбызның мәшһүр язучысы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның 15 томлык язма мирасы халкыбызга кайтарылды. Бу узган әдәбият елында булган иң зур казанышларыбызның берседер, мөгаен. Мирасы кайтарылу бер хәл, ә шәхеснең исемен, аның иҗатын халкыбызга гына түгел, ә башка милләтләргә дә таныту, әлеге шәхескә карата төрле буын кешеләрендә ихтирам, аның белән горурлану хисе тәрбияләү актуаль булып кала бирә. Бу уңайдан КФУның филология һәм мәдәниятара багланышлар институты профессоры **Хатыйп Миңнегулов** сүзләре игътибарга лаек: *«XX гасыр башында безнең һәрбере үзе бер дөнья булырлык әдипләребез бар: Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Фатих Әмирхан, Мәҗит Гафури һ.б. Боларның һәммәсе берәр төрки әдәбиятны бизәрлек затлар! Бу шәхесләр башка төрки*

милләтләрдә булса, аларны бәяли белерләр иде! XX гасыр башында безнең әдәбиятыбыз идея-тематик, сәнгати яктан баеый, дөньякүләм югарылыкка күтәрелә. Моны без авыз тутырып әйтергә тиешбез. Артык тыйнакланмыйк! Исхакый кайда гына яшәсә дә, татар өчен көрәшә, татар мәнфәгатен яклауны тар кысаларда гына түгел, ә дөньякүләм масштабта алып бара. Кайсы татар язучысын Рим Папасы кабул иткәне бар? Кайсы язучыбыз Япония императорлары белән очрашкан? Керенскийлар белән бәхәсләшкән әдипләребез бармы? Г.Исхакый иҗатының беренче адымыннан алып вафатына кадәр, хәтта үлеменә өч көн кала язган хатында да, мин халкыма хезмәт иттем, ди. Исхакый — безнең горурлыгыбыз!»

Сулдан уңга: Васил Гарифуллин, Разил Вәлиев, Сөмбел Таишева

Конференция барышында КФУның гаммәви коммуникация бүлеге мөдире, профессор **Васил Гарифуллин** «Гаяз Исхакыйның журналистлык һәм публицистлык эшчәнлеге», «ТАТМЕДИА» АҖнең генераль директор урынбасары **Сөмбел Таишева** «Татар журналларын торгызуда Гаяз Исхакыйның роле» кебек темаларга чыгыш ясады, татар журналистикасының актуаль мәсьәләләренә, күпләрне борчыган проблемаларга тукталды. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире **Вахит Имамов** Чистайда Гаяз Исхакый укуларын торгызу, Яуширмәдәге музеена ремонт ясау кирәклеген искәртте. Г.Исхакыйның 15 томлыгын төзүдә катнашкан галим-текстолог **Фәния Фәйзуллина** язучының язма мирасы турында сөйләде.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе **Разил Вәлиев** Гаяз Исхакыйның бөеклегенә соклануын, шул ук вакытта аның шәхесенә булган битарафлыкка җаны әрнүен белдерде: *«Бездә Габдулла Тукай урамы, скверы, мәктәбе, хәтта районы бар. Ә бит Гаяз Исхакый кайбер гамәлләре белән Тукайдан да зуррак булган! Без Исхакыйның бөеклеген раслау, исемен мәңгеләштерү, аны гади халыкка таныту өчен нәрсә эшлибез? Гаяз Исхакый — гомере буе милләт язмышын кайгыртып яшәгән язучы. Без соңгы вакытларда дәүләтчелегебезне торгызу 1980 нче елларда башланды, дибез. Юк, һич кенә дә алай түгел! Бу Исхакыйлар чорында ук башланган гамәл. Гаяз Исхакый аны 1980-1990 елларга караганда да кискенрәк итеп күтәргәндер әле! Бүген дә дәүләтчелегебез язмышы турында уйлыйбыз икән, һичшиксез, байрак итеп Гаяз Исхакыйны күтәрергә тиешбез. Аның «Идел-Урал» проекты хәзер дә актуальлеген югалтмаган!»*

Р.Вәлиев татар теленә, милләткә янә куркыныч янавын белдерде һәм татар журналистларын Исхакый кебек үк кыю, үткен телле булырга чакырды: *«Хәзерге вакытта Россия Дәүләт Думасына «Мәктәптә филологик белем бирү концепциясе» проекты тәкъдим ителде. Ул мәктәпләрдә барлык фәннәрне фәкать рус телендә генә укытуны күздә тота. Әгәр бу закон гамәлгә керсә, ул Россия Федерациясендә яшәүче бик күп халыкларның милләт буларак юкка чыгуына китерәчәк. Чөнки милләтнең бетүе милли телләрне (татар, чуваш, мари, удмурт, чечен, ингуш һ.б.) кулланучыларның саны кимүдән башлана. Журналистларыбыз кыюрак булсын иде. Һәрбер татар матбугат чарасының, журналының, интернет-сайтның, телевидение-радионың төп максаты, төп темасы милләт язмышы булырга тиеш».*

Конференциядә Г.Исхакыйның 15 томлыгын яңадан бастырып чыгару (чөнки беренче 5 томы инде сатуда юк, соңгы томлыклар да санаулы), аның чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез өчен электрон нөсхәсен булдыру, әдипнең драмаларын Г.Камал исемендәге Академия театры сәхнәсендә кую, «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен ТНВ телеканалы аша уку кебек тәкъдимнәр дә булды.

Гаяз Исхакый мирасының бер өлеше чит илләрдә, шул исәптән Төркиядә дә саклануы мәгълүм. Конференциядә Анкара шәһәре Гази университетының әдәбият факультеты доценты, доктор **Фәрһат Тамирның** «Skype» аша төрек телендә ясаган нотыгы күпләрнең игътибарын җәлеп итте. Бактың исә, Исхакыебыз төрек телен камилләштерү, аны гади халыкка да аңлаешлы итү өчен тырышып йөргән икән! Ф.Тамирның әлеге мәкаләсен сезнең хозурыгызга да тәкъдим итәбез. Пленар утырыш барышында бу докладны икътисад фәннәре докторы, КФУның К.Насыйри институты директоры **Рәсим Хөснетдинов** тәрҗемә кылды.

Ленар Гобәйдуллин

ТӨРЕК ТЕЛЕН ГАДИЛӘШТЕРҮ ХӘРӘКӘТЕ ҺӘМ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ

Фәрһат Тамир

Гаяз Исхакый — төрки халыкларның бердәмлеге (пантюркизм) идеясенә тугры калган һәм инанган татар язучысы, фикер иясе һәм сәясәтче. Ул, үз милләтенең борчу-мәшәкатьләреннән тыш, башка төрки дәүләтләрнең дә милли мәсьәләләре белән шөгыльләнгән. Без бу нотыгыбызда аның госманлы төрек телен гадиләштерү-җиңелләштерү хакындагы фикер-карашларын тәкъдим итәбез.

Гаяз Исхакый, 1908 елның ахыры-1909 елның башында, өч-дүрт ай качкын булып Истанбулда яшәгән [1]. Качкын булуга карамастан, тик ятмаган, биредәге шул дәвернең алдынгы төрек зыялылары белән аралашкан, Истанбулның иң мәшһүр журналы «Сыйрат әл-мөстәкыйм»дә («Sırât-ı Müstakîm») Төркиядәге тел мәсьәләсе һәм Русия мөселманнары хакындагы язмаларын бастырган [2]. Мәкаләләренең азагына «Казанлы Гаяз» дип имза куйган.

Язучының «Сыйрат әл-мөстәкыйм» мәҗмугасында басылып чыккан беренче язмалары Төркиядәге тел мәсьәләсе турында. Бу мәкаләнең беренчесе Сөләйман Назифның «Тасвир-и

Әфкар» («Tasvir-i Efkâr») газетасында басылып чыккан «Тел мәсьәләсе» («Lisân Meselesi») дигән язмасына [3], икенчесе исә Али Нусрәт бәйнең «Сәрвәт-и фөнүн» («Servet-i Fünûn») мәҗмугасында дөнья күргән мәкаләсенә кайтаваз буларак иҗат ителгән [4]. Беренчесе — «Тел мәсьәләсе» («Lisân Meselesi»), икенчесе исә «Тел мәсьәләсенә карата» («Lisân Meslesine Dair») дигән исемнәр белән дөнья күргән. Гаяз Исхакыйның бу ике язмасы да госманлы төрекчәсен гадиләштерү-җиңелләштерү мәсьәләсенә карый һәм бу хосуста ул шул заман өчен гаять мөһим булган берничә фикерне алга сөрә.

Тел, Гаяз Исхакый фикеренчә, бөтен төрки дөньядагы кебек үк, госманлы төрекләренең дә киләчәген билгеләүче хәяти мәсьәлә. Чөнки Төркиядәге һәрбер сәяси, мәдәни һәм иҗтимагый үзгәрешләрнең һәммәсе тел мәсьәләсенә бәйле. Язучы фикеренчә, госманлы төрекләренең язма теле гадиләшеп, бу гади телдә язылган әдәбиятны гади халык укыса гына Төркиянең киләчәге иминлектә булачак. Киресе булган очракта халык борынгы хорафатлар эчендә яшәвен дәвам итә, шуның нәтиҗәсендә Госманлы дәүләтенең шанлы исеме тарих тузанына гына күмелеп калачак. Бу мәсьәләне язучылар тирәнтен уйларга тиеш һәм аларның хәлиткеч чараларны тәкъдим итүләре кирәк.

Госманлылар тел мәсьәләсендә икегә бүленгән: әдәби тел тарафдарлары һәм гади тел тарафдарлары. Һәр тараф бер-берсе белән каршылыкта. *«Элегрәк тә, Ауропада протестантлык хәрәкәте барлыкка килгәннән соң, бу ике фикернең каршылыгы хасил булган, нәтиҗәдә телне гадиләштереп, аны гади халыкка да аңлаешлы итеп куллану турындагы фикер хупланып кабул ителгән. Бүген Аурупада бу турыда бәхәс юк. Казан төркиләрендә дә (ягъни татарларда) мондый бәхәс беткән инде, анда да халыкка аңлаешлы гади тел өстенлек алган. Әмма госманлы төрекләре бу хакыйкатьне әлегә кабул итмәгәннәр»*, — ди язучы. Сөләймән Назиф һәм Али Нусрәт бәйнең мәкаләләрендәге фикерләрне анализлап, бу язучылар һаман да халыкка аңлашылмый торган әдәби тел тарафдарлары, ди. Алар үз фикерләрен түбәндәгеләр белән дәлилли: а) телебезнең матурлыгы гарәп-фарсыдан алынган сүзләр һәм кушымчалар булуыннандыр, болар бетерелсә, телебезнең матурлыгы һәм нәфислеге калмаячак; б) телебез башка телләрнең кагыйдәләрен (гарәп-фарсы) кулланмаса яши алмас; в) язган вакытта борынгы (төрки) сүзләр кулланылса, халык барыбер без аңлатырга теләгәнне аңлый алмаячак.

Гаяз Исхакый фикеренчә, Сөләйман Назыйф һәм Али Нусрәт бәй үз язмаларын бары тик Истанбулның югары белемле, гарәп һәм фарсы телләренең кагыйдәләрен өйрәнгән, саннары өчдүрт меңнән артмаган укучылары өчен генә язалар. Бу өч-дүрт мең кеше белгән телне төрек теле буларак кабул итәләр. Әмма бу санның тышында калган, төрекчә укый-яза алган унбиш миллион госманлы төрекләре турында бер дә уйламыйлар. Болай эшләп аларның: *«Сезнең телегез дорфадыр, сез аңлаган телдә язабыз икән, безнең, язучы әфәнделәрнең, югары катлам зыялыларының хәтере калыр. Сез шул рәвештә калыгыз, сезгә сәясәт тә, әдәбият та, мәгариф тә кирәк түгел!»* — дияселәре киләдер.

Татар әдибе төрек язучыларының әлеге фикерләрен кискен тәнкыйтьли. *«Аларның «гадиләштерү булса, телебез дорфалашыр» рәвешендәге карашлары ялгыштыр. Чөнки бер телдәге матурлык, нечкәлек башка телләрдән алынган сүзләр белән генә була алмый. Мондый карашны якларга беркем дә батырчылык итә алмас. Бер телнең матурлыгы ул телдәге сүзләрнең төрле мәгънәләрдә кулланылуы, башка телләрдән сүзләр алмавы, ихтыяҗ буларак алынган сүзләрне дә туган*

тел кагыйдәсенә буйсындырылуы белән дә булырга мөмкин. Бу кагыйдәләр дөньядагы барык телләр өчен дә бер үк. Госманлы төрекчәсе дә бары тик бу юл белән генә матураер һәм үсәр. Шул сәбәпле Сөләйман Назиф һәм аның фикерендә булган башка язучылар да, бик күп санлы гарәп һәм фарсы алынмалары урынына, һәркем өчен дә җиңел аңлашыла торган төрки сүзләрне кулланырга тиешләр», — ди.

Аңлашылганча, Гаяз Исхакый — гади тел тарафдары. Аның фикеренчә, бу бер үк вакытта гади халык тарафында булу, дигән сүз дә әле. Татар әдибе һәрбер сәяси һәм иҗтимагый фикернең төрекләргә җиңел аңлашылуын һәм җиткерелүен тели. Чөнки Исхакый яшәгән дәвер — «гомумнең фикерләре гасырыдыр» («efkâr-ı umûmiye asrı»dır). Илнең төзеклеге, милләтнең тәрәккыяте, шул милләт кешеләренең барысының да фикердә,囲 эштә яңаруы белән генә булачак. Г.Исхакый фикеренчә, үз милләтен яратучы һәрбер төрек язучысы үз әсәрен үз милләте аңлардай гади төрек телендә язарга тиеш. «Уннан дүрте гарәпчә, уннан дүрте фарсыча, уннан бере французча һәм грек телендә һәм бары уннан бере генә төрек телендә булган әдәби тел»не кулланмаска тиешләр. Чөнки төрекләрнең фикерен уятып, аларга дөньяда ни булганлыкны аңлату, барыннан да бигрәк, язучыларның вазифасыдыр.

Дөрес, ул вакытта терминнар өчен госманлы төрекчәсендә сүзләр табылмаганлыктан, гарәп-фарсы сүзләренә ихтыяҗ туа. Ләкин, Исхакый фикеренчә, бу сүзләр «кунак» кына буларак кабул ителеп, аларга тулы хокук бирелергә тиеш түгел, ягъни алынмалар төрек теленең үз кагыйдәләренә нигезләнеп кулланылсын.

Гаяз Исхакый фикеренчә, халык белән зыялылар арасында тумыштан бернинди дә аерма юк. *«Шуңа күрә, «күпме генә ачык һәм борынгы төрки сүзләр кулланылса да, халык аңлатырга теләгәнне аңламас», дигән фикер тулысынча ялгыштыр. Бу рәвешле уйлаучы язучыларны төрек халкы белми, аларның язганнарын аңламый. Моның сәбәбе һич кенә дә төрекләрнең аңсызлыгы түгел, ә әдипләрнең үз әсәрләрен гади халык белмәгән гарәп һәм фарсы сүзләре белән чуарлап, үзгә бер телдә язуындадыр. Төрек халкы аңлаешлы телдә язылган мәкаләләрне, әдәби әсәрләрне бик җиңел аңлый, бернинди кыенлык юк. Мәсәлән, Мәхмәт Әмин бәйнең шигырьләрен халык гаять җиңел укый, аңлый. Бу җәһәттән, госманлы язучыларының бурычы — халык аңлаган төрек телендә язудыр»,* — ди язучы.

Әйтеп үтелгән бу фикерләр Гаяз Исхакыйның милләт тормышында телнең әһәмиятен бик яхшы аңлаганлыгын күрсәтә. Язучы бу карашы белән госманлы төрек язма теленең гадиләшүен-җиңелләшүен, ягъни халыкның күпчелеге аңларлык дәрәҗәдә булуын яклый. Тагын шунысы әһәмиятле: Гаяз Исхакый бу тәкъдимен 1911 елда «Яшь каләмнәр» («Genç Kalemler») мәҗмугасында госманлы төрекләренең язма телен гадиләштерүне әдәби бер агым хаденә китергән «Яңа тел» («Yeni Lisân») хәрәкәте тарафдарларыннан ике ел алдан әйтә. Шуның өчен дә бөек татар язучысының бу ике мәкаләсен госманлы төрек язма теленең гадиләшүенә тәүге адым һәм ышандыргыч дәлил буларак кабул итәргә кирәк.

Чыганаклар

1. Ali Akış. Anılar: Muhammed Ayaz İshakî – Hayatı həm Faaliyeti. – Ankara, 1979. – 302s. (Гали Акыш. Мизгелләр: Мөхәммәд Гаяз Исхакый – тормышы һәм эшчәнлеге. – Анкара, 1979. – 302б.)
2. Сыйрат әл-мөстәкыйм. – 1325(h). – 2 том. – №46, 50, 51, 52; 3 том. – №53, 55, 56.
3. Шунда ук. – 2 том. – №46. – Б.316.
4. Шунда ук. – 2 том. – №50. – Б.360. ■

ТУКАЙ – ЯДКЯРЛӘРДӘ

Рәмил Исламов, Җәүдәт Миңнуллин

Татар халык шагыйре Габдулла (Габдуллаҗан) Мөхәммәтгариф улы Тукай (1886-1913) турында истәлекләр аның тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнүдә мөһим чыганакларның берсен тәшкил итә. Аларны барлау-туплау, матбугатта бастыру һәм аерым китап итеп нәшер итү юнәлешендә максатчан эш, шагыйрь вафатыннан соң башлап, хәзергә кадәр дәвам иттерелә. Әмма бу хосуста ирешелгән казанышлар белән бергә башкарыласылары да байтак. Чөнки, мәгълүм булганча, күп кенә чыганаклар үз вакытында хаким идеология таләпләре нигезендә шактый «әшкәртелгән» рәвештә дөнья күргәннәр, ә байтагы, кызганыч ки, һаман хәзерге укучыга билгесез булып кала килә.

Г.Тукай турында истәлекләр аерым җыентык рәвешендә беренче тапкыр **Сәгыйт Исәнбаев** тарафыннан төзелеп, **«Тукай турында замандашлары: Истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы»**[1] исеме белән 1960 елда нәшер ителә. Анда шагыйрьнең *«туганнары, бергә эшләгән каләмдәшләре, авылдашлары, дус-ишләре, белеш һәм танышлары тарафыннан язылган истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр»*[2] тупланган. Материаллар, нигездә, Октябрь түнтәрелешенә кадәрге татар вакытлы матбугатыннан һәм СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты (хәзерге Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге) тупланмасыннан алынганнар. Алар, төзүче үзе аңлатканча, язылу датасына карап түгел, шагыйрьнең биографик хронологиясе буенча урнаштырылган.

Җыентыкта барлыгы 52 берәмлек истәлек һәм мәкалә, янә шагыйрь турында 3 бәет һәм Шәехзадә Бабичның (1895-1919), Мирхәйдәр Фәйзинең (1891-1928), Мәҗит Гафуриның (1880-1934), Габдулла Харисның (1893-1931), Габдулла Сөнгатинең (1894-1917 елдан соң), Сәгыйть Сүнчәләйнең (1888-1937) 6 шигыре урын алган.

1976 елда **Ибраһим Нуруллин** һәм **Риф Якупов** (1940-2011) төзегән **«Тукай турында хатирәләр»** дигән җыентык дөнья күрде[3]. Аны әзерләгәндә, кереш сүздә әйтелгәнчә, ике принципка нигезләнеп эш ителгән: *«Беренчесе: китап Тукайның тормыш юлын теге яки бу дәрәҗәдә тулы итеп күз алдына бастыр-*

[1] Тукай турында замандашлары: истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы / Төзүчесе һәм текстларны әзерләүче Сәгыйт Исәнбай. Г.Халит редакциясендә. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. — 296 б.

[2] Күрс. хезм. — Б.4.

[3] Тукай турында хатирәләр / Төзүчеләр һәм текстларга аңлатма бирүчеләр: Ибраһим Нуруллин, Риф Якупов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. — 191 б.

[4] Нуруллин И., Якупов Р. Хатирәләр турында берничә сүз / И.Нуруллин, Р.Якупов // Тукай турында хатирәләр… — Б.3.

[5] Күрс. хезм. — Б.4.

сын, биографиясенең барлык чорларын да тиешле пропорциядә чагылдырсын»[4]. *«Икенчесе: истәлек ышанычлы булсын, фактлардан бик үк читкә китмәсен, тормыш детальләренә бай булсын, шагыйрьнең җанлы сурәтен күз алдына бастыра алсын»*[5]. Истәлекләрнең 1917 елга кадәргеләренә өстенлек бирелсә дә, шагыйрьнең тууына илле, алтмыш, җитмеш, сиксән ел тулу уңаеннан язылганнары шулай ук игътибар үзәгенә алынган. Текстларда куелган сынык җәяләр эченә алынган өч нокта мәсьәләсенә килгәндә исә, ул *«сызылган урыннарның күпчелеге жанр сафлыгын саклау һәм кабатлаулардан котылу өчен эшләнде»*[6], дип аңлатыла.

Җыентыкта тупланган 33 истәлекнең 21е элекке басмада дөнья күргән. Әмма аларның кайберләре беренчел чыганактан алынган. Яңаларыннан 3се кульязмадан, 5се төрле көндәлек матбугаттан, 2се сайланма әсәрләрдән алынган. Я.Морадиның «Тукаев Уральскида» дигән китабының тексты да кыскартып урнаштырылган.

Шул ук авторлар 1986 елда **«Тукай турында истәлекләр»** исемле икенче җыентык та әзерләп нәшер итте[7]. Күләмне арттыру һәм эчтәлекне яхшырту юнәлешендә башкарылган *«бусына элеккеге ике китапта урын алган истәлекләрнең барысы да дип әйтерлек кереп бетү белән бергә, вакытлы матбугат һәм архивтан алынып, дистәдән артык материал»*[8] өстәлеп, ул барлыгы 51 берәмлекне эченә ала. Аларның яңа урын алганнары: төрле матбугаттан — 10, сайланма әсәрләрдән — 2, җыентыктан — 1. Кульязмада сакланган һәм киң катлау укучыга һаман да билгесез булып калган язмалар, нишләптер, анда кертелмәгән. Алар бит

[6] Күрс. хезм. — Б.3.
[7] Тукай турында истәлекләр / Җыентыкны төзүчеләр һәм искәрмәләрне әзерләүчеләр Ибраһим Нуруллин, Риф Якупов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. — 256 б.
[8] Нуруллин И. Кыйммәтле хәзинә / И.Нурулин // Тукай турында истәлекләр... — Б.6.

шактый гына, югыйсә. Шунысын да билгеләп үтү урынлы: әлеге соңгы ике җыентыкта искәрмә-аңлатмалар шактый баетылган.

Бу җыентыклар гәрчә Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнүдә мәгълүм роль уйнасалар да, кызганыч ки, алар шул чор хаким идеология кысалары нигезендә төзелгәннәр. Шул сәбәпле аларга, беренчедән, үз вакытында көндәлек матбугатта дөнья күргән бик күп истәлекләр, мәкаләләр һәм башка төрле чыганаклар кертелмәгән. Мәсәлән, «халык дошманы», «эмигрант», «динче» кебек ярлыклар тагылган Муса Бигиев, Гаяз Исхакый, Габделбарый Баттал, Мөхәммәтфуад Туктаров, Мөхәммәтсафа Баязитов, хәтта, иҗтимагый-сәяси афәтләрдән котылып калган Ш.Мөхәммәдъяров һәм башка шәхесләрнең язмалары шундыйлардан. Ул җыентыкларда инде акланганнардан, мәсәлән, Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗатын беренчеләрдән булып фәнни нигездә өйрәнгән Җәмалетдин Вәлидинең дә бары бер генә истәлеге урын алган, янә дүрт-биш мәкаләсе, нигәдер, игътибардан «читтә» калган.

Шагыйрьнең җеназа мәрасимен яктырткан язмаларның да бер-икесе генә хәзерге заман укучысына мәгълүм. Ә бит алар берничә. Дөрес, табигый ки, аларда кабатланулар да бар, шул ук вакытта бер-берсен тулыландыра торган фактлар да юк түгел.

Икенчедән, югарыда телгә алынган җыентыкларга кергән материалларның байтагы шактый кыскартылган. Кайвакытта андый урыннарны күрсәтү яки билгеләп үтү кирәк дип табылмаган. Алай гына да түгел, сүзләр үзгәртелү, текстлар редакцияләнү күренешләре дә күзәтелә.

Үткән елда безнең тарафтан әзерләнгән 2 том күләмендәге «Тукай — ядкярләрдә» дигән хезмәт бу юнәлештәге бай тәҗрибәгә нигезләнеп башкарылды. Әмма биредә Г.Тукай турында туганнары, замандашлары, дуслары һәм танышлары тарафыннан язылып һаман киң гавам укучыга билгесез калган, төрле вакытларда көндәлек матбугатта басылып чыккан истәлекләрне, мәкаләләрне мөмкин кадәр барысын да һәм тулысынча туплау максат итеп куелды.

Шагыйрь вафат булгач, замандашлары тарафыннан аңа багышлап шигырьләр язылган, бәетләр чыгарылган. Аларның барысы да Тукайга ихтирам хисләре белән сугарылган булса да, бу җыентыкка кайберләре генә кертелде. Чөнки күбесенең әдәби яктан эшләнеше бик йомшак булганга күрә, шушы юлны сайларга туры килде.

Әлеге җыентыкта барлыгы **670 берәмлек** материал тупланды. Шуларның **599 берәмлеге гарәп хәрефендәге чыганаклардан гамәлдәге татар алфавитына беренче мәртәбә күчерелеп, биредә урнаштырылды**.

Җыентыкка кертелгән аерым истәлек-хатирәләрне журнал укучыларының игътибарына да тәкъдим итәбез.

ӘҺЛИ ХӘЛИУЛЛИН ХАТЫНЫ КАМИЛӘ АПА ИСТӘЛЕКЛӘРЕ[9]

Минем картым моннан җиде ел элек үлде. Ул Габдулла белән яшьтәш иде. Кырлайда торганда алар Габдулла белән бергә укыганнар, бергә уйнап йөргәннәр. Габдулла турында ул шулай сөйли иде:

— Габдулла минем иң якын балалык иптәшем иде. Мәктәптә укыганда аның бик кечкенә бер чанасы бар иде. Һәр көн иртә белән китап, Коръәннәрен шул чанасына салып, безнең тәрәзә төбенә килеп «Әһли!» дип кычкыра торган иде ул. Мин йөгереп чыга идем дә, без аның белән бергәләп мәктәпкә китә торган идек. Ул вакыт безнең белән мәктәптә укучылар арасында яшь ягыннан да, гәүдә ягыннан да олырагы булып Мөхәммәтша Сафасы белән Сафиулла Хәбибуллин[10] исәпләнә иделәр. Сафиулланы ул вакытта ук малайлар «Сапи» дип йөриләр иде. Яше зур булуга карамастан, ул үзе сабакны да авыррак укый иде. Зур үсеп, буйга җитеп кечкенә балалар белән бергә укып йөргәнлеге өчен аратирә без аннан көлгәли торган идек. Габдулла аны күргән саен бик сузып кына: «Сапиу! Печию! Чиеп, чиеп булдыйму?» — дип кычкыра торган иде. Сапиның аңар ачуы килеп, аны куып йөри торган иде. Сапи тота башлагач, Габдулла миңа килеп ышыклана торган иде. Мин аңар Сапидан тидертми идем. Күп вакыт Габдулла, скамья астына йә бүлмә артына кереп, шул сүзләр белән Сапины үрти торган иде.

Минем картым, солдаттан кайткач, миңа өйләнгәнче Петропавелга[11] эшкә киткән. Шулвакыт Габдулладан аны Казанга үзенә кунакка чакырып хат килгән булган. Картым кайтканчы Габдулла үлгән булган. Картым үлгәнче шуны сөйләп, шуңар бара алмавына үкенеп йөрде. Бервакыт, миңа өйләнгәч, бергәләп Казанга бардык. Шулвакыт картым: «Габдулла исән булса, без аңар керер идек, мин аңар сине күрсәтер идем», — дип катлы-катлы сөйләп йөрде.

ХӘКИМ НИГЪМӘТҖАНОВ[12] ИСТӘЛЕКЛӘРЕ[13]

Мин Тукайга караганда яшьрәк булсам да, аның белән бергә уйнадым һәм бервакытта мәктәптә булдым. Мин бик шук идем. Тукай да бик шаян иде. Ләкин ул үзе күп уйнамый, күбрәк балаларны котыртып уйната иде. Бервакыт Сәгъди картның тормышы бик начарланып китте. Зөһрә тәтәй үзе малай тапкач, Тукайга анда тору читенләште. Ул мәктәпкә күчеп тора башлады. Сәгъди картлардан ашарына алып килә алмый иде. Шуңа күрә мәктәптә ач тора иде. Ул вакытта мин бабайларда тора идем. Минем бабай Гыйбадулла исемле булып, авылның бай тормышлы кешесе иде. Мин Габдулланы еш кына бабайларга алып кайтып тамагын туйдырып җибәрә идем. Бабай безне үз янына утыртып чәй эчерә, ашата иде. Бабай ул ат суючы иде. Беркөн ат суйгач, өй казанына тутырып ит салганнар иде. Мин Габдулланы, аш өйгә алып чыгып, печь башына мендереп утырттым да казаннан

[9] Камилә Хәлиуллина (1892-1968) — Г.Тукайның Кырлайдагы сабакташы һәм иң якын дусларыннан берсе Әһлиулла Хәлиуллинның (1886-1937) хатыны. Язучы һәм әдәбият галиме М.Гали тарафыннан 1944 елда кириллицада язып алынган әлеге истәлекләр хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана: 9 ф., 4 тасв., 55 сак. берәмлеге. **Текст** шуннан алынды һәм **беренче мәртәбә басыла**.

[10] Сафиулла Хәбибуллин (1884-?) — Кырлай авылы кешесе, Г.Тукайның замандашы.

[11] Петропавел (Кызылъяр) — Казакъстандагы шәһәр.

[12] Хәким Нигъмәтҗанов (1889-?) — Кырлай авылы кешесе, Г.Тукайның замандашы. Язучы һәм әдәбият галиме М.Гали тарафыннан 1944 елда кириллицада язып алынган әлеге истәлек хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият

Арча районы Яңа Кырлай авылында Сәгъди абзый йорты. 2013 ел, март

кисәк-кисәк ит алып аңар бирдем. Ул кулларын пешерә-пешерә аны бик шәпләп ашады. Берничә мәртәбә мин, бабайларның ашау әйберләрен урлап, аның тамагын туйдырып җибәрдем. Беркөнне калага чыгарга дип бабайга борай күмәче пешереп куйганнар иде. Габдулла белән без икәүләп шул күмәчне ашадык. Аны сизделәр. Аның өчен безне ачуланып кына калмадылар, бабай «Габдулла минем калага алып барасы күмәчемне ашап чыккан», дип муллага әйткән. Шуның өчен мулла Габдулланы чакырып ачуланган. Габдулла: «Ул күмәчне миңа Хәким ашатты», — дигән.

Габдулла ул, бераз ашаса, һәрвакыт «мин тук, тук!» дип кикереп йөри иде. Мин аның «Тукай» дигән фамилиясен кайдан алынуын белмим. Ул вакытта ул үзен «Тукай» дип йөртми иде. Мин үземчә әллә шул «Тук, тук» дигән сүздән «Тукай» дип аталып киткәнме икән, дип уйлап йөрим.

Габдулла ул бала вакытыннан ук җыр һәм такмак чыгарырга бик оста иде. Ул вакытта безнең авылда Сабит атлы кешенең берничә кызы бар иде. Аның олы кызы Бәнат, Әсәт исемле бер егет белән йөреп, корсак тутырды. Ләкин Әсәт аңар өйләнмәде, аның сеңлесе Җәмиләне ябыштырып чыгарды. Шуннан соң халык, бигрәк тә бала-чага арасында шул турыда чыгарылган җыр һәм такмак таралды. Минем уемча, ул җыр һәм такмакларны чыгаручы кеше, һичшиксез, Габдулла иде. Ләкин ул аны үзе җырламый иде. Бәлки, үзе чыгаргач, халыкка беленер дә, мине ачуланырлар, дип куркып җырламагандыр. Ләкин минем үземә генә ул бу җыр һәм такмакларны җырлап күрсәтте. Мин аңарчы ул җыр һәм такмакларны бер кешедән дә ишеткәнем юк иде. Шуннан соң ул җыр һәм такмакларны мин балалар алдында җырлап йөри башладым. Шуннан соң ул җыр һәм такмаклар халык арасында таралды.

Ул җыр һәм такмакларның бик азы гына хәзер минем хәтеремдә калганнар. Аның Бәнат авызыннан җырлана торганы шул:

Аклы ситсы күлмәгеңне каралганчы ник кидең,
Алырдай булып йөрмәгәч, саргайтканчы ник сөйдең?

һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана: 9 ф., 4 тасв., 55 сак. берәмлеге. **Текст** шуннан алынды һәм **беренче тапкыр басыла**.

[13] Авыл халкы бу кешенең сүзенә критическирәк карарга киңәш бирделәр. Аратирә аның юкны бар итеп сөйләү гадәте дә бар икән. — М.Г.

Аннан «Сабит абзыйның бакчасы зирек белән тулгандыр», дип башлана торган такмакның ахыры «Апасы белән йөреп гомер итте, сеңлесен алып көн итте», дип бетәдер иде. Аны кайбер кеше «Апасы белән йөреп мәхрүм итте, Җәмиләсен алып көн итте», дип тә җырлыйлар иде.

Ул җыр һәм такмак озын иде, башкасы хәтердә калмаган.

Ягъкуб Байбурин[14]

ГАБДУЛЛА ТУКАЕВ ХАТИРӘСЕ

1910 нчы елның май ае иде. Ул вакыт Ташаяк ярминкәсенең иң кызу чагы иде.

Беркөнне төштән соң олуг шагыйрь Габдулла Тукаев фатирга[15] алҗып кайтып:

— Ташаякта булдым әле, — диде.

Хәзер хәтеремдә юк, безнең кайсымыздыр аның анда нишләгәнлегене сорады. Ул, артык эш булмаган шикелле генә иттереп:

—Карусельдә әйләндем, элекке үчне алдым, — дип, Ташаяк ярминкәсе кергәч, инде өченчеме, дүртенчеме тапкыр, безгә бала вакытында Казанга килеп Яңа бистәдәге «әти»се тәрбиясендә торган чакта Ташаяктан карусельгә утыра алмаенча кайтуыны вә шунда шуның өчен ни дәрәҗә боекканыны, кимсенгәнене сөйләде.

Ул вакыт без шагыйрьнең бу хәрәкәтене йиңелчә генә көлеп уздырдык. Әмма шагыйрьнең үзенең тәбәссеме[16] хәтеремдә калмаган.

Шуннан бер өч-дүрт көн узгач, бервакыт шагыйрь миннән үзе белән Ташаякка минем дә чыгаламмылыгымны сорады (ул күп вакыт андый йиргә ялгызы гына йөрми торган иде).

Киттек.

Ташаякка барып кергәч, аның теләве буенча, иң әүвәл туптуры карусельгә таба юнәлдек. Без барып туктаганда, карусель әле әйләнә, гармун әле уйный иде. Озакламады, карусель туктады. Әйләнеп туйганнар төшә башладылар, туймаганнар икенче тапкыр әйләнергә калдылар. Бушаган урыннарга яңа кешеләр (билгеле, күбесе бала-чага) урынлаша башладылар. Олуг шагыйрь дә агач аргамакка таба бара башлап, миңа карап:

— Әйдә, меник инде, — диде.

Мин, бераз кызарып, үземнең тартынганымны, оялганымны сөйләдем һәм:

— Син үзең генә әйлән. Мин менә бунда сине көтәрмен, — дидем.

Аның чәһрәсе[17] әүвәлгедән җитдиләшә төште. Ул, миңа тугры карап:

— Аннан ни булган соң? — диде.

Мин, аның кәефе китәчәкне күреп, вә эчемнән: «Чынлап та, аннан ни була соң?» — дип уйлап, аның артыннан киттем.

[14] Ягъкуб Байбурин (1880–1914) — журналист, тәрҗемәче, Г.Тукайның дусларыннан берсе. Аның бу истәлеге **беренче мәртәбә «Аң» журналының 1913 елгы 9 нчы санында басылган**. Текст шуннан алынды.

[15] Ул вакыт без: Габдулла Тукаев, Фатих Әмирхан, Вафа Бәхтияр, мин, язга чыккач, Ботанический бакча каршында дача шикеллерәк бер фатир алып тора башлаган идек. Автор искәрмәсе. Ул Литовченко дигән кешенең агачтан төзеттерелгән йорты Казанның хәзерге Һади Такташ урамында була. Аның урынына кирпечтән биш катлы 115 нче санлы яңа бина корылган.

[16] Тәбәссем — елмаю, көлемсерәү.

Икемезгә беррәттән ике агач аргамак табып алдык. Икемезгә дә атларның матур, яхшы, шәп төслесе тугры килде. Атландык.

Шагыйрьнең аргамакка атлангач, егыла күрмим дигән бала шикелле, куллары белән бик каты кысып, аргамакны түшәмгә беркеткән нечкә тимер баганага бик нык тотынганы әле хәзер дә күз алдымда. Әгәр ул тотыну гади бер тотыну гына булса, мин аны язмас та идем, ләкин ул чын күңелдән саклану иде.

Утыручылардан акча җыя башладылар, без дә икемезгә дүрт тиенне түләдек. Шуннан соң карусель салмак кына әйләнә башлап, гармунчы да салмак кына уйный башлап, бара-тора икесе дә куәтләнә башлады. Шуңар утыручылар бала-чаганың көлүләре, кычкырышлары, «кәефләнгән» пассажир марҗаларның җырлаулары бергә кушылып, шунларның барысыннан чынлап та игътибар итәрлек мәнзарә[18] хасил булды. Әмма шунларның шау-шуларына, гармун көенең күңел күтәргечлегенә карамаенча, олуг шагыйрьнең чәһрәсе һаман шул бер килеш җитди вә уйчан иде. Аның кыяфәте, баганага тотынышы карусель туктаганча һаман бер килеш булды.

Башым әйләнгәнлектән, карусель туктагач, мин «айгырым»нан йиргә төштем; ул миннән соң тагы ике тиенлек әйләнде. Аннан төшкәч миңа:

— Үч кайтты инде, — диде.

Аннан соң савыт-саба, уенчык кибетләре рәте буйлап киттек. Уенчык кибетләрене, савыт-саба кибетләрене туктый-туктый карап йөрдек.

Ул вакыт аның йөзеннән чынлап та тынычлану, канәгатьләнү, җиңү галәмәтләрене аңларга мөмкин иде. Ул, ул вакыт үзенең «Исемдә калганнар»ында:

«…Кайчакта әни белән Ташаяк базарына барып, андагы уенчык базарларына кызыгып вә самакатларда[19] шатланып-шатланып агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп тора идем.

Мин дә атланыр идем — акчам юк. Әнидән сорарга куркам, ул үзе белеп бирми иде.

Шулай итеп, мин кеше рәхәтенә генә кызыгып кайта идем…» — дип, язганынча көчсез, кодрәтсез түгел иде инде…

Шагыйрь ник «үч» ала?

Анадан бәхетсез булып туган шагыйрьне тормыш үзе вә әллә нинди бәндәләре аркылы таптаган, изгән. Булачак вә булган олуг шагыйрьне, кайда гына булмасын, читсенгән, «эткән дә төрткән»… Аның тук вакыты да бик санаулы гына булган…

Менә шунлар, шул тирән җәрәхәтләр барысы бергә җыела-җыела нечкә хисне тишеп чыкканнар вә шуның өчен анларны басып калырга олуг шагыйрьнең куәте йитмәгән — ул анларны «үч» белән юарга тотынган, вә шул аңар ләззәт тә биргән, вә шул аны тынычландырган да.

Менә шулай итеп, олуг шагыйрьнең соңгы вакытта тормышка галәбәләреннән[20] берсендә миңа шаһит булырга тугры килде. ■

[17] Чәһрә — йөз, төс, кыяфәт.
[18] Мәнзарә — күренеш.
[19] Самокат — карусель. Автор искәрмәсе.
[20] Галәбә — җиңү, өстенлек.



ЯКТЫ ӨМЕТ – ОСТАЗЫБЫЗ!

Альберт Борһанов

2015 елның 14-18 сентябрендә Судак шәһәрендә (Кырым Республикасы) «Кеше һәм табигать. Социотабигыять тарихы» дип исемләнгән нәүбәттәге XXV Халыкара фәнни конференция узды. Аңа кадәр конференция 24 мәртәбә Кырым Республикасы, Краснодар краеның төрле шәһәрләрендә, Мәскәү янындагы Звенигород, Польшаның Познань һәм Краков шәһәрләрендә өр-яңа фәнни юнәлеш – социотабигыять тарихы фәненә нигез салучы, профессор Эдуард Сәлмән улы Кульпин-Гобәйдуллин җитәкчелегендә РФА Шәрыкны өйрәнү институтының Социотабигыять тарихы проблемалары буенча фәнни шура ярдәме белән, Польша Фәннәр академиясе һәм Кырымның югары уку йортлары, музейлары катнашында оештырылды.

РФАдә социотабигыять тарихы буенча фәнни шура эшен оештыру, **«Человек и природа. Проблемы социоестественной истории»** дигән монографияләр сериясенә, «История и современность» фәнни журналына мәкаләләр туплау һәм бастырып чыгаруга да Эдуард Сәлмән улы бар көчкуәтен, акыл-зиһенен бирде.

Судакта социотабигыять проблемалары турындагы XXV конференция Э.С.Кульпин-Гобәйдуллинның якты истәлегенә багышланды. Ул Мәскәүдә, Кырымнан кайтканнан соң, 2015 елның 23 июнендә бакый дөньяга күчте. Шул уңайдан тарихчы, философ, шәркыятьче-галим, укытучым, дустым, гомумән, чын мәгънәсендә зыялы шәхес Эдуард аганың тормыш юлы һәм фәнни эшчәнлеге хакында бәян итәргә телим.

***

Бу инсан хакында төрле риваятьләр сөйләделәр, исән вакытында аның фәнни карашларына, фаразларына, китапларына һәм эшчәнлегенә төрле мөнәсәбәт булды. Шунысы хак, ул — күркәм кеше, үз Ватанының асыл улы, һәм, әлбәттә, икътисад, фәлсәфә, тарих фәннәрендә саллы хезмәтләр калдырган зур галим. Эдуард аганың язмышы шактый сикәлтәле. Әмма ул аны намус белән яшәде, күпләр өчен ачык, киң күңелле кеше булды.

Эдуард Кульпин-Гобәйдуллин — икътисад фәннәре кандидаты, фәлсәфә фәннәре докторы, профессор, Россия табигыять фәннәре академиясе академигы, Мәскәү физика-техника институтының тарих кафедрасы мөдире, РФАнең Шәрыкны өйрәнү институты (аңа кадәр Социология институтында эшләде) баш фәнни хезмәткәре, социотабигыять буенча фәнни шураның җитәкчесе, **«История и современность»** журналының баш мөхәррире, икътисад, фәлсәфә, Кытай, Шәрык, Россия, Евразия, Европа һәм Алтын Урда тарихлары буенча 30га якын фәнни китап һәм саллы монографияләр авторы, социотабигыять проблемаларына нисбәтле 30лап җыентыкның төзүче мөхәррире.

Эдуард Сәлмән улы 1939 елның 21 сентябрендә (документ буенча 29 сентябрь) Бакы шәһәрендә дөньяга килә. Аның әнисе ягыннан карт бабасы Александр Кульпин — оста куллы крепостной крестьян, ә әтисе ягыннан карт бабасы Салих Гобәйдуллин — мәшһүр татар сәүдәгәре, хәйрияче булган. Салихның бер улы, ягъни Эдуард аганың бабасы — һәммәгезгә дә мәгълүм татар тарихчысы, шәркыятьче һәм язучы, заманында Казан университетын беренче дәрәҗә диплом белән тәмамлаган шәхес, татардан беренче тарихчы-профессор, күп мәкалә һәм китаплар, шул исәптән **«Татар тарихы»**ның да авторы Газиз Гобәйдуллин, 1937 елда пантюркизмның төп идеологы буларак, атып үтерелә.

Газиз Гобәйдуллинның улы Сәлмән (ягъни Эдуард аганың әтисе), Бөек Ватан сугышының башыннан азагына кадәр ил азатлыгы өчен аяусыз көрәшкән, халык дошманы улы буларак җәбер-кыерсытуларны күп күргән зат. Миңа Сәлмән ага Гобәйдуллин белән очрашып күрешергә насыйп булды. Ул гади, кызыксынучан һәм зыялы кеше иде. Мәрхүмнең татар халкына һәм Татарстанга ихтирамы чиксез булды.

Эдуард Сәлмән улы 1956 елга кадәр Советлар Союзының ун мәктәбен алыштыра, аннары исә даими Мәскәүдә яши. Мәктәптә укыганда ук шәркыятьче булырмын, дип уйлый, бер туганы (әлбәттә, татар) ярдәмендә гарәп телен дә өйрәнә, әмма Шәрык телләре институтына (хәзер МДУның Азия һәм Африка илләре институты) сәламәтлеге начар булу сәбәпле керә алмый.

Эдуард ага Мәскәү полиграфия институтын тәмамлый. Уку вакытында «Комсомольская правда»ның штаттан тыш хәбәрчесе була, жур-

А.А.Борһанов, Э.С.Кульпин-Гобәйдуллин, И.М.Миргалиев Саратовта. 2015 ел, июнь

налист булырга хыяллана. Әмма дә беренче командировкасы вакытында уңышсызлыкка очрый. Дәүләт электрокерамика тикшеренү институтының лабораториясенә эшкә урнаша, ике елдан Нефть эшкәртү һәм нефть сәнәгате министрлыгына китә.

Эдуард аганың һәрвакыт үз фикере бар иде, дәшми торырга кирәк булган чакларда да, ул әйтәсе сүзен кистереп әйтте, белгечләрнең, гади халыкның мәнфәгатен яклады. Шунысы кызык, үзсүзлелеге нәтиҗәсендә аңа юллар ябылмады, ә киресенчә, киңрәк ачылды.

1970 елда Э.С.Кульпин Халыкара эшчеләр хәрәкәте институтының аспирантурасына укырга керә, Кытайны өйрәнеп, диссертация яклый. 1975 елда **«Технико-экономическая политика руководства КНР и рабочий класс Китая»** дигән беренче китабын бастырып чыгара. Тагын ике ел дәвамында аның мәкаләләре төрле җыентыкжурналларда басыла, ә аннары ун ел дәвамында галимнең Кытай буенча мәкалә-китаплары бер генә фәнни журнал тарафыннан да кабул ителми.

Килеп туган киеренке хәлдән бушану өчен, яшь галим ил буенча лекцияләр укый, Матбугат һәм яңалыклар агентлыгында эшли. Ел ярым Көнбатыш кешесе рәвешендә кереп **«Хәзерге заман Кытае һәм без»** исемле Сингапур журналына мәкаләләр яза. Журнал сәхифәләрендә үз исемен Калифорнияле профессор Эд Варт дип куя.

Кытай турында сүз әйтергә ярамаса да, аның революциягә кадәрге чоры хакында язарга мөмкин. Э.Кульпин бу темага да нисбәтле докладлар укый башлый, яңа монография иҗат итә. Әмма аны антик дөньяны өйрәнүче тарихчылар пычак кайрап каршы ала. СССР ФА Шәрыкны өйрәнү институтының Кытай бүлеге галимнең кулъязмасын ике мәртәбә тикшерә: башта инкяр кыла, ә аннары 1984 елда монографияне бастырырга һәм аны докторлык диссертациясе буларак якларга тәкъдим итә. Әмма мәсьәлә алай гына хәл ителми, кулъязма җиде ел дәвамында **«Шәрык әдәбияты»** нәшриятының киштәсендә тузан җыеп ята. Аннары исә, Э.С.Кульпин китапка кул селтәргә теләгәч кенә, аның хезмәтенә битараф төркем тарафыннан киңәшмә җыела. Баш мөхәррирнең: «Китап ничә ел яшәячәк?» — дигән соравына автор: «Ким дигәндә 50 ел», — дип җавап бирә. Шулай итеп, **«Человек и природа в Китае»** дип исемләнгән монография 1990 елда гына басылып чыга, Мәскәү

шәһәрендә 15 көн эчендә сатылып та бетә, ә аннары автор СССР ФАнең Шәрыкны өйрәнү институты игълан иткән конкурста беренче премияне ала.

Сикәлтәле тормыш юлы, әти-әнисе белән экспедицияләрдә йөрү, аспирантура каникуллары вакытында Беловежская Пущада эшләү, инженерлык хезмәте һәм, әлбәттә, борынгы Кытай тарихын өйрәнү Эдуард Сәлмән улына башка цивилизацияләрне дә танып белер өчен бай тәҗрибә биргән, гуманитар һәм табигыять фәннәре белән кисешкән яңа фәнни юнәлешкә — социотабигыять тарихына күзләрен ачкан. Эдуард ага үзе укырга керә алмаган Азия һәм Африка илләре институтында социотабигыять тарихы буенча лекцияләр укый башлый. 1992 елда **«Социоестественная история: предмет, методы и концепции»** дигән темага докторлык диссертациясен яклый. Шул ук елда Кырымның Күктүбә култыгында **«Кеше һәм табигать — социотабигыять проблемалары»** Халыкара конференциясен оештырып җибәрә, тарихчыларның, психолог, биолог, географ, геолог һәм башка табигыять белгечләренең фәнни җитәкчесе булып китә. Шәһәр тирәлеге академиясе каршында социотабигыять тарихы үзәге, Россия фундаменталь тикшеренүләр фонды һәм РФА Шәрыкны өйрәнү институты ярдәме белән, Э.С.Кульпин җитәкчелегендә **«Генезис кризисов природы и общества в России»** проекты буенча 15 китап чыгара. Соңрак галим тарафыннан РФнең социология һәм Шәрыкны өйрәнү институтлары каршында социотабигыять тарихы мәсьәләләре буенча фәнни шура оештырыла.

Эдуард Кульпин-Гобәйдуллин язган хезмәтләрне биредә санап бетерү мөмкин түгел, шулай да кайбер китапларына тукталып үтәсем килә.

Галимнең 1995 елда басылган **«Путь России»** исемле китабы — Евразия һәм Россия тарихын тикшерү өлкәсендә тиңе булмаган басма. Бу китапта Россиядә XIV-XVII гасырлардагы социаль-икътисади кризиска анализ ясала. Тарихны анализлау Көнбатыш Европаның үсеш юлы белән параллель рәвештә тикшерелә, Россия дәүләтчелеге тарихында төркиләрнең һәм Алтын Урданың роленә дә аерым урын бирелә.

«Золотая Орда. Проблемы генезиса Российского государства» исемле монографиясе 1998 елда Мәскәүдә басыла. Өч мәртәбә басылып таратылган бу китапта XIII-XVI гасырларда Көнчыгыш Европада булган вакыйгалар турында белемнәр туплана һәм Россия җәмгыятендәге үтә дә кискен поблемаларның чыганаклары тикшерелә. Тулаем алганда, китап урта гасырлар Евразиясенең иң эре һәм оешкан дәүләте Җучи Олысына (Алтын Урдага) багышланган.

Эдуард Кульпин фикеренчә, XIII гасырда Евразиянең төп халыкларын берләштергән һәм XIV гасырда ислам динен кабул иткән төркиләр үзләренең әйдәманлыкларын саклап кала алмыйлар, ике гасырдан соң лидерлык көнчыгыш славяннарга күчә. Россия, дәүләт буларак баш калкытканда, барлык уңай традицияләрне дә Алтын Урдадан ала. Урдалыларның йогынтысы Россия дәүләте оешуга, рус милләтенең югары үсешкә ирешкән этнос буларак формалашуында зур роль уйный. Шуның өчен дә автор Евразия һәм Россия тарихын өйрәнгәндә Алтын Урдага да аерым урын бирергә кирәк, дип ассызыклый.

Соңрак галимнең тагын бер мөһим хезмәте — **«Русь между Западом и Востоком»** басылып чыга. Биредә автор VIII-XIV гасырларда Көнчыгыш Европада булган күренеш һәм вакыйгаларга социотабигыять — кеше һәм табигатьнең үзара мөнәсәбәте ноктаи назарыннан карый. Китапта урта гасырлардагы Евразия тарихында Алтын Урданың роле, славян, төрки һәм башка халыкларның киләчәк язмышлары тикшерелә. Хезмәтнең нигезен Э.С.Кульпин-Гобәйдуллинның

Познань шәһәрендәге (Польша) Адам Мицкевич исемендәге университетта укыган лекцияләр курсы тәшкил итә.

Галимнең **«Золотая Орда: Судьбы поколений»** (2008 ел) исемле китабы 8 мәртәбә басылып чыга. Бу монография Россия, Казакъстан, Украинада яшәүче төрки халыклар тарихы һәм Идел буе Болгарстанының утрак төркиләре белән бергә кушылып, уңай булмаган табигый шартларны җиңеп, дөньяда тиңе булмаган дала шәһәр цивилизациясе төзегән Евразия күчмәннәренең тормышы, аларда булган кискен үзгәрешләр турында. Китапта кешеләрнең дөнья һәм үзләре турындагы карашларына, кеше белән табигать, этносларның үзара мөнәсәбәтләренә, югары мәдәнилекнең экологик һәм икътисади факторларына, тәхет түнтәрелешләренә аеруча игътибар ителә. Җәмгыять беренче мәртәбә тарихи анализда тере организм үсеше кебек карала. Күп кенә халыкларның, шул исәптән төркиләрнең һәм, гомумән, Россиянең дә тарихи үсеш-үзгәреш этабы, ягъни кризис, күтәрелеш һәм яңарышы кешелекнең 7 буыны дәверендә булуы мөһим, дип яза.

2005 елдан Э.С.Кульпин үзенең бар көч-куәтен Россия гуманитар һәм тарихи басмалары арасында иң яхшысы дип саналган «История и современность» фәнни журналын редакцияләүгә һәм дөньяга чыгаруга бирде.

***

Миңа Эдуард Сәлмән улы Кульпин-Гобәйдуллин белән иҗади һәм шәхси хезмәттәшлек алып бару, аның белән дуслашу бәхете насыйп булды. Ул оештырган күп кенә конференцияләрдә катнаштым, **«Человек и природа: проблемы СЕИ»** һәм **«История и современность»** җыентыкларында гына да 20гә якын фәнни мәкалә бастырдым.

Бу мөхтәрәм шәхес белән 1995 елда, Чиләбе һәм Әркаимда узган «Россия һәм Шәрык» дип исемләнгән Халыкара конференциядә танышкан идем. Ә якыннанрак танышуыбыз шул ук елның декабрендә Казанда һәм Биектау районы үзәгендә оештырылган **«Казан арты тарихы һәм мәдәнияте»** беренче төбәк фәнни-гамәли конференциясендә булды. Соңрак Эдуард ага Казанда һәм Татарстанның районнарында еш кунак булды, татар галимнәре оештырган халыкара конференция һәм корылтайларның мәртәбәле кунагына әверелде. Биектауда галим төбәкне өйрәнүче җирле тарихчылар белән, шулай ук район хакимияте башлыгы, хәзер Республикабыз Президенты Рөстәм Миңнеханов белән дә очрашкан иде.

Соңрак, 2009 елда Рөстәм Нургали улы Э.С.Кульпинга, 70 яшьлек туган көне уңаеннан, татар халкы тарихын өйрәнүгә керткән өлешләре өчен Рәхмәт хаты тапшырды.

Галим белән соңгы очрашуым, аның белән актык сохбәтләшүем 2015 елның 3-6 июнендә, Саратовта Алтын Урда шәһәре Үкәккә багышлап оештырылган фәнни конференция эше барышында булды. Энергиясе, көч-куәте ташып тора, яңа фикер-идеяләр белән яна иде әле… Кызганыч, Саратовтагы очрашу соңысы булыр, дип кем уйлаган…

Татар халкының ватанпәрвәр улы Эдуард аганың кылган игелекле гамәлләре, язган хезмәтләре — фәнни каһарманлык һәм гуманизм үрнәге! Галим татар халкы тарихына карата гадел караш булдыру, халкыбызның Россиядә, дөньядагы ролен билгеләү һәм таныту өчен бәһаләп бетергесез эшләрне күп кылды. Татарстанның яшь галимнәрен тарих фәненә җәлеп итүгә, аларның фәнни мәкаләләрен бастырып чыгаруга һәм диссертацияләрен яклатуда да аның зур хезмәте бар. Ул безнең дустыбыз, остазыбыз һәм Якты өметебез иде…

***Редакциядән:** Э.С.Кульпинның хезмәтләре белән журналыбызның алдагы саннарында таныша алачаксыз.* ■

ИРЕК ШӘРИПОВ: «ТАТАРНЫҢ КӨЧЕ – ДУСЛАРЫНДА»

ТР Дәүләт Советы депутаты, Халыклар Дуслыгы йорты директоры Ирек Илдус улы ШӘРИПОВ белән язучы Рәдиф Сәгъди әңгәмәсе.

– Ирек әфәнде, Сезне утыз ел чамасы беләм. Ижау шәһәрендә гастрольдә еш була идек, соңыннан Татарстан Язучылар берлегендә эшләгәндә дә килгәләдем. Шулвакытта сез безнең турыда телевидениедә тапшырулар төшерергә дә, «Яңарыш» газетасына мәгълүмат бирергә дә өлгерә идегез. Ирек әфәнде, сезнең милләт хезмәтенә кереп китүегез кайчан һәм ничек башланды?

— Бу турыда үземнең дә уйланганым бар. Шуны күзәтәм: милли хәрәкәткә килгән кеше бервакытта да аның белән араны өзми. Мин 1987 елда Казан дәүләт университетына укырга кердем. Милли үзаңның күтәрелеп килә торган вакыты. Ирек мәйданында зур-зур халык җыеннары гөрли. Әлбәттә, без ул чакта яшь-яшь егетләр, студентлар идек… Ул вакыйгаларның әһәмиятен аңлый, аларның мөһим икәнен белә идек. Ике дистә елдан артык вакыт узуга карамастан, бүген дә халкыбыз даулаган гадел карашның нәтиҗәсен, бәрәкәтен күреп яшибез.

Ул елларда тарих Казанда, мәйданнарда гына язылмады. 1990 елларда төрле төбәкләрдә милли хәрәкәт бердәм күтәрелә башлады. Әмма анда эшләргә кешеләр җитми иде, чөнки дистә еллар туган тел өйрәнелмәде, газета, радио, телевидение юк, мәктәпләр, балалар бакчалары ябылган, мәчетләр күптән эшләми иде. Шулвакытта, журналистика факультеты студентлары арасыннан башка төбәкләргә китеп милли эшкә тотынучылар шактый булды. Мин үзем, мәсәлән, Рәмис Сафин белән Исхак Хәлимов исемле егетләребезнең Ульянга кайтып китүләренә кызыгып калдым. Берсе — татар газетасын ачарга, икенчесе татар телевидениесен оештырырга кереште.

Үзем — Әгерҗе төбәгеннән. Әгерҗе Ижау шәһәре белән дустанә мөнәсәбәттә яши. Ижауда туганнар, танышлар күп. Шул ук Рәмисләр Ульянга юл тоткан елны Ижауга практика үтәргә киттем. Мине удмурт радиосына рус телендә эшләүче хәбәрче итеп алдылар. Шул чордан андагы татар ансамбльләре, милли хәрәкәт, мәчет тирәсендә йөрүче кешеләр белән танышлыгым арта барды. Практиканы үткәч, кире Казанга

киттем. Яңа еллар тирәсендә Ижаудан танышларым шылтырата: татар телендә телевидение ачарга телибез, кайт әле монда, эшләр кешебез юк, диләр. Киңәшер өчен деканыбыз Флорит Әхмәт улы Әгъзамов янына кердем. Аңа ниятемне җиткердем. Һәм... егерме елдан артык тормышым Удмуртиядә узды. Аллага шөкер, гомернең иң матур чоры, дип атыйм аны.

Башлаган эшләрнең без киткәннән соң да сүрелмәве һәм таркалмавы — зур бәхет. Татар газетасы хәзер дә чыга, татар телендәге телевидение тапшырулары хәзер дә бар. Милли-мәдәни автономия уңышлы эшләп килә. Шуңа күрә болар бәрәкәтле юнәлешләр булганнардыр, дип уйлыйм. Аның иң югары нәтиҗәсе — мөстәкыйль рәвештә яшәүләре.

— Бу эшләр бит иң авыр заманда эшләнде. Тагы да югарырак үсеш әлегә күренми кебек?!

Сез Ижауда җиң сызганып хезмәт итә идегез. Хәзер Казанга кайттыгыз. Халыклар Дуслыгы йортын җитәклисез. Тарихи ватанга кайтуыгызга үкенмисезме?

— Һич юк. Шундый мөмкинлек биргәне өчен Ходайга рәхмәт. Удмуртиядә легендар шәхес, республиканың мөфтие Габдулла хәзрәт Мөхәммәтшин бар иде. Ул, кайчандыр заводта шофер булып эшләгән, вакыты җиткәч, Удмуртия мөселманнары аны Республиканың мөфтие итеп сайлады. Гадел мөфтият төзеп, эшне башлап җибәрде. Хәзрәт шундый фикер әйтә иде: «Без эшлибез, дип тәкәбберләнергә кирәкми! Ходай безгә эшләргә мөмкинлек бирә!» Миңа да Ходай үз вакытында Удмуртиядә һәм хәзер Казанда эшләргә мөмкинлек бирде.

Үземне татар милли хәрәкәтенең сафтагы вәкиле, дип саныйм, гәрчә бүген Халыклар Дуслыгы йортында

эшләсәм дә. Ни өчен? Чөнки татарның көче, гомумән, һәрбер кешенең көче — дуслар күп булуда. Бүгенге көндә Татарстан Республикасында яшәүче 170тән артык милләт татар халкына, Татарстан дәүләтенә хөрмәт белән карый икән, безнең үсешебезгә ярдәмче, аркадаш булып тора икән — бу безнең хезмәтнең дә нәтиҗәседер.

Без Халыклар Дуслыгы йортында татарга, Татарстанга карата хөрмәт тәрбиялибез. Башка милләт вәкилләренә Татарстанның, татарның кем икәнлеген аңлатып, аларны үзебезнең дустыбыз итәбез. Бу кешеләр белән бергә үзебезнең киләчәгебезне төзибез. Бу — Татарстан, татарлар, татар милли хәрәкәте өчен бик мөһим юнәлеш. Бер дәүләт эшлеклесе: сез дипломатия хезмәтендә, дигән иде. Чынлап та, без — татар халкының дипломатлары, чөнки татар халкы һәрвакыт башкалар белән дус яшәргә тиеш. Бу аңа үзен, үзенең үсешен тәэмин итәр өчен кирәк.

— Әлбәттә, үзеңне үрнәк итеп куйсаң гына матур яшәп була!

— Татарстан халыклары Ассамблеясында без аерым бер халык өчен өстен шартлар тудырмыйбыз. Без бары тик кайсыдыр халык кимсетелмәсен, дип эшлибез. Чөнки кемдер җәмгыятьтә кимсетелә икән, бу инде сәламәт җәмгыять түгел. Безнең эшебез, беренче чиратта, милләтләр арасында гаделлек булдырудан, кимсетелгән кешеләр булмавын искәртүдән гыйбарәт. Әгәр дә андый хәл бар икән, аны кичекмәстән төзәтү мөһим.

— Сез — ТР Дәүләт Советы депутаты. Татарның борчу-мәшәкатьләрен белгән ир-атның депутат булуы безне шатландыра. Шул ук вакытта Дәүләт Советында сезнең кебек милли җанлы, киң карашлы әйдәманнарның бик аз булы борчуга сала.

— Милли сәясәтне кем оештыра? Кем кора? Кем барлыкка китерә? Сайлаучылар белән очрашканда да һәрвакыт әйтәм: «Милли сәясәтне Президент оештыра, дип уйлыйсызмы? Юк! Хакимият башлыклары, дип уйлыйсызмы? Юк! Халыклар Дуслыгы йортымы? Юк! Аны сез үзегез — гаилә, гаиләләр, Аналар оештыра!»

Беренчедән, без бик нык кими барабыз. Татар мохите генә түгел, татарның саны да азая. Һәр районда затлы, менә дигән гаиләләр бар. Алар бер бала тәрбияли. Мин әйтәм: «Акчаң бар, өең бар, дәрәҗәң бар! Синдә тамак туйдыру кайгысы юк! Үстер, тәрбиялә балалар!» Милләтебезнең йөзен билгеләп торган затлы кешеләр саны кимеп бара. Белемсез, соры масса күп, ә затлылык кими.

Икенчедән, мохит бик тиз үзгәрә. Минем өч улым бар. Яшь аермалары сигезәр ел. Аларның үрнәгендә үзем дә күрәм: 16 ел эчендә мохит ничек үзгәрде. Олы улым Ижауда яшәгәндә татарча шигырьләр яза иде. Уртанчысы инде шигырьләр язмый, әмма урысча да, татарча да иркен сөйләшә. Кечкенәсе беренче сыйныфта укый. Әмма Камил укый торган чордагы мохит Инсаф укый торган чордагы мохиттән бик нык аерыла. Хәзерге заманда урысчага гына корылган интернет, матбугат, күңел ачу чаралары...

Мохит сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да үзгәрә. Ул татарлаша бармый. Күптән түгел генә Осиновода халык белән җыелыш уздырдык. Анда ике мәктәп бар. Элек берсе — урыс, икенчесе татар мәктәбе булган. Хәзер балалар саны 4-5 мәртәбә арткан, ике мәктәптә дә икешәр смена укыйлар. Ул балаларга нинди телдә белем бирергә, дигән сорау да тормый. Алар, бөтенесен бер калыпка салып, урысча укыталар, чөнки җитешмиләр. Казан каласында халык саны бик нык арта һәм алар татар мохитенә ихтыяҗлы булган кешеләр түгел. Шулай итеп татар мохите тарая.

Җәмгыятебездә читтән килгән кешеләрнең саны арта. Татарстан ел

саен 200 меңгә кадәр мигрант кабул итә. Алар эшләр өчен килә, әмма бер өлеше биредә төпләнеп кала. Актаныш районында 20 мең халык яши. Минзәләдә — 22 мең. Бу бит ун Актаныш, сигез Минзәлә килә, дигән сүз! Бик зур сан. Ул бит әле Актаныштагы, Минзәләдәге карт-коры, бала-чаганы исәпкә кертеп. Мигрантлар исә урта яшьтәге, гайрәте ташып торган кешеләр. Алар барысы да үзләренең милли үзаңнары белән килә. Берсе дә бирегә килеп татар, урыс булачакмын дип килми, милли үзаңнары бик көчле, үз менталитетлары бар һәм аннан баш тартырга җыенмыйлар. Менә шундый көчле кешеләр янында без йомшак күренәбез. Бу уйландырырга һәм безне җитди эшкә этәрергә тиеш. Кәеф төшереп утырырга дигән сүз түгел, хәрәкәт итәргә кирәклеккә бер дәлил.

Мигрантларның 90%тан артыгы — төрки халык. Шунысы куандыра: алар кардәш кавем булганлыктан, менталитетта, дөньяга карашта, телдә уртаклыклар бихисап. Әгәр дә 200 мең кеше бөтенләй башка дөнья кешесе булса, зур кыенлыклар килеп чыгар иде.

Мин татар халкының киләчәгенә оптимизм белән карыйм. Безнең халкыбыз зыялы, аның тамыры тирән, нигез-асылы черемәгән, сау-сәламәт.

Тагын шул шатландыра: төрки телле мигрантлар безне хөрмәт итеп килә. Бүгенге көндә базарда сәясәт үзгәрә. Сез агропаркка барыгыз: андагы үзбәкләр соңгы елларда татарчаны өйрәнде һәм татар белән татарча сөйләшә.

Күп очракта төрки телле мигрантлар бирегә килеп безне баета, безгә зыян китерми. Ассамблеябыздагы кайбер төрки оешма җитәкчеләренең хатыннары татар. Күреп торабыз: бүгенге көндә алар — татар гаиләләре, гәрчә әтиләре башка милләттән булса да.

— Без — затлы, башкаларга үрнәк халык. Ничек кенә булса да милләтебезне саклап каласы иде…

— Әүвәл милли сыйфатларыбызны, менталитетны саклау кирәк. Җәмгыять белемен өйрәнүче галимнәрнең бер формуласын укыганым бар: әгәр үз халкын

кайгыртырдай, тормышын шуңа багышлардай талантлы, энергияле 200 кешесе бар икән, ул милләт күтәрелә ала. Ә бездә андый кешеләр бар!

Татарстанда яшәү кызыклы. Бездә идеяле, энергияле, дәрт-дәрманы ташып торган шәхесләр бик күп. Удмуртия Республикасы — удмурт халкының тарихи ватаны. Әммә милләт чишмәсе саеккан. Мәдәният, Мәгариф, Милли сәясәт министрлыкларына милли кадрлар эзлиләр. Тапмыйлар! Милләт белемле, дәртле милли кадрларны тудырмаган. Бүгенге көндә бездә конкуренция бар: аңа шатланырга гына кирәк. Төрле урыннарда эшләр өчен яхшы, энергияле шәхесләр үзара көрәшә. Бу — яхшы көрәш, дип уйлыйм.

Нинди генә районда нинди генә хакимият башлыклары юк. Нәрсәләр генә уйлап тапмый, нәрсәләр генә эшләми алар. Мин районнардан сөенеп кайтам. Бу район җитәкчесе бик яхшы эшли дә сыман, аны алыштыралар, урынына килгәне тагын яңа нәрсәләр уйлап таба.

— Шундый җитәкчеләр бар: тәхеткә килү белән үз халкын танымый башлый, акчага табына, өстәге җитәкчеләр турында гына уйлый. Аларга синең газетаң да, журналың да кирәк түгел! Менә шундый тәкәббер адәмнәр хакимияттә утырмасын иде. Дөрес, бик әйбәт җитәкчеләр дә бар…

— Җитәкчеләрне, лидерларны, язучыларны халык үзе тәрбияли. Безгә башка милләт вәкилләре һәрвакыт әйтеп тора: милли сәясәт буенча бөтен өмет сездә — Татарстанда, диләр. Сез башлап җибәрегез, без кушылырбыз, диләр. Кимчелекләребезгә карамастан, Россиядәге милли сәясәтнең йөзен бүгенге көндә күп очракта Татарстан һәм татарлар билгели.

— Сез җитәкчелек иткән Дуслык йортында милләтләрнең бер-берсенә мөнәсәбәте ничек күренә?

— Тормыштан бер вакыйганы мисалга китерәсем килә. Ике ел элек Әрмәнстанда президент сайлаулары булды. Россия анда бер төркем күзәтүчеләр җибәрде, мин дә алар составында идем. Биш көн буе анда яшәп шуны күрдем: Әрмәнстан һәм Төркия, Әрмәнстан һәм Азәрбайҗан арасында коточкыч зур дошманлык бар. Бу халыклар тарихи дәверләрдә бер-берсенә шактый зур зыян салган. Күршең дошман булсын әле… Һәм бу дошманлык дәүләт җитәкчеләре дәрәҗәсендә генә түгел, хәтта кешеләр арасында да бар. Монысы тагын да куркынычрак. Әрмәнстаннан бик авыр хисләр белән кайттым. Әлеге халыклар беркайчан да дуслаша алмас кебек, ахыры нәрсә белән бетәр инде, дип борчылып кайттым.

Берзаман минем эш кабинетыма Ассамблеяның төрек оешмасы рәисе Йосыф Саглам белән әрмән оешмасы рәисе Михаил Хачатурян кочаклашып килеп керә. Мин аларга: «Егетләр, сез минем йөрәктән бик авыр хисне алдыгыз!» — дидем.

Билгеле бер мохиттә бу милләтләр дошман булырга мөмкин, ә мин шат: Татарстан Республикасында алар, ике илнең ике вәкиле, дус-тату, бер-берсенә карата бернинди дәгъвалары да юк. Татарстан аларны дуслаштыра.

— Ирек әфәнде, Сезнең борчулар — безнең борчулар. Татарстан киләчәктә дә башка милләтләр белән дус яшәр, дип уйлыйм, чөнки без гадел халык. Татар халкы кайда гына яшәсә дә башкаларның мәнфәгатенә аяк чалмый…

— Әйе, милләттәшләребез кайда гына яшәмәсен, беркайчан да үзләренә аерым, өстенлекле шартлар сорамый. Безгә гадел караш булса, шул җиткән. Гадел караш була икән, без хәзерге шартларда бик югары күтәрелергә сәләтле милләт. Моны һәр төбәктә күрергә мөмкин. Ә иң ачык мисалы — Татарстан үзе, әлбәттә. ■

ТУГАН ЙОРТ

мәдхия

Хәбир Ибраһим

Быел туган йортны яңарттык. Мәшәкәте күп булды: кәкре-бөкре калын идән такталарын кубарып, бер-берсенә кереп кенә утыра торганнарын җәйдек. Искеләрен сүткән чакта, идән астына күз салдым. Зал ягында – баз. Әти шунда агач яшникләр куеп, бакчадан җыйган алмаларны саклый торган иде. Аларның хуш исен әле дә онытасым юк! Иң гаҗәпсендергәне шул булды: идән астында, бер почмакта кечкенә генә уенчык машина аунап ята. Зур тизлек белән барган җиреннән, кинәт кенә һәлакәткә юлыкканмыни! Балачакта машиналар белән уйнарга ярата идем шул. Димәк, бу уенчык машина да инде ярты гасыр, әнә шулай әйләнгән хәлендә, идән астында караңгыда яткан...

Туган нигез

– Нигезең нык, абзый, — диде идән җәюче балта остасы, үзебезнең авыл егете, — черегән җире күренми...

— Минем гомергә җитәр әле! — дигән булдым мин.

Мин һәрчак: «Әле дә ярый әни исән!» — дип уйлап куям. Йортны, нигездә, аның өчен яңартабыз. Картайган көнендә яхшы өйдә яшәсен, мәңгелеккә күчкәндә дә халык: «Мул тормышта яшәгән икән бу карчык!» — дисеннәр...

Без — дүрт бала. Бишенчебез... тугач, өч айдан соң үлгән. Нидән үлгәнен беркем дә белми. Бик матур бала булган, күз тигән, диделәр. Барыбызны да берләштереп торган иң нечкә җеп, өзелергә тора. Әни ул турыда уйламый да, уйлыйсы да килми. Ул шушы тормышка ябышкан, шуңа береккән, аңа рәхәт монда.

Әнинең беркая да китәсе килми. Юкса, ветеран хатыны буларак, каладан фатир да бирделәр үзенә. Алып

бардык без аны анда, тугызынчы катка хәтле алып мендек, ләкин шул дәүләт биргән фатирында, көч-хәл белән ике сәгать кенә утыра алды. «Улым, алып кайт син мине, тотма монда, үлсәм, үз йортымда гына үлим!» — диде. Аңладым: авылдан гомер китәчәк түгел әни!

Туган йортын, туган ягын сагыну хисе генә түгел, монда үз-үзеңне саклау инстинкты да өстенлек итә, күрәсең. Гомер буе авылда яшәп, авыл суын эчеп үскән карт кешеләр, авылдан балалары янына китеп, калада яши башлауга ук, нигәдер, бик тиз сүнә. Таш кала аларны һәм, киресенчә, алар таш каланы кабул итә алмый — керсез җаннарына тынгы таба алмыйча, чәчәк кебек сулалар. Минем әни, Аллага шөкер, әлегә исән, сәламәтлегеннән башка бернигә дә зарланмый. Әнә ул, Ходай биргән гомеренә сөенә-сөенә, көн-төн плитә янында кайнаша. Бүген ул кыстыбый пешерә. Минем кыстыбый тышын яратканымны яхшы белә, көйгәнен бигрәк тә! Беренчесен, әллә ашыгып, әллә махсус көйдереп ала да: «Мә, улым, ашый тор, бусы көеп китте әле!» — дип шул кыстыбый тышын алдыма китереп куя. Мин исә сөенәсе урынга, нигәдер елыйм, әнидән күз яшьләремне яшереп, тын гына елыйм…

Әти кайчак: «Мин үлгәч кемгә калыр инде бу йорт, кем карар аны!?» — дия иде. «Миңа калыр, мин карармын!» — дигәч, ул: «Китчәле, мыхамур!» — дип кул гына селти иде. Ул, ялкаулыгы чиктән ашкан, бер күзе белән авылга карап сокланса, икенчесе белән кала ягына караган, мәхәббәт шигырьләре язып, Мәҗнүн исемен алырга йөргән шагыйрь малаена әллә ни зур ышаныч багламагандыр да, билгеле. Хәзерге йортыбыз әти яшәгән йорттан күпкә матуррак, әйбәтрәк булып күренсә дә, аны үткәнгесе белән чагыштырып булмый, әлбәттә.

Бу йортта һәрчак тормыш кайнап торды. Әти дә, әни дә — яшь. Без — балалар — барыбыз бергә. Күңелле чак. Бервакыт шау чәчәктә утырган шомырт янында җыйнаулашып фотога төштек. Әти, әни, ике апам, абый, Сәрвәр тәтә һәм мин. Йорт эчендә ремонт беткәч, мин шул фотоны түргә элеп куйдым. Әләрлек тә шул: яшь чак, матур чак! Ә мин — төпчек малай, бөтенләй сабый бала (башыма кәләпүш кидергәннәр!), нәүмиз генә шау чәчәккә баткан язгы бакчага карап утырам…

Йортның төп бурасын кайчандыр урыс авылыннан сатып алып кайтканнар. Өйнең тышкы ягын сайдинг белән төргәндә, иске такталарын, сүтәргә туры килде. Шуны сүткәндә дини китапларга тап булдык, алар бура белән такта арасына кыстырылган иде. Гарәпчә язылган бу борынгы китапларның саргайган кәгазь битләре кара тузанга баткан, бер күчкә оешып укмашкан иде. Система дини китапларны өнәмәде, алар ачыктан-ачык тыелмасалар да, аларны күздән ераграк тотарга туры килде.

Әтием кырыс холыклы булса да, алдынгы карашлы кеше иде. Беренче эш итеп ул өй каршында җәйге «кухня» салдырды. Җәй айларында өйгә кунарга гына керәбез, ә көндезен ашау-эчү шунда уза, өстәлдәге самавыр һәрчак кайнап тора. Телевизор антеннасы баганасын авылда да беренче булып әти куйдырды. Ул антеннаны түбә башына күтәреп куяр өчен ярты авыл кешесе җыйналды…

Мин — бәхетле кеше. Туган авылым, йортым, нигезем бар. Бу бәхет бөтен кешегә дә тәтеми. Әгәр дә әтием сугыштан исән кайтмаган булса, без дүрт бала бу дөньяга килмәгән дә булыр идек.

Кайчандыр нигезебезнең хуҗасы булып безнең бабай торган. Фамилиябез дә аның исеменнән килә. Эшчән, тырыш һәм шулай ук бик кырыс кеше булган, диләр аны. Ярлы яшәмәгән, элеккеге бәя белән банкта биш мең алтын акчасы булган. Ул аны ашлык һәм иген, алма сатып җыйган. Властька Керенский җитәкләгән вакытлы

хөкүмәт менеп утыргач, ул акчалар янган. Хәлле, әйбәт яшәгән кешеләрне совет заманында кулак итеп күргәннәр, әмма бабайны «кулак» дип гаепли алмаганнар. Акыллы һәм сак кеше булган, дип уйлыйм аның хакында. Патша заманында ничек хәлле яшәсә, колхоз чорында да югалып калмаган ул, мул яшәгән. Тирә-якны, табигатьне яраткан — йорт артында гына алма бакчасы, агачлык. Авылда аның исеме белән бер чишмә, бер күпер атамасы да булган…

Сугышны узган әти, нигәдер, авылына кайтырга ашыкмаган. Сугышка хәтле ул, Ферганә каналы төзегәннән соң, Әндиҗанда (Үзбәкстан) яшәгән, анда сәүдә эшендә йөргән, сугышны узгач, Әндиҗанга барып, бар булган байлыгын кире алып кайткан. Сәүдәгәр яһүд аны Әндиҗанда калырга, хәерче Рәсәйгә кайтмаска үгетләп караган, ләкин әти аны тыңламаган, берникадәр яшәгәннән соң, кабат туган җиренә әйләнеп кайткан. Сәбәбе: җирсү һәм әнисен сагыну.

Әтисен бөтенләй белми ул. Бабай Беренче Бөтендөнья сугышында һәлак була, шул сәбәпле әтинең әнисе өч яшь бала белән тол кала: ике кыз (әтинең апалары) һәм әти үзе. Әнисе өч бала белән Мөхәммәткәрим атлы бер авыл мужигына кияүгә чыга. Аңардан ул тагын бер кыз бала таба. Ул кыз бала да кияүгә чыгып, күп бала табарга өлгерә. Ләкин әбинең генә (әтинең әнисе) гомере артык озын булмый, ул, йөрәк ревматизмыннан чирләп, үлеп китә. Әтигә кабат авылдан китү мөмкинлеге ачыла. Ләкин ул китмичә кала. «Казанга китү мөмкинлеге бар иде, ләкин авылны ташлыйсым, бабам үстергән талларны калдырып китәсем килмәде. Кая гына китсәм дә, миңа рәнҗеп ятарлар төсле тоелды!» — дип аңлатты ул авылда калуын. Бер карасаң, нәрсә соң инде ул тал?! Талны аны хәзер агачка да санамыйлар, чүп үләненә тиңлиләр. Аңардан йорт та, бура да салып булмый, мунча миченә яксаң да, артык җылысы чыкмый. Тал агачы белән мунчаны җылытыр өчен, бер арба коры утын ягарга кирәк. Күрәсең, ул талны нинди дер төзү материалы итеп түгел, ә җан иясе рәвешендә күргән. Урман булып, таллар гына түгел, төрле-төрле агачлар үсә безнең бак-

ча артында: шомырттыр, карамадыр, юкәдер, өянкедер...

«Төрлесенең холкы төрлечә, һәркайсы белән аерым телдә сөйләшәм мин!» — дия торган иде әти.

Утыз яшен тутырган, сугыш афәтен кичергән фронтовик, ялгыз яшәүдән туеп, төп нигезгә әнине алып кайта. Әнине клубтан театр карап утырганда дәшеп чыгаралар. Сугыштан соң кызлар күп, җүнле ирләр, егетләр аз, әтигә бик күп кешене димләп карыйлар, ләкин әти инде бер генә кызга күз салган була. Туганнарына: «Алсам, Анияне генә алам, алмасам, беркемне дә алмыйм, авылдан китәм!» — дип үз таләбен куйган әти шул рәвешле әнигә өйләнә. Ләкин аларга төп нигезгә кайтып төпләнгәнче, авылдан авылга күченеп, берничә йорт алыштырырга туры килә. Бу йөрүләр әтинең эш урыны белән бәйле була. Шуңар күрә ике апам да, абыем да төрле җирдә туалар, бер мин генә шушы йортта туганмын. Бары тик әти үзенең туган колхозына рәис булып эшкә кайткач кына, безнең гаилә, ниһаять, бик озакка шушы нигездә төпләнеп кала...

Әти картаеп үлде. Туксан өч яшендә. Үләре алдыннан бер ике-өч ай элек әти: «Йортны сатып, акчасын банкка салып куярга кирәк!» — дип саташты. Үз гомерендә шактый күп тормыш нужалары күрүгә дә карамастан, бәхетле кеше, дип саныйм. Үләсен аңламыйча һәм белмичә китеп барды ул бу якты дөньядан...

Авыл йорты — ул үзе бер дөнья. Ул яңа гына дөньяга килгән бала өчен аягына басып, үсеп җиткәнче гаҗәеп сер булып кала. Ниндидер бер хикмәти сер — илаһи тарту көче бар авыл йортында!

Татар авылларының күбесе кечкенә инеш һәм чишмә тирәсендә урнашкан, шуңар күрә дә безнең урамнарыбыз «керәле-чыгалы», алар тигез бер яссылыкта урнашмаган. Инеш-елга кайсы якка акса, урамнарыбыз да шул тарафка таба үскән. Тартылып торган өчпочмакны хәтерләткән татар «хутыр»лары тар ягы белән урамга карап тора. Әйтерсең лә йортлар кеше күзеннән качырып салынган, биек коймалар артында яшеллек эчендә яшерелгән. Бездә җәй кыска, кыш шактый озын. Өй тәрәзәләре кояш ягына карап тора. Сәбәбе гади: кояш җылысы күбрәк керсә — өй һәрчак җылы торган...

Авылда алты почмаклы йортларга караганда дүрт почмаклылары күбрәк. Нарат бурадан салынган өй каршында чолан ясап куялар, өйгә кергәндә болдыр аркылы керәсең. Өйнең шулай ук түр ягы һәм чарлагы да бар. Җәен үстергән бәрәңгене салыр һәм саклар өчен, җир казып, идән асты ясап калдыралар. Без — балалар бик шаулагачкотырышкач, әни: «Бик шауламагыз, шауласагыз, идән астына ябып куям!» — дип куркыта торган иде. Ә ул идән асты безнең өчен, чынлап та, иң куркыныч һәм иң шомлы урыннарның берсе булып тоела иде. Әгәр дә олылар берәребезне, бәрәңге алырга дип, идән астына төшереп җибәрсә, без тын да алмыйча, куркышып, аның шуннан исән-имин менгәнен көтеп утыра идек. Өйдә тагын бер шундый куркыныч урын бар, ул мич артында ясалган кечкенә төнлек. Ул көндезен дә, кичен дә гел караңгы килеш тора, җилдавылда гүли, безнең уйлавыбызча, анда ниндидер куркыныч җеннәр, йортияләре йөри, аксак тәпиләре белән бертуктаусыз шыпырдашалар...

Йорт ияләре, дигәннән... Мин үзем андый «җан» ияләренең барлыгына бигүк ышанып бетмәсәм дә, нигәдер шуңар ышанасы да килә. Халык сөйләве буенча, һәрбер өйдә йорт иясе бар. Кем соң ул йорт иясе? Бармы ул? Булса, ни кыяфәтле ул? Идән астын яраткан, идән астында яшәп, төн урталарында чыгып, шыпыр-шыпыр, өй эчендә йөри торган мәхлукны бездә йорт иясе диләр. Йорт иясе төрле җенестә һәм төрле кыяфәттә булырга мөмкин. Төрле халыкта төрлечә, ягъ-

ни. Бездә аны Бабакай, диләр. Без аны кечкенә, карыш буйлы, озын ак сакаллы, ак чәчле, кеше сымак киенгән бер карт кеше итеп күз алдына китерәбез. Йорт иясе, билгеле ки, халык юравы буенча өйне төрле бәла-казалардан, афәтләрдән саклый. Ут казасы буласы булса, ул төне буе йокламыйча йөреп чыга, тыныч кына йоклап яткан кешеләрне аякларыннан тартып уята башлый, тавышлана…

Мин аның барлыгын сизәм. Бездә яшәвен, бездә булуын телим. Аны беркайчан да онытмыйм: шәһәргә китәр алдыннан ашарына нәрсә булса да куеп калдырам. Сакласын йортны! Йортның рухын, иминлеген сакласын!

Борын заманнарда авыл йортларында агач сәкедән һәм тимер казан куелган олы мичтән ары артык нәрсә булмаган, өй эче буш һәм иркен торган. Күрәсең, бу авыл халкының ярлылыгыннан һәм шулай ук аның тыйнаклыгыннан да киләдер.

Түр ягы — ир ягы булып саналган. Монда хатын-кызга урын табылмаган. Хатын-кыз күбрәк почмак якта яшәгән. Түр якта тәрәзәләр күп булу сәбәпле, монда почмак ягына караганда, шактый якты һәм иркен булган. Түр ягында күп вакытны йортның хуҗасы һәм аның олы яшьтәге ир балалары уздырган. Түр якның дәрәҗәсе башкаларга караганда югары булган, ул еш бизәлгән, һәрвакыт чиста, пөхтә торган, монда гаиләгә кагылышлы төрле кыйммәтле әйберләр саклаган. Өйгә килгән кадерле кунакны да иң элек түр ягына чакыра торган булганнар. Безнең түр як гомер буе әти белән әни бүлмәсе булды, ул якка без күп очракта әтидән рөхсәт сорап кына керә идек…

Татар йортының иң күркәм әйберсе булып мич саналган. Акшарланган апак мич. Мич йорт хуҗаларын ашаткан да, җылыткан да. Мичнең ничек салынуына, аның кайсы якка авышуына карап, бүлмәләрнең торышы да үзгәргән. Элеккеге авыл мичләренә хәзер инде ясин чыгарга гына калды, авыл җиренә зәңгәр ягулык, ягъни газ килеп керү белән аларны заманча ясалган тимер мичләр алыштырды. Өйдә ак мичкә урын калмады, аның дәрәҗәсе төште һәм хәҗәте дә калмады. Утын-күмер, паровой белән ягу бетте, хәзер кая да шул газ! Газ гына бетмәсен инде! Газ бетсә, элеккеге ак мичләр кабат исебезгә килеп төшәчәк бит!

Авыл миче безнең өчен бер зур җан иясе булып тоела иде. Мичнең, әгәр дә игътибар итсәк, башы да, йөзе дә, авызы да, хәтта кашы да (мич сыры) бар. Кыскасы, кеше кебек ул — алды да, арты да үз урынында. Мичнең аның кеше кебек үк җаны да бар. Тартмаган мич авыру карчыкны хәтерләтә, ул авыр яна, кире тартып, өйгә төтен кертә, андый мичнең морҗасыннан кара сыек төтен генә пыскып тора. Аның җылысы да, бәрәкәте дә юк. Яхшы мич (аны таза ир-ат дип уйлыйк!), гөрләп-шаулап яна, мичкә салган утыннары да шыртлап-шартлап, очкыннар атып яна. Андый мич янында җылы да, күңелле дә, — тәнгә сихәт, җанга рухи көч иңә…

Мич торган урында кечкенә генә аралык кала — аны йә чәчәкле чаршау, йә бүлмә тактасы белән бүлеп куялар. Бездә аны почмак як дип атыйлар. Шул якта әни, йә кызкыркын (апалар) ашарга әзерли. Тик мичне сүткәч, йортны зурайтып, аш ягын аерым бер бүлмә итеп ясаткач, шул почмак ягы да юкка чыкты, ул гади бер йокы бүлмәсе генә булып калды. Өй миче хикмәтле нәрсә ул. Гел хезмәттә — җәен дә, кышын да. Мичтә пешкән ипинең тәмлелеген хәзергеләр белмиләрдер шул һәм, мөгаен, белмәсләр дә. Ходайның рәхмәте, безнең буынга андый бәхет татыды! Әнинең олы мичне тергезүе безнең өчен бер бәйрәм була торган иде. Безнең мичтә пешкән азыкны яратуыбызны белә — иртән таңнан, шыпыр-шыпыр килеп, әкрен генә камыр изә башлый. Камыр ризыкларының

пешкәнен көтә-көтә түземлегебез бетә, шуңар күрә пешә барганын әкренләп «әрли» барабыз. Әни түгел, ә табигать-Ана үз куллары белән үзе әзерли кебек тоела иде безгә…

Салкын көннәрдә мич өйне җылыта. Өйдәге мичне һич кенә дә суытырга ярамый, иртә-кич кабызып, җылытып торабыз. Әле мин түр якта «голланкалар» (голланд миче) торганын да хәтерлим. Калын кара калай белән уратылып алынган ул түгәрәк мичнең өйне ничек җылытканын хәтерләмәсәм дә, аның шул сурәте хәтергә сеңеп калган. «Галанка»ларны күп очракта ризык пешерер өчен түгел, ә өйне җылытыр өчен генә кулланганнар. Ә чын авыл мичендә бар нәрсәне дә әзерләгәннәр, хәтта чуен казан куеп, терлекләргә боламык та пешергәннәр. Бәрәңге боламыгы, мичтә пешкән хуш исле ипи дә, кабартма да, юка да түгел, билгеле, аның яман исеннән котылыр өчен, чолан ишеген ачып, өйне шактый озак җилләтергә туры килә иде…

Мичне, билгеле ки, бер татар гына түгел, ә башка халыклар да кулланган. Ләкин татар өйләре җылырак булган, чөнки мичнең бер генә ягы (арты дип әйтик!) диварга орынып торган. Мич өйне җылытып кына калмаган, ул хәтта кешене дә дәвалаган. Әниебез (гомере буе чирләде) салкын тидерә калса, йә әти белән ачуланышса, җылы мич башына менеп китә дә, шуннан берәр көн төшмичә ята. Ходайның хикмәте, берзаман әнкәй терелеп төшә (җылы мичнең сихәте бар, күрәсең!), соңыннан өйдә дә, гаиләдә дә тынычлык урнаша…

Әйе, безнең балачагыбыз шундый ук ак мич тирәсендә узды. Югарыдарак мич сыры дигән нәрсә бара, без шуңар бар булган уенчыкларыбызны, китап-дәфтәрләребезне тезеп куя идек. Мич ягу гел безнең өстә булды, иртән-кичен киртәдән утын ташып, мич яктык. Соңрак күмергә күчтек, ләкин күмергә күчсәк тә, мичне һаман да вак утын белән элдерергә мәҗбүр идек. Мич морҗасы җилле-давыллы көннәрдә куркыныч авазлар чыгарып, шаулап тора. Әнә шулай мич морҗасы улаганын тыңлый-тыңлый безнең күбебез шагыйрь һәм язучы булып бетте дә инде. Кызганыч, ул ак мичләр хәзер тарихта гына калып бара. Андый мичләрне өюче осталар да юк дәрәҗәсендә, хәзер андый мич сала башласаң, авылда оста табалмыйсың. Чөнки теләсә кемнең кулыннан килә торган эш түгел ул, аның үз нечкәлекләре, серләре бар — ялтыратып өеп куйган мичең тартмаска да мөмкин…

Бу йорт — әти йорты. Әни — килен, ул — килгән кеше. Килсә дә, килмешәк түгел. Чөнки әниебез кебек әлеге йортка береккән, аны чын мәгънәсендә яраткан кеше арабызда булдымы икән!? Унөч яшеннән бригадир йөген тарткан, сугыш чорындагы ач һәм ялангач тормышның бар ачысын, бар авырлыгын үз җилкәсендә татырга өлгергән яшь кыз, сугыштан кайткан әтигә кияүгә чыкканнан соң, шушы нигезгә килен булып төшкән. Әни: «Мине клубта театр караган җирдән Сафиулла бабаң дәшеп чыгарды, әле мин кияүгә чыгарга теләми идем, бригадир эшеннән туйдым, шуңа кияүгә чыктым!» — дип сөйли иде. Әти үз чиратында: «Ишегалдында эт өреп тора, әниегезнең өстенә сикерә, ә ул шул этне атлап чыгып, өйгә кереп китте!» — дип шаяртырга ярата иде, әнинең шулхәтле кияүгә чыгарга теләвенә ишарә ясап…

Безнең әни — гади кеше, гади бер авыл хатыны. Хәер, җиде класс белеме бар, үзенә кирәген укый-яза белә. Безнең йорт кебек үк гади һәм тыйнак кеше ул. Татар йортлары тарихына багышланган юка гына китапның төсле фотосурәтләренә күз салып утырам. Фотосурәтләрдә — агач сәке, сәндерә, сандык, чаршау, кашага, намазлык, шамаиль, бирнә букчасы, чиккән сөлге,

тастымал, комган, палас, тал бишек һәм башка нәрсәләр. Мин яшәгән йортта боларның кайберләре әле булгаласа да, аларның күбесе хәзерге заман тормышы өчен хәҗәтсез нәрсә булып калды. Аларның күбесе заман сынауларын үтә алмады, ягъни үзләрен саклап кала алмады. Хәзер инде беркем дә өй түшәменә кашага сузып куймый, сөлге чигеп тә маташмый. Минем әни, сүз дә юк, заман белән бергә атлый алмады, яңа тормышны, яңа буынны аңламады, ләкин тормыштан төшеп тә калмады. Нинди генә авырлык килсә дә, дөньяны аңлый алмыйча интексә дә ул һәрвакыт шушы йортка ышыкланды. Ул аны җирдән-яңгырдан гына түгел, ә рухи көчсезлектән дә саклады. Әйе, йорты, авылы, иле булган кеше беркайчан да тормыш авырлыкларыннан сыгылып төшми, Ил-йорт аны саклый.

Ятим калды синсез, әни, дөнья… Әнине югалткач, мин озак кына денгә керә алмыйча интектем. Ни җүнләп язалмадым, ни яшәмәдем. Кул китте. Әйтерсең әни үзе белән тормышымны да, илһамымны да алып китте. Ярты елдан артык вакыт узгач кына әзрәк денгә кереп, кабат тормышка кайттым. Тик һаман да юксынам үзен, өйгә кайтам да, әнине сагынып, елап утырам. Әтине югалтуны артык авыр кичермәдем, ә менә әнинең китүен шактый авыр кичердем, үземне комлы сайлыкка кереп баткан кораб каршында басып калгандай хис иттем. Әни яткан диван каршында гына чәчәк сурәте төшерелгән бер пар зәңгәр башмак торып калган, әнинең башмаклары. Менә ул хәзер ухылдап урыныннан күтәрелер дә, шул башмак эчләренә кан тамырлары чәрдәкләнгән аксыл аякларын тыгып, бүлмә буйлап атлап китәр кебек. Мин аңар: «Әни, кайттыңмы?» — диярмен, ә ул җавабында: «Кайттым, улым, әйдә, утыр, чәй куйыйк!» — дип эндәшер сымак. Мин ул башмакларны шундук күздән югалттым, түзәрлек түгел чөнки, күзгә яшь килеп өелә…

Ата-бабамнан мирас булып калган туган йортыма мәдхия язармын дип йөрдем. Туган йортка мәдхия укымыйча мөмкинме соң! Ләкин күп очракта (ташландык нигезләрне күреп) җаныма һаман да сыкранырга гына кала: «Әй… нигез, туган нигез! Мине иркәләп үстергән, бишеккә салып тирбәткән, шушы якты дөньяга күзем ачкан, күңелемдә мәхәббәт хисләрен уяткан, туган нигезем, ни булды сиңа? Нишләп соң барысы да сине ташлый, синнән кача? Капка-ишегеңне тауда чана шуып кайткан сабый балалар, көянтә-чиләк күтәреп, чишмә суы ташучы апалар, кызлар түгел, ә җилләр, әче җилләр генә каерып ача.

Туган йортым, туган нигезем! Мин бит синең балаң, кадерле, сөекле балаң. Минем синдә каласым, синең кочагыңда иркәләнәсем, сиңа сыенасым, синдә яшәп, гомер итәсем килә. Үз сүземә тугры була алырмынмы, үз-үземә хыянәт итмәммe, ачы язмыш җилләре мине синең җылы куеныңнан тартып алганда, синең түр ягыңда яисә бусагаңда булса да басып кала алырмынмы?! Анысы Ходай иркендә! Бәхет-шатлыкларым синдә артса, кайгы-газапларым синдә кимесә һәм соңгы сулышым да синдә өзелсә, мин ничек бәхетле булыр идем! Җилдавыллардан, тормыш гарасатларыннан исән-имин чыккан, хәзергә тиклем имәндәй нык торган газиз туган йортым, туган нигезем, инде мин сине югалтырмын кебек. Тик мин шуны беләм: мин сиңа кайтачакмын, ышан, барыбер бер әйләнеп кайтачакмын, үзем булмасам да, рухым бер әйләнеп кайтыр, дип өметләнәм…»

P.S. *Төн. Авылга кайтып киләм. Күрәм — өйдә ут яна. Күңелемдә: «Әни!» — дигән күңелле уй йөгерә. Ялгышамын — соңгы мәртәбә авылдан киткәндә әни ягындагы утны сүндерергә онытканмын…* ■

ГЫЙЛЕМ ИЯЛӘРЕ ИЛЛӘРНЕ ҺӘМ ДӘВЕРЛӘРНЕ ГИЗӘ

Айзирәк Гәрәева

Мәгълүм булганча, Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте һәр елны аерым бер темага багышлап уздыруны күркәм гадәткә кертеп җибәрде. Узган 2015 ел «Татар дин галимнәре елы» дип игълан ителде һәм шул уңайдан танылган дин әһелләре яшәгән районнарга сәфәрләр оештырылды, имамнар рухына дога кылынды.

БУБЫЙЛАР ТӨБӘГЕ КАДЕРЛӘҮГӘ ЛАЕК

Әгерҗе — Казаннан ерак урнашкан районнарның берсе. Шуңа күрә дә бу якларга сәфәребез төнлә башланды һәм таң атканда инде без бай тарихлы төбәккә аяк бастык. 25 июньдә Әгерҗенең «Нур» мәчетендә халык җыены уздырылды, максатыбыз шул чарада катнашу иде. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә Казан һәм төрле районнардан килгән имамнар иң әүвәл Иж-Бубый авылында булды.

Татар халкы тарихыннан хәбәрдарлар Иж-Бубыйлар мәдрәсәсе, гомумән Бубыйларның кем булуы хакында һичьюгы берничә сүз әйтеп бирә алыр. Шулай да кыскача гына кабат искә төшереп үтү дә артык булмас. Тарихи чыганаклардан мәгълүм булганча, Иж-Бубый авылындагы мәдрәсә 1781 елда эшли башлаган. XIX гасыр ахырында бертуган мәгърифәтче Гобәйдулла һәм Габдулла Бубыйлар әлеге уку йортында реформа ясаган. Мөхлисә Бубый исә хатын-кызлар мәдрәсәсен оештырып җибәрә. Иж-Бубый мәдрәсәсе 1911 елның гыйнварында ябылган, аның мөгаллимнәре эзәрлекләүгә дучар ителгән.

XIX гасыр архитектура ядкяре — Габдулла бай Гобәйдуллинның кунак өендә Бубыйлар тормышын чагылдырган тарихи экспонатлар, төрле елларга нисбәтле гарәби кулъязма һәм басма китаплар бар. Хәзерге вакытта бу бина авыл мәчете дә булып тора.

Кунаклар, мәчет намазын укып алгач та, түр якта урнашкан тарихи ядкярләр белән таныштты. Имамнар авыл кешеләренең туган яклары хакында горурланып сөйләгәннәрен тын гына тыңлап утырды… Өч бертуган Бубый гаиләләре белән яшәгән ике катлы торак йортта ремонт эшләре бару сәбәпле, экспонатларны биредә кадерләп саклыйлар икән. Алга таба ниятләре — зур, заманча музей оештыру. Бу хакта «Бертуган Бубыйлар» иҗтимагый оешмасы директоры Раиф Гәрәев бәян итте.

Шуннан соң Бубыйлар яшәгән торак йортны карадык. Мөхлисә Бубый укыткан кызлар мәдрәсәсе шул йорт каршында булган икән, әмма ул юкка чыккан.

Чистайда кульъязма һәм басма китаплар белән танышу

Хәйрияче Мөхәммәдҗан Әхмәтҗан улы 1895 елда салдырган җамигъ мәчетенең матурлыгына, баскычларының һәм агач ишекләренең ныклыгына сокланып эчкә уздык. Биредә дә төзекләндерү эшләре бара икән. Алай да хәзрәтләр тарихи мәчетнең таушалган идәненә келәм җәеп намазга басты, дога кылды. Җил-давылларга бирешмәгән борынгы дивар эчендә дога яңгырады: *«Динебезне, милләтебезне саклаган, тәрбия кылган, рухыбыз сагында торган бабаларыбызның урыннарын җәннәт түрләреннән итсәң иде... Мәгърифәт нурын тараткан Габдулла, Гобәйдулла, Мөхлисә һәм башка мөгаллим-мөгаллимәләрнең, бик күпләргә ярдәм кулы сузган, шушы мәчетне төзеткән Мөхәммәдҗан Әхмәтҗан улы рухларын шатландырсаң иде... Кылган догаларыбыз аларның рух-шәрифләренә барып җитсә иде...»*

Җамигъ мәчеттә төзекләндерү эшләре өлешчә башкарылган. Әйтик, түбәсе, тәрәзәләре алыштырылган. 2007 елда — манара, 2014 елда яңа ай куелган. Бу эшләрне авыл аксакалы, 85 яшьлек Җәүдәт абый Хәлиуллин башлап йөргән.

Биредә яшәүчеләр теләгәнчә, Иж-Бубый авылына музей-комплекс дәрәҗәсенә күтәрелергә һәм рухи мирас буларак ныграк кадерләнергә язсын.

ЧИСТАВИ ВАТАНЫ

Совет заманында Дагыстанның дин әһелләре, мөселманнары ни өчен Татарстанга килеп йөргән соң? Әлбәттә, Әбү Габдерахман Мөхәммәдзакир бине Габделваһһаб әл-Чиставиның (Саснави) каберен зиярат кылып йөргән алар. Олуг татар ишанын безнең дин әһелләре дә зурлый хәзер. Чистай районына сәфәребез чираттагы «Чистави укулары»нда катнашу, шәех рухына дога кылу, каберен зиярат итү нияте белән оештырылды. Моннан тыш быелгы укуларда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Чиставиның «Хузур» нәшрият йорты тарафыннан татар, урыс, гарәп телләрендә бастырылган «Мөршидләрнең фикерләүләре» китабы тәкъдим ителде.

Гарәп телендәге бу хезмәтнең ике басмасы мәгълүм. Аның берсе 1890 елда татар дин галиме Галимҗан Баруди тарафыннан нәшер ителгән. Икенчесе — шәех әл-Багини басмасы. Камил хәзрәт Сәмигуллинга Дагыстан мөфтие

урынбасары Әхмәд хаҗи Мөхәммәдов менә шул басманы бүләк итеп биргән дә инде. Шулай итеп китапның дагыстанлылар саклаган нөсхәсе узган ел Чиставиның ватанында да үз укучыларын тапты.

Китап керешендә түбәндәге мәгълүматлар бар: *«Мөхәммәдзакир Казан губернасының Чистай шәһәре мәчетендә ярты гасырга якын имам-хатыйп вазифасын үтәгән. Ул шунда «Кәмалия» мәдрәсәсен тәэмин иткән. Россиянең төрле өлкәләреннән һәм губерналарыннан ислам дине гыйлемен алырга килгән йөзләрчә яшьләргә тормыш итүгә юл күрсәткән. XIX гасырның 80 нче еллары ахырында «Кәмалия»дә якынча 400 шәкерт белем алган. Алар укырга Чистай өязеннән генә түгел, Казан, Уфа, Самара һәм башка җирләрдән дә килгәннәр. Р.Фәхреддин, Ф.Кәрими, Г.Гафуров-Чыгтай, Х.Фәйзи-Чистапули кебек мәшһүр кешеләр әлеге мәдрәсәдә белем алганнар. 1882 елда шәех үз акчасына тагын бер мәчет салдыра. Шулай итеп, ул халкыбыз күңелендә мәгърифәтче, галим буларак кына түгел, юмарт мөселман булып та истә калган».*

Чистави укуларында катнашкан дин әһелләре, татар галимнәре, мәхәллә халкы татар шәехе Мөхәммәдзакир Камалов-Чистави 1846-1893 елларда имамлык иткән «Нур» мәчетендә дә булды. Бу мәчет совет хакимияте елларында да ябылмаган. Иске гарәби язулы китаплардан тыш биредә Чистави чорыннан калган борынгы агач мөнбәр дә саклана. Август аенда ошбу тарихи мәчеттә төзекләндерү эшләре бара иде. Шулай ук аның тирәсендә һәм 1990 елда салынган мәдрәсә ишегалдында балалар өчен махсус спорт мәйданчыгы булдырылган.

Берничә айдан соң бу мәчеттә кабат булырга туры килде. Аллага шөкер, биредә төзекләндерү эшләренең нәтиҗәсе күзгә күренеп тора: мәчет тагын да күркәмләнеп, яктырып киткән. 2017 елда Закир хәзрәт 47 ел имам булган мәчетнең 200 еллыгы үткәреләчәк.

МӘРҖАНИ КАБЕРЕ ЯНЫНДА ЕЛАДЫ...

Республикабыз мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин КФУның Көнчыгышны өйрәнү институты студентларына татар дин галимнәре турында сөйләде. Сүзен ул болай башлады: *«Гарәпләр Коръән Хиҗазда иңгән, Истанбулда матур итеп язылган, Каһирәдә гүзәл итеп укылган, Казанда беренче мәртәбә басылган, диләр. Дөрстән дә, 1803 елда нәшер ителгән басма Коръән — «Казан басмасы» белән безнең бабайлар ислам тарихына кергәннәр. Фикъһ — ислам хокукы мәсьәләсенә кагылышлы гарәп китапларында намаз вакыты турында сүз барганда «Болгар шәһәрләрендәге кебек» дип чагыштырулар китерелә. Ягъни, безнең җирлеккә хас үзенчәлек — җәй көннәрендә шәфәкъ кызыллыгы бетмәү искә алына. Ә инде төрле илләрдә киң таралган татар дин галимнәре хезмәтләренә килсәк, аларны бик күп санарга мөмкин булыр иде. Ул хезмәтләрне элеккеге заманнарда да өйрәнгәннәр, хәзерге дөньякүләм танылган ислам уку йортларында да укыталар. Әйтик, без Төркиядә дини гыйлем алганда, «Карабаш тәҗвиде»н һәм татар имамнары язган классик дини китаплар буенча укыдык. Габдрахман Карабашның «Карабаш тәҗвиде» китабы барча төрки халыкка Коръәнне укырга өйрәнергә булышкан рухи мирас».*

Чит илләрдә безнең кайбер татар дин галимнәрен башка ил галиме дип беләләр икән. Хәзрәт бу хакта искәртеп, үзе шаһит булган вакыйганы сөйләде: *«Казанга Әл-Әзһәр халыкара университетының Фәләстыйн бүлеге җитәкчесе, шәех Исмәгыйль Бүлбүл килгән иде. Ул безгә күп еллар дәвамында бөек Әфган галиме Мәрҗанинең 3 томлык китапларын шәкертләренә өйрәтүе хакында сөйләде. «Әфган галиме» дип әйтүе күңелгә тиде һәм кунакны Мәрҗани мәчетенә, йортына, татар зиратына алып бардык. Ул Мәрҗанинең кабере*

Мөхәммәдзакир Камалов-Чистави 1846-1893 елларда имамлык иткән «Нур» мәчете

янында, галимне олылап, елый-елый үзенең шигырьләрен укыды. Бөек галим каберен зиярәт кылу аңар шулкадәр нык тәэсир итте ки, шунда әйтте: «Әгәр дә остазым Мәрҗани кабере янына җирләсәгез, мин Казанга эшләргә килер идем…»

Шулай ук мөфти хәзрәтләре чит илләрдән алып кайткан китаплар белән дә таныштырды: *«Гарәбстанга сәфәр кылганда галим Салих Мәһди әс-Самараи белән күрешергә насыйп булды. Ул минем Татарстаннан икәнне белгәч ике томлык гарәпчә китабын бүләк итте. Бу китап Япониягә ислам китергән татар имамы Габдеррәшид Ибраһимов турында. Ул иске татар теленнән гарәпчәгә тәрҗемә ителгән булган. Әлеге татар имамы дөнья буйлап йөргән һәм исламга дәгъватлаган. Нәкъ менә аның башлангычында Япониядә беренче мәчет төзелгән».*

Дин галиме, тәрҗемәче Шәйхелислам Хәмидинең «Әл-иткан фи тәрҗемәтел Коръән» дигән ике томлык Коръән тәфсире булуы мәгълүм. Хәмидигә хөрмәт йөзеннән, Тукайны аның янына күмгәннәр, дигән фикер дә бар. Ләкин совет чорында Шәйхелислам Хәмидинең кабере юкка чыккан. Сарман районы Яхшыбай авылында Коръәнне татар теленә тәрҗемә кылган Шәйхелислам Әсәдулла улы Хәмиди эшләгән борынгы мәчет бинасы саклана.

Камил хәзрәт Бәйрутта Мөхәммәдморад Рәмзинең «Тәлфыйк әл-әхбар вә тәлкыйх әл-әсар фи вакаигъ Казан вә Болгар вә мөлүк әт-татар» китабының бер нөсхәсен табуы хакында да сөйләде. Иске Әлмәт авылыннан булган Рәмзи хәзрәт Мәккәдә гарәп шәкертләренә гыйлем биргән. Галимнәребез хакындагы китабын шунда яшәгәндә яза. Белгәнебезчә, Ризаэддин Фәхреддиновның да моңа охшаш хезмәте бар, ул «Асар» дип атала. Татар дин галимнәренең тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында язылган әлеге саллы китапларны укып та без бабаларыбызның ни дәрәҗәдә укымышлы, гыйлемле кешеләр булганын аңлый алабыз. ■

ГАИЛӘ ДӘРЕСЛӘРЕ

Фәхрелбәнат Сөләймания[1]

БЕЛЕК (БЕЛЕМ)

Балалар тәрбиясе гомуми тәрбиянең нигезе булганлыктан, «хатыннарның тәрбиясе камил булган кавемнәр алга китәр» дигән кагыйдәне һич тартышмый кабул итмәк һәрбер хаклыкны белүчеләрнең бурычлары җөмләсеннәндер. Әгәр дә без шушы рәвештә кызларыбызга гыйлем вә һөнәр өйрәтүгә каршы торуыбызда дәвам итсәк, башка укымаган милләтләр кеби без дә тиздән бетәчәкбез.

Фикер белек нуры берлә нурланмаса, адәм наданлык караңгылыгында калыр. Тәрбияи фикрияләре[2] камил булмаганнарның тән вә дин тәрбияләре дә яхшы булмас. Чөнки гыйлем вә мәгърифәт тәрбияи фикрия ияләрендә генә булып, тәрбияи фикрияләре булмаган адәмнәр үзләренең дөнья вә ахирәт эшләрен эшләүдә ялгышып кимчелекләргә төшәрләр.

Рух гыйлем вә мәгърифәт берлә камилләнер. Хәтта гыйлем вә мәгърифәт үзе хәят [тормыш] дип әйтергә дә мөмкин. Инсаннарның кадере мәгариф берләдер.

Гыйлем вә мәгърифәттән һичбер зарар күренгәне юктыр. Аны яхшы өйрәнмәк — һөнәрдер. Дөньяда никадәр явызлык булса, һәрберсе наданлыктан


فخر البنات سليمانيه

عائله درسلرى

قزلر مكتبى اوچون

ناشرى : محمد فاتح صكالوف .

مطبعهٔ كريميه قزان .
١٩١٣

КАЗАНЬ
Лито-Типографія Т. Д. „Бр. Каримовы".
1913.

туар. Иң зур һәлаклек чокыры — наданлык вә адәмлекне бетерүче дә наданлыктыр.

Күркәм гыйлем алган, холкын төзәткән бер хатын, әлбәттә, һәр җирдә хөрмәтләнергә тиештер. **Матурлык — узып китә торган бер зиннәттер. Мәгърифәт адәмнең үзе берлә бергә яшәр.** Фикерен наданлык шомлыгыннан пакьләгәннәр намусын, гыйффәтен, хатынлыгының кадерен, шөбһәсез,

---

[1] Фахрелбәнат Сөләймания. Гаилә дәресләре: кызлар мәктәбе өчен / Нашире: Мөхәммәдфатих Скалов. — Казан: Матбагаи Кәримия, 1913. — Күренекле мәгърифәтче, мөгаллимә, «Сөембикә», «Дин вә мәгыйшәт» журналларының актив язучысы Фәхрелбанат ханымның бу китабын журналга кыскартып тәкъдим итәбез. Китапның һәр бүлеге кыз балаларга аерым дәрес итеп язылган.
[2] Тәрбияи фикрия — фикер, аң тәрбиясе.

бөтен мәгънәсе берлә белер. Белекле адәм һичбер нәрсәдә алданмас. Надан хатыннарның балаларына бирәчәк тәрбияләре дә кимчелекле вә төпсез булыр.

Адәмлек өчен кирәкле булган намус, гыйффәт, оят кеби фазыйләтләрне иң башлап тудыручы — гыйлем вә мәгърифәттер. Бәхетеңнең дә, рәхәтлегеңнең дә, байлыгыңның да нигезе, төбе — гыйлем вә мәгърифәттер. Галим вә камил булганнарның дәрәҗәләре бик зурдыр. «Гыйлем мәртәбәсе — мәртәбәләрнең иң олугысы» дигән сүз — бик тугры бер сүздер. Кайсы җирдә гыйлем вә мәгърифәт булса, ул җирдә бар бәхет, дәүләт оясыдыр. Кайсы җирдә наданлык урынлашкан булса, ул җир — бер файдасыз коры вә ташлык җирдер. Күркәм холыклар берлә бергә булган гыйлем адәмнәрне бәхетле итәр, тергезер вә югары дәрәҗәгә күтәрер. Кабахәт эшләргә сәбәп булган белекләр һәр җирдә, һәр диндә гаептер. Гыйлемнән максуд — күркәм эшләр вә изге гамәлләрдер. Шуның өчен белгәннәр белгәне берлә гамәл кылмак тиешледер.

Һәр хатынга үзенә кирәкле булган гыйлем вә һөнәрләр берлә бергә кул эшләрен вә йорт эшләрен үгрәнергә вә белергә тырышмак лязимдер.

Мөхтәрәм туташлар! Ничек тә адәм булырга тырышыйк, укып күркәм холыкларга, изге гамәлләргә якын булган мәгарифне өйрәнеп, ике дөньяда да бәхетле булыйк.

ГЫЙФФӘТ

Гыйффәт — адәмнең нәфес теләгенә ияреп начар эшләргә катышудан үзен саклавыннан гыйбарәт булган бер гүзәл эштер. Намусын, кадерен вә бөтен мәртәбәсен саклап, начар вә кабахәт эшләрдән, гаеп булган эшләрнең һәрберсеннән качып, адәмлек өчен лязим булган тугры юлга кергән адәмнәргә гафиф яисә гыйффәтле диярләр. Гыйффәт — бер мәгънәви җәүһәрдер ки, адәмнәрнең төп кадер вә кыйммәте моның берлә үлчәнер. Хатыннарның үзләренә махсус булган иң гүзәл, иң кадерле зиннәтләре — гыйффәттер. Гыйффәтсез хатын — нурсыз, пычрак, җирәнгеч бер гәүдәдер. Гыйффәтләрен сакларга тырышмаган хатыннар һичбер вакытта мәхәббәт вә илтифатка[3] лаек була алмаслар. Ханымлык мондый хатыннардан еракты р. Гыйффәтсез хатыннар адәмнәр җәмгыятенең кадерсез, җирәнгеч, ким-хур булган берәр кисәге булып, начарлык берлә хөкем ителмештерләр. Аларга вөҗдан — ләгънәт, дөнья тарлык итәр, Җәнабе Хак та җәза бирер.

Гыйффәтенә кимчелек китергән бер хатын үзендә бетерү мөмкин булмаган бер тап ясаган булып, гөнаһ вә кайгыга төшкән булыр.

Ханым вә кызлар! Сезнең өчен иң зур байлык, иң зур мәртәбә, иң камил фазыйләт — гыйффәттер. Гыйффәтле бер хатын фәкыйрь булса да, мәгънәви кыйммәте бик югарыдыр. Гыйффәтсез булганнар, никадәр бай булсалар да, карамакта янә фәкыйрь вә кадерсездерләр.

Муеннарыгызга таккан алтыннарыгыз, башларыгызга, күкрәкләрегезгә кадаган бриллиантларыгыз, хәтта касса тулы акчаларыгыз берлә дә гыйффәтне сатып алу мөмкин түгелдер. Гыйффәт — бер зур байлыктыр ки, аның бәһасен чикләмәк һич мөмкин түгелдер. **Хатыннар матурлык вә сылулыкларына, байлык вә малларына түгел, гыйффәтләренә куанырга тиештер.**

***

Гыйффәтнең тәмам нәрсә икәнен аңлар өчен, аннан туган фазыйләтләрне белмәк лязимдер. Хәкимнәрнең әйтүләренә караганда гыйффәттән унбер фазыйләт туар ки, алар да түбәндә күрсәтелмешләрдер.

1) **Хәяә** [оят], 2) **сабыр**, 3) **дәгать** [тыелу], 4) **нәзаһәт** [намуслылык, начар нәрсәләрдән ераклык], 5) **канәгать,**

[3] Илтифат — кадер, хөрмәт, ярату.

6) **вәкарь**, 7) **рифык** [йомшаклык], 8) **хөсне сөлүк** [үз-үзеңне матур тота белү], 9) **вәрәгъ** [тыелу, хәрәмнән саклану, диндарлык], 10) **интизам** [тәртипле булу], 11) **сәха** [юмартлык].

Хәяэ [оят] — нәфеснең гакылда, шәригатьтә, гадәттә кабахәт вә гаеп булган эшләрдән сакланып, ул эшләрне кылудан оялу вә куркуыдыр. Шәригатьтә кабахәт булган эшләрне эшләүчеләргә — **«фасикъ»**, гакылда кабахәт булган эшләрне кылучыларга — **«гакылсыз»**, гадәттә кабахәт булган эшләрне кылучыларга **«ахмак»** диярләр. Оятлы булганнар бу өч төрле кабахәтнең өчесеннән дә сакланырлар. Оятның иманнан икәнен белмәк һәркемгә лязимдер. «Оялу, оят — иманнан», димешләр.

Сабыр. Бер теләгән нәрсәнең булмый калуына яки бер булдырасы килмәгән хилаф эшнең булуына каршы торып түзүгә сабыр диярләр. Гыйффәттән туган сабыр: «Теләгән нәрсәнең булмый калуына түзмәк» кыйсеменнән булып, икенче кыйсеме сәбат[4] мәгънәсендәдер. Болай булса, сабырны гомуми сурәттә: «Кайгы вә катылыкларга каршы чыдамлы вә түземле булмак, нәфес теләкләренә иярүдән сакланмак», дип тә тәгъриф кылмак [аңлату] мөмкиндер. Сабыр — бик мактаулы вә күркәм холыкларның берседер. Сабыр — максудларның ачкычыдыр. Сабырлык берлә һәрбер морадларга ирешү мөмкин булыр. Коръән Кәримдә: *«Аллаһы Тәгалә сабыр итүче коллары берлә бергәдер»*, — дип боерылмыштыр.

Дәгать [тыелу] — шәһвәтнең [енси дәрт, теләк] кызган вакытында нәфесне басып, ихтыярны кулдан җибәрмәссезлектер. «Нәфескә көч җитү — өстенлекнең иң олугсыдыр», — дигәннәре никадәр тугры сүздер. Шәһвәткә иярәп эш кылганнар бөтен адәмлек фазыйләтләреннән мәхрүм булырлар.

Нәзаһәт — [намуслылык] адәмнең үзенә дә, башкаларга да золым вә дошманлыкка сәбәп булмаслык рәвештә мал казанмагы вә аны тиешле вә мактаулы урыннарга сарыф кылмагыдыр. Моның да күркәмлеге сөйләп бетергесез дәрәҗәдә күптер.

Канәгать. Кулында кирәк-яраклары тотарга җитәрлек кадәр малы булып та, миңа фәләнчә кадәр кирәк, төгәнчә кадәр кирәк, дип борчылмый, барына риза булуга канәгать диярләр. Комсызлык вә тамыг [ачкүзлелек] һәрвакытта да хурлыкка сәбәп булыр. Шулай булса да гыйлем вә мәгърифәт өйрәнүдә җитәрлек кадәрле берлә канәгатьләнү яки эш вә кәсептә ялгыз көн күрә вә яши алырлык кадәр казанмак берлә канәгатьләнмәк, кәсептән тыелмак муфыйк түгелдер. Димәк, мәгарифтә, һөнәрдә, мәгыйшәттә канәгать итәмен дип, алга китәргә тырышмаганлык канәгатьнең мәгънәсен аңламаганлык димәктер. «Канәгать — бетми-төкәнми торган бер хәзинәдер» мәкалендәге мәшһүр сүз фани булган ләззәтләрне хурлау тугрысында булган иктифа[4] мәгънәсендәге чын канәгатькә гаидтер.

Вәкарь — максудларга керешкәндә акрынлык димәктер. Адәм бер эшне башлаганда ашыкмый-кабаланмый акрынлык берлә эш кылмак тиештер. Чөнки ашыгычлык булачак эшнең булмый калуына да сәбәп булыр. Шулай да бу акрынлык теләгән нәрсәнең вакытын үткәрмәслек дәрәҗәдә булуы да лязимдер.

Рифык [йомшаклык]— яхшылыкка сәбәп булган эшләрдә йомшаклык вә ягымлылык күрсәтмәктер. Ачу вә катылык берлә эшләнгән эшләр адәмне оятлы итәчәге кеби, игътибардан төшүгә дә сәбәп булыр.

Хөсне сөлүк [үз-үзеңне матур тота белү]— күркәм холыклар вә кирәкле һөнәрләрне өйрәнү берлә камил адәм булырга мәхәббәт итмәк мәгънәсендә булган бер фазыйләттер. Инсаниятне камилләргә, мәхәббәт берлә гыйлем вә мәгърифәт хасил итәргә тырышучылар — һәркем тарафыннан сөелгән фазыйләт иясләредер. ■

---

[4] Сәбат — чыдамлылык, ныклык.
[5] Иктифа — канәгатьләнү.

Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре

● Фәкать сәдака бирү ысуллары бозылган вә тиешле булган тәртиптән бер читкә чыкканнан соң гына ислам дөньясы ач күзлелек хасталыгына дучар булды вә йөз кешедән туксан тугызы бер кеше өстенә салынып, шуның маңгай тирләре берлә яшәү юлына керде.

● Ач күзле, комагай «галим»нең халык арасында хөрмәте булмаганлыгы вә бу бозык холык хәтта иң зиһенсез адәмнәргә дә билгеле булуы сәбәпле, андый кешедән нәфрәт кылулары мәгълүм.

● Һәрнәрсә хакында үз әрбабыннан (белгеченнән) фәтва сорарга, кирәк дөньяви вә кирәк охрави (ахирәт) эш булсын, әһелләренә киңәш кылырга вә шуның берлә үзең дә фикер йөртеп вә тикшереп карарга тиешле. Чөнки кешенең үз хәлен үзе яхшырак белүе, башкаларның күңелләренә дә килми торган нәрсәләрнең үзеңә алдан хис кылынуы тәҗрибәләр берлә мәгълүмдер.

● Кадере беленмәгән, бәһасе тәкъдир ителмәгәнне күргәннән соң халыклар изгелекләр вә хезмәтләрдән суыналар, тукталалар.

● Сабый вакытта өйрәнелгән гадәтләр адәм балаларында ахыр гомерләренә кадәр ташланмый барганлыгы мәгълүм.

● Хөрмәтле мөгаллимә вә мөгаллимнәр, мөрәббия вә мөәддипләр (тәрбиячеләр) милләт балаларының үз диннәренә мәхәббәтсезлек күрсәтүләре хакында берәр төрле чара тапсыннар иде.

● Мәгыйшәт вә дөнья көтүнең рухы тәдбир (эш ахырын уйлап эшләү) берлә икътисадтыр. Хатын, никадәр кәмаләт сахибе булса да, тәдбирле вә икътисадка игътибар итмәсә, гаиләнең киләчәге бәла вә бәхетсезлектән имин булмас.

● Бу заман яшьләре үз туйлары өчен үзләре хуҗа булырга вә үзләре тәдбир йөретергә тиешле. Туй сылтавы берлә җыелышып сыйлаша, ашый-эчә торган заманнар инде артта калды. Әгәр дә картлар сыйлашасылары, ашый-эчәселәре килсә, үзләре арасында туй ясасыннар. Әмма яшьләрнең бәхетләренә кермәсеннәр. Сыйларга, эчәргә вә ашарга багышланган акчалар яшьләрнең үз кирәкләре, самовар, ат вә сыер, өй вә келәт кебек үз заруры өчен сарыф ителсен, үз хәятләренә сәрмая ясалсын.

● Никах вакытында әһәмият биреләчәк нәрсә мәһәр, туй, бирнә вә җиһаз түгел, бәлки һәр ике тараф арасында дин вә әхлак, тәрбия вә табигать тугрыларында муаффәкыять булудыр.

● Әгәр сәбәпләрен кылмый вә тәдбирләр итми торып дога берлән генә эш бетсә иде, пәйгамбәребез сугышларга барырга хаҗәт күрмәгән, бәлки утырган урынында кул күтәреп дога кылган булыр иде дә, дошманнарының көлләре күккә очкан, әсәрләре беткән булыр иде.

Ленар Гобәйдуллин *әзерләде.* ■

1963 ел

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Александр Филиппов

«Бу рәсемдәге иң яшь кеше дә бүген җитмешен тутырып килә булыр. Менә минем үземә дә (беренче рәттә уңнан беренче) 2015 елның 20 гыйнварында 78 яшь тулды... 1962 елда мин дә, биш ел буе тормыш «университетын» тәгәлләп, белем бирә торган чын университетка укырга кердем. Икенче уку елында кайсыбыздадыр Зәй районының Түбән Биш урта мәктәбен тәмамлап, Казанның югары уку йортларында укый торган «яшьти»ләрне җыеп, фотога төшү теләге туды. Билгеләнгән көнгә Ленин бакчасына 14 студент җыелды. Биредә медицина, педагогика, ветеринария, төзелеш, финанс институтларыннан һәм консерваториядән дә студентлар килде. Кызганыч, фото артына кемнең кем икәнлеге язылмаганлыктан, сурәттәге кайбер кешеләр инде истән дә чыккан. Шулай да биредә миңа якын ике кеше бар: аның берсе гомер буе Түбән Каманың ябык зонасында табиб булып эшләгән һәм гармунын кулыннан төшермәгән, җае чыккан саен кулына каләм алып, юмор һәм сатирага бай үткен шигырьләр язучы Никифор Тукмачев (өченче рәттә сулдан икенче) булса, икенчесе төс-килбәте, кыяфәте, ятимлеге белән дә Тукайга гына охшап калмыйча, мәктәп елларыннан ук үзенең шагыйрәнә осталыгы белән барлык җиһанны таң калдырган кеше Мөдәррис Әгъләм

(рәсемдә икенче рәттә уңнан икенче). Ул арабыздан, бары тик алтмыш яшен генә тутырып, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты һәм Татарстан Республикасының Халык шагыйре исеменә лаек булып китте».

1972 елның 25 апреле

***

«Арча партия райкомында пропаганда һәм агитация бүлеге инструкторы булып эшләгән елларымда Казаннан һәм башка төбәкләрдән килгән язучыларны Тукай-Кырлай авылына озатып куярга туры килә иде. Беренче фотодан соң ун еллар вакыт узгач, мин якташым Мөдәррис Әгъләмне яңадан очраттым һәм Тукай торган Сәгъди абзый йорты янында фотога төштек. Бу вакытта инде ул СССР Язучылар берлегенең тулы хокуклы әгъзасы иде».

Ә.Нурмиев фотосы. 1981 ел

***

«Бу фотоның тарихы болайрак. Мине, Ленинград Югары партия мәктәбенең журналистика бүлеген бетереп кайткач, Апаска, «Йолдыз» район газетасына баш мөхәррир итеп җибәрделәр. Ул елларда язучыларны, тормыштан бик үк аерылып бетмәсеннәр өчендер инде, район газеталарына берәр айга эшкә юллыйлар иде. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Гариф Ахунов Апаска Рабит Батулланың бару теләге барлыгын белдерде. Мин бик теләп риза булдым. Авылдашым буларак, мин аны кунакханәдә түгел, ә үзебездә торырга күндердем. Рабит Батулладан редакция бик уңды, дияр идем. Ул, бер ай эчендә күп кенә колхозларда, мәктәп һәм балалар бакчаларында, мәдәният учакларында булып, ике-өч айга җитәрлек материал язып калдырды».

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ: ИРКӘ САКАЕВА

Сүнмәс йолдыз балкышы

Абдулла Дубин

Диктор — теге яисә бу тапшыруны әзерләгән күп санлы коллектив эшчәнлегенә йомгак ясаучы соңгы боҗра. Ул алгы сызыкларда санала һәм телетамашачылар, радиотыңлаучылар белән беренчеләрдән булып элемтәгә керә. Дикторның һөнәри осталыгы никадәр югары булса, тапшыру да шул рәвешле бәяләнә. Начар сөйләм белән иң бөек, даһи әсәрне дә бозып ташларга мөмкин. Һәм — киресенчә...

Бүгенге көндә экраннарда яңгыраган «чыктым аркылы күпер»ләр тамашачының телен, зәвыгын боза. Бу — алып баручылар да, телевидение дә үз хезмәтенә хөрмәт белән карамый дигән сүз. Ирексездән, күңел журналистлык һәм артистлык сәләтләрен бергә үреп, дикторлык эшчәнлеген югары профессиональлек дәрәҗәсенә күтәргән шәхесләрне юксына башлый. Иркә Сакаева (1938-1982) да әнә шундыйлардан иде. Аның тырышлыгы, хезмәт сөючәнлеге, туктаусыз югарыга үрләве башкаларга әле дә үрнәк булырлык.

Даһиларның сәләтен танырга теләмәгән, кешелекне яклау, теләктәшлек таба алмаган торгынлык елларында Иркә ханым аянычлы язмышка килеп капты. Ялгыз калган көннәрдә ул кешелекнең иң явыз дошманын — «яшел елан»ны дус итте. Илгә 1982 ел иңеп бара иде...

Иркә Сакаева — егерме ел буена Татарстан радиосында да хезмәт куйган шәхес. «Яшьләр радиодулкыны», «Идел белән Урал арасында», «Говорит юная смена» тапшыруларын алып барды ул.

Гомерләр бигрәк кыска шул. Исән вакытында кешенең кадерен белергә кирәк. Ә инде вафатыннан соң яхшылап искә алу да урынлы булыр иде...

Татарстан телевидениесе дикторлары Әминә Сафиуллина (сулдан), Абдулла Дубин, Иркә Сакаева, Айрат Арсланов. 1963 ел

Абдулла Дубин һәм Иркә Сакаева «Кичке Казан» тапшыруын алып бара. 1975 ел

Иркә-Иркуша

Туфан Миңнуллин

Без Мәскәүнең театр училищесына барыбыз да театрның ни икәнен белмичәрәк барып эләктек.

Арабызда театр дөньясын бездән күбрәк белүче бердәнбер кеше Иркә Сакаева булгандыр. Ул — татар театрының атаклы шәхесләренең берсе Нури Сакаев белән бер нәселдән. Башка туганнары да, танылган артистлар булмасалар да, театр тирәсендә йөргән-эшләгән кешеләр иде...

...Ул бик сәләтле кеше иде. Һәрвакыт игътибар үзәгендә булды. Әллә ни чибәр булмаса да — сөйкемле. Мин аның елмаюын ярата идем. Казан телевидениесендә ул диктор булып эшләде, аңа тамашачылар гашыйк иде. Инде якты дөньядан киткәненә ничә еллар узса да, аны һаман искә алалар, юксыналар.

«Иркуша» диләр иде аңарга. Югыйсә, Иркә — нинди матур исем!

Укыган чакта безне санлап бетермәсә дә, олыгая башлагач безгә тартылды. Телевидениедә очрашканда үз итеп килеп кочаклый иде дә:

— А помнишь? — дип яшьлекне искә төшерә иде.

Әйе, хәтерлим, бию дәресләрендә укытучы миңа пар итеп Иркәне бирде. Чөнки ул искиткеч музыкаль иде, ә минем колакка «аю баскан». Минем белән биеп интекте Иркә. «Ну чё ты, ну чё ты!.. Чё на ногу наступаешь?» — дип мине өйрәтә иде, ләкин беркайчан да ачуымны чыгарырлык сүз әйтмәде. Мин аның белән биемим, дип киреләнмәде. Бервакыт вальс әйләнгәндә кулым таеп китеп, үзен кочаклап алдым. «Ну вот, начал обниматься», — дип елмайды.

Сагынам мин Иркәне! Без аны барыбыз да сагынабыз. Шул ук вакытта талантлы татар кызының үз асылын таба алмыйча, табигать биргән сәләтне татар халкына тулысынча багышламыйча, якты дөньядан китеп баруына сызланабыз да.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Иркә Сакаеваның тормышы һәм иҗаты белән Әхтәм Зариповның «Иркә, иркәләмисең...» («Татарстан» журналы, №8/9, 1998), Айрат Арсланның «Ул — Сакаевлар йолдызлыгыннан» («Мәдәни җомга» газетасы, 1 август, 2008) мәкаләләре, «Сәхнә ул — могҗиза» («Рухият» нәшрияты, 2004) җыентыгы аша тулырак таныша аласыз.

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

9. ОСТАЛАР БЕЛӘН МӨГАМӘЛӘ ТУРЫНДА

Тагы бер катлам бар – оста эшчеләр,
Яшәү хаҗәтләре өчен эшлиләр.

Болар да сиңа бик кирәкле заттыр,
Якын тот аларны, якла, и, батыр.

Тимерче, итекче, янә кырмачы,
Буяучы-бизәкче, җәяче-укчы.

Бу дөнья кирәген болар әзерләр
Җиһан таң калырлык төрле әйберләр.

Шуларын санасаң озакка китәр,
Үзең кара, ә мин санадым – җитәр.

Болар белән яшә аралашлыкта,
Аларны шатландыр – яшә шатлыкта.

Эшләтсәң эшеңне, эш хакын тиз бир,
Табыннар оештыр, ашат һәм эчер.

«Саран» диеп сине сүз йөртмәсеннәр,
«Аты артак»[1] диеп хур итмәсеннәр.

Ни шәп әйткән бераү – сүзләр белгече
(Халыкка теләктәш күңле төз кеше):

Озын гомер түгел, изге ат телә,
Изге атыңны син гомергә тиңлә.

Үзең үләсең, тик кала исемең,
Изге атың яшәү шатлыгына тиң,

Кемнең яманаты таралган булса,
Аның өчен яхшы буласы, үлсә.

Яшәвең, гүя, бер мая йомыртка,
Шуны басып утыр, җәннәт — комарткы.[2]

10. ФӘКЫЙРЬЛӘР БЕЛӘН МӨГАМӘЛӘ ТУРЫНДА

Фәкыйрьләр катламы – үзенә башка.
Аларга изгелек кыл, эчерт-ашат.

Догачы булырлар сиңа, и, кардәш,
Бик изге нәрсә ул дога, и, кардәш.

Алардан сорама җыем-салымны,
Салым өчен сиңа – җәннәттән урын.

... Менә шул төркемнәр бирелә сиңа,
Шуларга эш төшә идарәчегә.

Рәхим-шәфкатъ белән бирсәң син әмер,
Барча төркем сине якын күрәлер.

Ике дөньяда да исмең нур алыр,
Изге атың-даның ерак таралыр.

Эшләтсәң эшеңне, эш хакын тиз бир,
Табыннар оештыр, ашат һәм эчер.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.

[1] Артак – «чыгымчы».

[2] Комарткы — «ахыргы әҗер, васыять, бүләк».

11. НИЧЕК ӘУЛЕК[2] АЛЫРГА?

Әгәр өйләнмәкче булсаң син үзең,
Сайлап ал һәм җете күрсен һәр күзең.

Асылы-җәвере игедән булсын,
Әдәпле-хаялы һәм пакь тән булсын.
Өйдә үскән, кеше кулы тимәгән,
Синнән үзгә бер ир күрмәгән булсын.

Шуннан сине сөяр, бүтәнне сөймәс,
Һәм сине кызыксыз хәлләргә куймас.

Хатының булсын ул түбәнрәк заттан.
Тик аңа кол булып калудан саклан.

Ничек әйтә, ишет, сынамыш кеше
(Сынамыш кешенең эше дә пеше):

«Хатын алсаң, ал син бераз түбәнне:
Тынычлык-шатлыкта үтәр көннәрең».

Йөзенә багынма, кара иплене,
Иплe булса хатын, яктыртыр өйне.

Бик иртә өйләнмә, көт насыйбәңне,
Шулчакта булырсың акыллы, аңлы.

Матурны эзләмә, эзлә игене.
Иплe кыланыш шул камиллек инде.

«И, матур», дип ал йөз эзләп йөрмә син:
Ал йөзеңне сары итә күрмәсен.

Өйләним, дисәң син, эзлә бу дүрттән
(И, егет асылы, кирәкми бүтән):

Берәү эзләп йөри баерак хатыннар,
Икенчеләр тели яшь һәм матурдан,

Өченчеләр эзли асыл затлыны,
Мактанырга «асыл зат, дип, хатыным»,

Дүртенчеләр «нечкә хисле, фикерле
Кәләшне, ди, өйгә сайлап китерим»,

«Каюсы яхшырак, дисәң, болардан»,
Хатын алыр булсаң, миңа колак сал.



Хатының булсын ул түбәнрәк заттан.
Тик аңа кол булып калудан саклан.

И, кем ки теләүче бер бай хатынны!
Әсир була күрмә, бул син акыллы.

Эре була күңле һәм теле озын.
Таләп итсә малын нишләрсең үзең?

И, матур кыз эзләп йөрүче егет!
Табалмассың, йөрмә кеше көлдереп.

Матурларны халык сөя һәм тели.
Тик алар язмышын Алла билгели.

И, кем ки эзли бер асыл затлы кыз!
Үзеңнең затыңны кылма кадерсез.

Асылзадәләрнең теле бик тә юка.
Асыл хатыныңа төшмә коллыкка.

«Фикерлерәк булсын, —
дисәң, — хатыным»,
Тапсаң шундыйны, ал шундук, акыллым.

Ирешерсең аның белән барсына:
Бай, асылзат, матур булыр ул сиңа.

[2] Әүлек – (Себер сөйләшләрендә дә бар) «хатын, кәләш, хуҗабикә» (әү — «өй» сүзеннән).

Акыллы, тәртипле хатын матур ул:
Акыл һәм дә холык – иң зур матурлык.

Теләгәнең байлык булса, табылыр,
Баетыр ул сине, йөзең ал булыр.

Акыллы, тәртипле хатын матур ул:
Акыл һәм дә холык – иң зур матурлык.

Асылзатлык ул аң-белем катында,
Димәк, өч фазыйләт аңлы хатында.

Акыллы-аңлыны алсаң, и, белкә,
Бөтен дүрт фазыйләт килер ич бергә.

Шундый кыз тапсаң, һичнигә карама,
Ычкындырма аны, бул бер карарда.

12. УГЫЛ-КЫЗ ТУГАЧ, АЛАРНЫ ТӘРБИЯЛӘҮ ТУРЫНДА

Угыл-кыз турәсә, егет, бәхеткә!
Үз өеңдә үстер, җибәрмә читкә[3].

Тәрбиячеләрдән сайла аруны –
Ару булыр балаң, йөрмәс азынып,

Угыл-кызга өйрәт әдәп һәм белек,
Ике дөньяда да тапсын ул өлеш.

Угылга кәләш ал, кызны бир иргә –
Кайгысыз яшәрсез барыгыз бергә.

Угылга бар сәнгать-һөнәрне өйрәт,
Шуннан ул малыңны арттыра бирә.

Яшь угылны тикшер – буш йөгермәсен,
Һәм башбаштакланып азып йөрмәсен.

Кызың җитсә, өйдә саклама озак:
Үлемең аурусыз, юкса, булачак!

Көфер сүз әйтәсем килә, и, дустым:
Тумасын кыз бала, туса тормасын[4].

Җир куены аның иң лаек өе,
Күрше булсын шуңа үлек сәрае.

Хатыннарны күзәт үз өеңдә гел,
Алар ике йөзле – беркатлы түгел.

Хатынны чыгарма, ятларга кертмә:
Күңле юлдан язып, ят ирне күрсә.

Күзең күрмәгәнне теләмәс күңлең,
Күзең күргәч, теләр күңлең, и, углым,

Күзеңне бәйдә тот – күңлең азмасын,
Күңелең азмаса әсир калмассың.

Табында булмасын катнаш ир-хатын,
Әгәр катнаштырсаң, китәр гыйффәте.

Хатынны чыгарма өйдән гозерсез,
Өйдән чыкса, туры юлдан язып тиз.

Угылга бар сәнгать-һөнәрне өйрәт,
Шуннан ул малыңны арттыра бирә.

Асылда хатын – ит, сасый күрмәсен,
Сакланмасаң, берни эшли белмәссең,

Кадерлә хатыныңны – сораганын бир,
Тик биклә капкаңны – күрмәсен бер ир.

Вафа юк кызларда әзәлдән бирле:
Күзе кая бакса, шундадыр күңле.

Кадерләп үстергән агачың булса,
Җимеше агулы – кызыкма шуңа.

Ничәмә-ничә мең юньле ирәннәр
Хатын сәбәбеннән юньсезләнгәннәр.

Ничә якты йөзле, абруйлы ирләр,
Хатын бәласеннән карады җиргә.

Төмән мең шәрәфле, данлы егетләр
Күмелгән хатын-кыз өчен тереләй.

Кем күзәтеп, киртә кора аларга?
Тапшырасыз инде барсын Аллага...

[3] Төрки халыкларда элек-электән балаларны чит гаиләдә үстереп, шул гаилә белән туганлашу (аталык, аналык, тайы иту) гадәте булган. Йосыф Баласагуни бу гадәткә каршы.
[4] Күрәсең, Йосыф хасс хаҗинең үз кызы бик әрнеткән.

13. КУЛ АСТЫНДАГЫ КЕМСӘЛӘР БЕЛӘН МӨГАМӘЛӘ ТУРЫНДА

Янә хезмәткәрне асра бик әйбәт,
Ашат-эчерт, кара, киемен бөтәйт.

Эш йөкләт һәркемнең көченә карап,
Хуҗа ялчы өчен бирәдер җавап.

Ая, алар азап күрмәсен артык –
Сорар синнән Алла хезмәтче хаккын.

Синең кебек Алла колы ич алар,
Җәзаласаң, Алла сине җәзалар.

Син аларга — өлкән, алар – кечеләр,
Өлкәннәр кечегә елмаеп сөйләр.

Олы булсаң да син, кече тот күңлең,
Олыга кечелек ярашыр, углым.

Ни ди, ишет, ушлы кеше, син тыңла
(Бу сүзләр ярашыр гамәл кылырга):

«Әгәр син халыкка булсаң баш, олуг,
Үзеңне кече тот – алырсың йолым».

Онытылып китмә, чыкма юрыктан,
Килер көч, чыкмасаң тугры юлыңнан.

Ару-таза булсын өең-каралтың,
Килер шунда сиңа дәүләт, юмартым.

Аш-су, икмәк-тозны мул булдыралсаң,
Бәхет кошы булып килер сиңа дан.

Кереме ңә карап чыгымны сана,
Чыгымнан соң кара керемгә янә.

Алымга-биремгә ипчел, оста бул, бел —
Кайда, кайчан, ничек ачык була юл.

Кулың кыска булып калган чакларда
Кешегә сер бирмә, егет – акылдар.

Дусларың ярдәмгә сирәк килерләр,
Ә менә дошманнар синнән көлерләр,

**Олы булсаң да син, кече тот күңлең,
Олыга кечелек ярашыр, углым.**

Дус-иш үзара «ул акылсыз» дияр,
Бу сүз сиңа җитер, күңлеңә тияр,

Кеше яхшысына аралаш, катыл,
Кеше белән кеше булу – зур акыл,

Авылларда торма, мал көтмә үзең,
Үкенеп саргаер, хәтта ал йөзең.

Олы юлга якын куйма ихатаң:
Бәлагә юлыгу бик ихтималдан.

Корыт, су урлаучан күршең булмасын[5],
И, тугрым, хәсискә якын торма син.

Бу өч күршеләрдән сиңа файда юк,
Зыяннары тисә, качыр җай да юк,

Өй алмакчы булсаң, күршесен сораш,
Җир алмакчы булсаң, юл кара суга.

Исәргә кагылма, сәламәт йөре,
Төз юлдан гына бар, кәвәл[6] шикелле.

Барына канәгатъ булса, ул чын бәк,
Хирысың аз булса, шатлыгың күбрәк.

Үзеңне онытма, оема үзең,
Ияңне белеп тор – ачык тот күзең.

Сүзең уйлап сөйлә – кайгы килмәсен,
Вакыт буш үтмәсен – һәм үкенмәссең.

Артык гади булсаң – алкыш табырсың,
Артык саранлансаң, каргыш табырсың.

Ни ди, ишет әнә вөҗданлы кеше
(Кешелек кылучан кешеләр өчен):

Үзең «изге атлы булыйм мин» дисәң,
Азрак ал кешедән, күбрәк бир, бирсәң.

Дәвамы бар ■

[5] Корыт — ачык таскакта киптерелә торган эремчек йомгаклары. Су урлау — кеше арыгындагы суны үз арыгыңа борып җибәрү. Бу сүзләрдә Урта Азиядәге сугарулы җирләрдә яшәү-көнкүреш үзенчәлекләре чагыла.
[6] Кәвәл — «яхшы өйрәтелгән хәрби ат». Бу сүз күп телләргә таралган һәм борынгы төрки язмаларда (КБ-тә дә) очрый. Шуннан кавалерия сүзе килә.

КЫЙССАИ ТАҺИР ИЛӘ ЗӨҺРӘ

Ул шулай ханның намусына тия, аны Таһирга каршы ярсыта торган күп сүзләр сөйләде. Хан да инде элеккеге Бабахан түгел иде. Гаделсезлек юлына басып, антларын бозып Таһирны эзәрлекли башлаганнан бирле аның бар башлаган эше сүтелә, тискәре нәтиҗә генә бирә торган бул-

* Дәвамы. Башы журналның 9 нчы санында (2015).

ды. Акрынлап ул бу тормышта, дөньяда берәр максатка ирешү мөмкинлегенә ышанычын җуйды. Уңышсызлыклар белән үзен борчымас өчен ул эшләрдән, бурычлардан читләшергә тырыша. Күбрәк исерткеч кабып күңелен күтәрә, үзен батыр егет итеп хис кыла, исереклектән хозурлана башлады. Вәзирләре, сарай даирәләре аның бу хәленнән үз мәнфәгатьләрендә файдаланырга тырыша, аны үз мәнфәгатьләренә эшләтә иде. Мондый «эшчәнлек» кенә нindидер нәтиҗә күрсәткәне өчен ул үзе дә гүя шундый очракларны гына эзли, шундый эшләрне генә башкара. Кыскасы, вәзирләре һәм сарай аксөякләре кулындагы бер курчак булып калган иде. Ул бар эшне баш вәзир дәрәҗәсенә күтәргән, Карабатыр кулына тапшырып куйган. Аны эшкә өйрәткән төс күрсәтә, җәмәгатьчелек алдында шуның белән аклана иде. Карабатыр да, аның һәркем кулында курчак булып, эшкә комачау тудыруларын сизә, аңлый, бер үк вакытта, аны нәкъ шул юнәлешкә генә юллый иде. Ул аңлый: эшләр шулай барса бик тиздән хан үзе дә, халык та Зөһрәне үзенә кәләшлеккә биреп, Карабатырны тәхеткә утыртудан башка чаралары калмаячак.

Карабатырдан ишеткән хәбәрдән ханның ачуы соң дәрәҗәсенә җитте. Ул Зөһрә сарае тирәсенә аулак җирләргә күп гаскәрләр яшерде. Аларга Таһир күренүе белән тотып бәйләп үз каршысына китерергә боерды. Ул көнне Таһир йоклаган иде, бер куркыныч төш күрде. Тирә-ягын куркыныч кара этләр чолгап алды, өстенә ташланалар... Таһир качмакчы була, әмма урыныннан да селкенә алмый... Куркуыннан ул уянып китте. Әмма байтак һуш җыеп ятканнан соң гына үзенә килә алды. «Мин җиде ел элек тә шул төшне күргән идем, җиде ел зинданда интектем. Инде тагын да куркынычрак. Сакланыйм...», – дип, ул ике көн өеннән чыкмады. Әмма гыйшкына тәкать тота алмады, алтын сазын алды да өченче кичне Зөһрә сараена китте. Анда да, апасының нәсыйхәте исенә төшеп, Зөһрә төшергән ефәк баскычка үрелмәде, эчкә үтмәде. Таһирның бу кыланышларының сәбәбен белмәгән Зөһрә, Таһирның күңеле миннән суынган икән, дип уйлап, әрнеп бу шигырьне әйтте:

Җан кайгыга буялды, күңелем зарга туенды,
Таһирҗаным, гашыйгым, нидән күңелең суынды? —

Таһир аңа мондый хәсрәтле шигырь белән җавап кайтарды:

Кайгы шулай иткәндер: шатлык көнем үткәндер.
Син бәхетем кояшыннан аерылыр көн җиткәндер.

Авазыннан ук инде Зөһрә гашыйк Таһирга бер-бер хәл булганын аңлады. Күзләре яшькә тулды. Шунда күреп калды: әллә нинди кара шәүләләр Таһир өстенә ташланды. Әмма бу юлы Таһир үзен алардан юаш сарык кебек бәйләтмәскә булды. Куенына тыгып йөри башлаган хәнҗәрен тартып алды. Үзенең өстенә ташланучыларның кайсының муенына хәнҗәр орды, кайсының күкрәгенә чәнечте. Дошманнарының өстенә ташланып, кемен ботыннан тотып ата, кемен якасыннан алып олактыра башлады. Калган-котылган гаскәрләр үзләре куркынып, караңгырак почмакларга сыенды да хәлне ханга хәбәр итеп, ярдәмгә яңа гаскәрләр сорады. Бу хәбәрне ишетеп патша ярдәмгә тагын биш йөз кешелек гаскәр җибәрде. Килеп җитүләре белән бу зур төркем гаскәр тагын Таһир өстенә ташланды. Таһир тагын кулын, аякларын, хәнҗәрен эшкә төшерде. Ул гаскәр эчендә корыч бөтерчек кебек бөтерелде. Кемгә кагылса, аның җаны тәненнән очты, бер дошманы белән дүрт-бишен бәреп екты. Араларыннан җитмеш-сиксән кеше һәлак булгач, гаскәрнең тагын коты очты: чит-читкә кача башладылар. Гаскәр башы,

кеше җибәреп, тагын ханнан ярдәм сорады. Моны ишетеп бик каты ачуы чыккан хан мең кешелек гаскәр белән үзе килеп җитте. «Тотыгыз шул ахмак, хыянәтче баланы. Күрсәткән аш-суыма хыянәт белән җавап кайтарганының ачысын татысын!» – дип, патша гаскәрне Таһир өстенә ташлады. Таһир каушап калмады. Гаскәр уртасында корыган болын үләне хәлендә калды. Таһир төн буе һәм көн буе аларга каршы торып сигез йөзләп кешене үтерде. Моны күреп, Зөһрә Таһирга: «Әгәр мине теләсәң, атам падишаһка буйсын, аның ачуын чыгарма, хәтерен калдыра торган эш кылма», – дип ялварды. Бу үтенеч Таһирның ачуын кайнатты:

Җан Зөһрәм хафа булганда дәртемә шифа булырмы?
Үзгәрүчән кызлар күңелендә миһер һәм вафа булырмы? —

дип, үпкәле шигырен әйтте. Әмма үзе дә, аңсыздан, шул ук нәтиҗәгә килгәнен аңлады: «Бу ил бозыклык, гаделсезлек шаукымына юлыккан. Әйе, ул юл фәкать һәлакәткә алып бара. Әмма моңа карап, бозыклык юлына киткәннәр дип, синең ул кешеләрне үтерергә хакың бармы? Патшасыннан башлап соңгы кешесенә кадәр шул афәткә тарыган мондый илдә әшәкелек юлындагы һәр кеше җәзага лаек дип, бозыклык юлы азгыннарыннан дөньяны тазартмакчы булсаң, акрынлап илдәге соңгы кешегәчә башын чабарга туры килмәсме соң?» – дип уйланды. Һәм: «И, минем гашыйк ярым! Бу юлда сугышып башымны бирсәм миңа җиңелрәк булыр иде дә, синең хәтерең, намусым тынычлыгы исеменә атаңа буйсынам», – дип, хәнҗәрен читкә атып бәрде һәм бәйләүчеләргә кулларын артка сузды. Зөһрә исә:

Кыз-хатында тугрылык юктыр, димә, Таһирым,
Җаным, юлыңа корбан, хәсрәт өймә, Таһирым, —

дип, вәгъдә яңарту сүзләре белән ярын юатып торды.

Хан, кулы бәйләнгән Таһир янына килеп, аны битәрләргә, оялтырга тотынды: «Әй, аш вә тоз хакын хакламаган йөзе кара! Мин сине үз балам кебек сөеп үстергәнемә рәхмәтең шул булдымы? Мине йортның теленә калдырдың. Әлегәчә Зөһрәгә ничек тә булса өйләнү ихтималың юк түгел иде. Инде син, хыянәтче, иңсә чокырыңны күрә алмаган кебек, Зөһрәне дә күрәсең юк. Күпме гөнаһсыз җанны койдың!..» – диде. Таһир, бичара, хан сүзләреннән җиргә сеңеп китәрдәй булды.

Таһирны хөкем мәйданына сөйрәп илттеләр. Голәмәләр, вәзирләр җыелып тәхеттә утырган хан тирәсенә урнаштылар. Хан җәлладны чакырып: «Тиз генә шул хыянәтче баланың башын кис — башкаларга гыйбрәт булсын!» – диде. Таһир падишаһка карап бер шигырь әйтте:

Мине син хыянәтче иттең, ә үзең, әйтче?! –
Ант-вәгъдәңне таптадың, намусыңны таладың!
Җан кыйдым, беткәч түзем, кулым бәйләттем үзем,
«Җәллад!» – бар тапкан сүзең, гадел хөкем тапмадың!
Шатланып үлә алам: намуслы итте Аллам,
Бары ярым бирә дәрман, син антыңны таптадың!
Үкенечем юк үлгәндә, ярым туя күргәнгә,
Бу дөньяга килгәннән, кулга бер эш тапмадым!
Эчәм үлем шәрабен! Халкым эзләр сәбәбен,
Аңлар тормыш хәрабен, шуңар җәллад тап тагын...

Ханның «...башын кис!» дигән сүзләрен ишеткәч, галимнәре һәм вәзирләре

һәрьяктан: «И, падишаһыбыз! Мондый хөкем дәүләтеңә лаек түгел… Берәр яктан бер дошман чыга калса, моның да кирәк көне булыр!..» – дип киңәшләр бирделәр. Әмма ханның Таһирга ачуы һәрнинди чикне-чаманы узган иде инде. Нindидер бер яшерен ярсу белән ул эченнән: «Ярый, сезнең киңәшләрне кабул иткәндәй булыйм. Әмма шундый җәза уйлап табыйм ки, ул башын чаптырмауларына мең мәртәбә үкенерлек булсын…» – дип уйлады. «Сүзегезне мәслихәт күреп, аның җанына кул салмаска булдым. Әмма илдә калдыра алмыйм. Аның гомерен тәкъдире ихтыярына тапшырыйк. Тәкъдирен сынасын: сандыкка салып Иделгә ташларга!» – дип әмер итте. Осталарын Таһир буена яраклы итеп сандык ясарга утырттылар. Зөһрә шунда ук осталар янына барды: «Әгәр дә сандыкны су үтми, давыл-дулкын сугуларыннан бозылмый торган итеп ясасагыз, мин сезгә күп алтын бирермен», – дип вәгъдә итте. Алтын алыр өчен осталар сандыкны Зөһрәнең бөтен таләпләренә җавап бирә торган итеп ясадылар. Иделнең текә ярында сандыкны елгага атар өчен корылма ясадылар. Зөһрә йөрәгенә ут салып Таһирны Идел ярына алып килделәр. Бу фаҗигадән тетрәнеп яр буена шулкадәр күп халык җыелган иде ки, энә җиргә төшәргә урын юк иде. Хәтта кысылып, тапталып күп кенә үлүчеләр дә булган, диделәр. Бар җыелган халык гөр килеп ризасызлыкларын искәртәләр. Ил олылары: «Болай карап торып гаделсезлеккә юл бирергә ярамый. Халыктан акча җыеп, күпме хак куйса да, Таһирны ханнан йолып алыйк…» – дип сөйләшәләр. Әмма аларның мондый сүзләре ни эшләргә дә чара таба алмаудан өметсезләнүләрен генә чагылдыра иде. Ясавыллар сандыкка салганда, Таһир, соң мәртәбә күргәндәгедәй зар булып, туган ил күгенә карады. Әнисен исенә төшерде. Ана исеменә атап бу шигырьне әйтте:

Әй, миһербаным, анам! Тагын утларга салам,
Сине кайгыга ягам, кичер, бәхетсез балаң.
Тәкъдир дөнья йортында көн күрсәтми бер тын да,
Бәгыреңне ерттым да, гел җафа булдым, балаң.
Миңа — сәфәр, сиңа зар; өмет, сабыр миндә бар,
Синең күңелең кем табар, сүнмәс сагышлы анам?!

Шуннан соң Зөһрә исеме телгә килде һәм аңа шигырь әйтте:

Кодрәтле Аллаһ, кадир дә, өлеш иткән тәкъдирдә,
Безгә фирак һәр җирдә, ялгыз ярым, әлфирак!
Йолдыз күзлем, йөзең гөл; сабыр кыл гел, сабыр кыл!
Бар дәва тик сабырдыр, вәгъдәлем, хуш, әлфирак!

Таһирны салып, сандыкны бикләделәр. Ачкычын элгеченә бәйләп тактылар. Сандыкны корылмага элделәр дә чайкалдыра-атылдыра башладылар. Сандык корылманың өске бүрәнәсеннән югары күтәрелә башлагач, арканны бердән ычкындырдылар. Сандык очып китеп елганың көчле агышына барып төште һәм, әйләнгәли-әйләнгәли, еракларга агып китте.

Зөһрә бу шигырьне әйтеп, яр өстенә капланып өзгәләнеп үксеп калды:

Күрәсезме, дивана булдым бүген:
Караңгы төн каплады күңелем күген.
Яр гөл йөзен күрүдән тик мин хәят, –
Ул юк, җан бит тик әрнү, бинигаять!
Нигә болай бар зат безгә ят булды?

Без янганнан алар көне шат булды?!
Сабыр суын койсаң да, сүнмәс утым.
Кол итте зар, көнем түгел, минутым.

Таһирның әнисе Хубан ханым Бабахан алдына барып бу шигырьне әйтте:

Ник каныктың? Чөнки безне ятим, яклаучысыз күрдең,
Безне тоташ утка яктың, корымын йөзеңә сөрдең!
Сеңми, батмый ятим хакы: син дә күрмәссең якты көн,
Әзәрлекләә, безгә уты, сиңа да тик сөрем, төтен.
Димә: «Минем дөнья түгел! Тыңла: алдый, тын да алмый
Китәрсең, киткәндәй синдәй ничә патша, берсе калмый.
Олың-кечең, тирәң шакшы, бу мәхшәрдән аккан яхшы,
Аh-зарыбыз хәддән ашты, җаныбыз утка болашты.
Болар бар да сиңа кайтыр: әҗерен җаның, җирең татыр,
Ни күрәсең, мескен татар искә алмый сине хәзер.
Кудың җаннан «Искәндәрең», кальбеңдә юк «Сөләйманың»,
Ә Таһирга тәкъдир язган Йосыф, Фәрһәд, Мәҗнүн данын!

Идел агымы Таһирны ераклардан-еракларга алып китте. Үз теләге, ана догасы кабул булып, бу озын юлда Хозыр аңа юлдаш булды. Ашыйсы килгәндә, тукландырды, эчәсе килгәндә хәзинәсеннән су эчертте. Сандык такталары гүя үтә күренмәле булып, Таһир илһам күзе белән тирә-як хәлләрен күреп барыр иде. Идел сандыкны алып килеп диңгезгә этеп чыгарды. Диңгез дулкыннары, агымнары аны әләктереп алып илдән еракларга, чиге-яры күренмәс диңгезнең урталарына табан сөйрәде. Сандык юлында, диңгездә бер упкын бар иде. Ул үз тирәсеннән бернәрсәне дә үткәрмәстән диңгез төбенә суырып ала, ә диңгез төбендә ул упкын тарткан һәрнәрсәне зур бер балык йотып тора иде. Сандыкны да упкын диңгез төбенә тартып алды. Таһирга рәхиме килеп, балык Таһирны йотмады. Йота алмыйча аны кире диңгез өстенә этеп чыгара, ә упкын исә кабат аны төпкә тартып ала иде. Сандык шул рәвешчә упкында кайнап тора башлады. Упкынның һич кенә дә аны куып җибәрәсе юк иде. Бу бәргәләнүләрдән интеккән Таһир бу бәладән коткаруны сорап Ходайга мөнәҗәт кылды:

Син дип бар дәрттән кичтем, Ходаем,
Гыйшык шәрабеннән эчтем, Ходаем,
Хыйреслэнми дөнья ләззәтләренә,
Әрнү-михнәтләргә күчтем, Ходаем,
Һавалану, һәвәсләнүне куеп,
Фәкыйрьлек юлына төштем, Ходаем,
Гыйшык утында, феникс кошка охшап,
Көл булдым да, тагын очтым, Ходаем,
Бу упкында һәлак итмә, хәлас ит,
Рәхмәт эстәп кулым ачтым, Ходаем.

Аллаһы Тәгалә Таһирның дога-мөнәҗәтен кабул кылып, сандыкны бу упкын кочагыннан коткарды. Таһир диңгез буйлап өч ай агып йөрде, илһам күзе белән андагы гаҗәеп хәлләрне күзәтеп Алланың кодрәтләренә таң кала иде. Шулай беркөнне сандык «Су кешеләре» иленә барып чыгып зур шау-шуга сәбәп булды. Алар суда яшиләр, җир адәменең исе килгән җирдә хәтта тора алмаслар икән,

шунда ук: «Алла! Алла!» – дип илерешеп, төрлесе-төрле якка чәчелеп качып китәләр икән. Таһир исен дә алар ерактан ук сизделәр. Борчыла, шаулаша, мыж килә башладылар. Карыйлар, эзлиләр: ис килә, көчәя бара, ә адәм заты күренми. Бу иснең сандыктан килгәнен аңлап алдылар да: «Адәм улы безне тотар өчен мәкер тозагы эшләтмәкче булган, хәйлә корган!» – дип кычкырышып, шунда ук илләрен ташлап диңгез киңлегенә чәчелеп киттеләр. Сандык алар шәһәре яныннан узып китте. Таһир бу хикмәтле хәлләрне шаккатып күзәтеп барды. Шул вакыйгага кадәр Таһир һәрчак артыннан килерләр, үзен коткарып алырлар, дип өмет итә, шул өмет дәрте белән күңелен юата, шуңа күңелен тук тота иде. Ниһаять, бу өмет тә азагына иреште. Өмет өзелү аңа җаны чыккандай бик көчле тәэсир итте!

Көн артыннан көн үтә торды. Инде сандык диңгезнең каршы як ярына якынлашып калды. Көннәрдән беркөн диңгез өстендә очкан чамадан зур бер кош, күңеленә Алла салуы буенча, сандыкны күрде, төшеп аны тырнакларына элде дә, оясына алып кайтты. Кошның оясы Каф тавы аръягындагы ерак илләрнең берсендә, Шат суы өстенә авып торган биек тау башында иде. Бу гомердә дә кеше аяк басмаячак таш кыя өстендә, җилләр иркендә Таһир инде үзен мәрхүм санарлык хәлдә иде. Кемдер кайчандыр юлыгып коткару ихтималыннан ул бөтенләй өметен өзде. Инде: «Мине суга, дәрьяга кайтар, бу кошлар җәбереннән имин кыл», – дип зарилык кыла башлады.

Киләсең дә, әй хушхәбәр нәүрүз җиле,
Кызганыч, – дип, – бичара Таһир хәле, –
Талпынасың, сыздырасың, сызланасың,
Яр сулышы булып мине кызганасың...
Хәстә күңелем сулышыңнан мәһрам таба. –
Сәлам җиткер, исеп бар да ярга таба...

Аллаһның кодрәте белән, нәүрүз (таң) җиле исеп, сандыкны кыядан дәрьяга төшереп җибәрде. Сандык, хәрәкәткә килеп, Шат суы белән тагын агып китте. Бу елга буенда гүзәллеге белән дөньяда тиңсез Багдад дигән шәһәр бар иде. Бу шәһәр тәхетендә ул вакытта Гадел исемле шаһ утыра, аның өч углы һәм өч кызы бар иде. Патшаның кече кызы гүзәл Маһым бер төнне төш күрде. Төшендә ул үзенең бер гүзәл егет белән бер гөлбакчада утырганын күрде. Әмма егет аның ягына карамый да, көнчыгыш якка текәлеп утырган. Маһым сылуның аның бу игътибарсызлыгыннан йөрәге кысыла һәм ул, аны үз ягына каратыр өчен һәм сөйләштерергә дип, төрле сораулар белән аңа мөрәҗәгать итә, имеш. Иртәсен бу төшен ул һичбер серен яшерми торган киңәшче-тәрбиячесенә сөйләде. Тәрбиячесе төшне юрап: «Көнчыгыштан бер егет килер. Ул синең күңелеңдә кайнар дәрт кузгатыр, әмма вәгъдәләшкән яры булганы өчен ул синең хисләреңне игътибарсыз калдырыр кебек», – дип уфтанды. Маһым күңелендә төштә күргән егеткә сөю хисе яралды. Көннәр үтеп ул шул дәрәҗәгә җитте ки, уфтанып, моңаеп: «Аны эзләп китми булмас, ахры», – ди торган булып калды.

Текстны басмага
***Мәсгут Гайнетдин** әзерләде.* ■

Кыйссаны тулысынча www.beznenmiras.ru сайтында укырга мөмкин.

«ФАТИХ АГА ИСЕМЕНӘ ДӘ ТЕЛ ТИДЕРГӘН ЧАКЛАРЫБЫЗ БУЛГАНДЫР...»

Хәсән Туфан

Такташны искә алу уңаенда, аның Фатих ага Әмирхановка мөнәсәбәте турында берничә сүз әйтеп үтәргә кирәк, дип саныйм.

Нинди дә булса кызык сүз, кызык-мызык хәбәр әйтеп сенсация ясарга яратучы язучыларыбызның берсе үткән ел башындагы бер җыелышта: «Ачуым килмәгәе, белмәгән кеше шуны белеп торсын!» — дип, җыелыш колагына пышылдап кына: «Такташ Фатих Әмирханны яратмый иде бит!» — дигән хәбәр әйтеп ташлаган булган.

Миңа Уфадан һәм Казаннан, әдәбият укучыларыбыздан килгән хатларда: «Безнең олы классикларыбызның гүзәл истәлегенә күләгә төшерә торган бу хәбәр дөресме?» — дип сораучылар, борчылучылар бар. Бу сорауга җавап бирү өчен безнең яшь чакларыбызны тагын бер кат искә алырга туры килә.

Без — Такташ та, мин дә — партия члены түгел идек. Ләкин үзебезне партиясез большевиклар, дип саный идек. Без һәрвакыт партиялеләр белән, Г.Гали, К.Нәҗми, Г.Нигъмәти, Г.Толымбайский һ.б.лар белән бергә, бер үк әдәби Казанда кайнап яшәдек. Партиялеләр ничек булса, без дә шулай идек. Без беркайчан да партиянең әдәбият мәсьәләләрендәге киңәшләренә, карарларына ревизия ясамадык, партиянең күрсәтмәләрен берсүзсез кабул итеп яшәдек.

Безнең якын дустыбыз Кутуй һәм күренекле замандашыбыз булган Нәкый Исәнбәт «Җидегән» мәсьәләсе буенча гаепләнгән вакытта, совет җәмәгатьчелеге нинди караштa булса, без дә шул караштa идек. Кутуйның һәм Исәнбәтнең гаепсезлекләре ачыла бару белән, безнең дә аларга мөнәсәбәтебез яхшырды, элеккеге хәленә кайтты.

Вульгар социологизм аяк терәп яшәгән чорда Ф.Әмирхан аганың «буржуа язучысы» дип аталуы безгә дә тәэсир итми калмады, билгеле. Аңа багышланган шигырьдә бу хәл ачык итеп әйтелгән дә иде инде:

Нигилизм аны — Әмирханны
Күмдерергә тели тереләй:
Ул, янәсе, аристократ әдип,
Без, янәсе, люмпен, плебей!

Һәркайсыбызга билгеле, Фатих ага, аяклары параличланган булу сәбәпле, чыгып йөри алмый иде. Ул гүя классикабызның аяклары бәйле Прометее иде, ә без — Такташ та, мин дә — дауга, иҗади давылларга керәбез генә, ә Фатих ага Әмирхан аннан чыгып килә, гомеренең ахырларына чыгып килә иде. Шул хәлдәге Фатих аганы ихтирам итмәүнең кощунство икәнен ачык төшенә идек.

Безнең әле үтә яраткан төс
Бары — кызыл, бары — ал гына, —

булганга, Фатих ага исеменә дә тел тидергән чакларыбыз булгандыр. Шуның өчен дә без Такташ белән аның өенә кергәндә гөнаһлылар кебек башыбызны иеп кердек. Ә ул, олы җанлы

кеше буларак, безне шелтәләмәде, тиргәмәде, ачык йөз белән кабул итте.

Гаепле дә аның каршында без,
Гөнаһлы да бераз, гомумән,
Олы җанлы кеше буларак ул
Каршылады ачык йөз белән.
Шәмен түгел, җанын ягып гүя
Яктыртты да безнең күңелне,
Бер караудa күреп алды кебек
Безнең хисләр яман түгелне.

Әмма Такташның яки минем нинди дә булса очраклы рәвештәге сүзебез яки чыгышыбыз Фатих агага ихтирамыбызны бервакытта да югалтмады, ихтирам итүебезне киметә алмады. <...>

Әйе, эгоистик ваклыкларга башын июче бәндә генә «Классиклар бер-берсен яратмыйлар иде!», «Бер-берсенә дошманнар иде!» дигән хәбәр тарата ала.

Фатих ага Әмирхан мәрхүм булганнан соң, 1926 елда (аны соңгы юлга озату якшәмбе көнгә туры килгән иде), алдан сөйләшенгән буенча, иртә белән Бишбалтадан Казанга Такташ янына килдем. Ирек мәйданына Фатих ага белән саубуллашырга Такташ белән бергә бардык. Бу көн безне, ничектер, шактый уйландырды. Тукайның якын дусты, киңәшчесе, соңгы могиканнарның берсе дөньядан, без яшьләргә калачак әдәби дөньядан китеп бара бит.

Такташ, Фатих ага мәрхүм булганнан соң, дөньяда дүрт ел яшәде. Без, шигырьдә яңалыкны алга әйдәргә теләүчеләр — шул еллар эчендә генә дә торган саен үзгәрә, яхшыра бардык. Олыларга — Галимҗан абый Ибраһимовка, Шәриф ага Камалга, Галиәсгәр Камал агайга — Тукайлар, Ямашевлар замандашларына бездә ихтирам һаман үсә барды.

Такташның нинди булса берәр

Һади Такташ. 1920 нче еллар ахыры-1930 нчы еллар башы



Хәсән Туфан. 1960 нчы еллар

Фатих Әмирхан. XX йөз башы

очраклы чыгышын, Такташның төп юнәлешеннән аерылып торган берәр очраклы хәрәкәтен аның төп сыйфаты итеп күрсәтергә теләү шагыйрьне бары тышкы яктан гына күреп калган булуны раслый.

Кыскасы, Такташ тормыштан Фатих ага Әмирханны инкарь иткән, аны дошман күргән хәлдә үтмәде, аны ихтирам иткән хәлдә китте.

Минем бер шигырьдә бу турыда менә шундый юллар бар:

Такташ белән (саф һавага)
Эрмитажга чыктык,
Элек яшь чагында
Әмирхан да йөргән бакчага.
Казанны да карамакчы булып,
Төшеп барган чакта Кольцога,

Күреп Такташ
Шактый биектәге
Нindiдер бер ачык тәрәзне,
— Сорап куйды:
Шуннан карап кына
Әвәлимсез һаман әсәрне?!

— Әйе, — димен, —
Язгалыйбыз кайчак
Шуннан гына караштырып та,
Сенсация ясап куяр өчен
Кызык хәбәр маташтырып та.

Син, янәсе,
Тукай киңәшчесен —
Әмирханны инкарь иткәнсең,
Гүргә, имеш,
Бер нигилист хәлдә —
Кире бәндә хәлдә киткәнсең.

— Әйткән әйтсен, әйдә, —
Диде Такташ,
Хатабызны төзәтә бирсен,
Кайбер бозык, фасикъ флюгерның
Ишарәсен күзәтә бирсен...

1939

ЗӘГЪФЕРӘН

Әхтәм Зарипов

(Мәшһүрләребез Хәсән Туфан белән Мөдәррис Әгъләмов турында бер хатирә)

Татарча чыгып килүче газета-журнал редакцияләренә барып керсәм, эш башында утыручы мөхәррирләр, минем сиксән яшем тулып узудан чыгыптырмы, мәрхүм замандашларым турында истәлекләр сорыйлар.

— Юк, — дигәч, ышанмыйлар.

— Кырык елдан артык әдәбият-сәнгать әһелләре белән кулга-кул тотынып эшләгән режиссёрның иҗатташлары турында хатирәләре булмау — гаҗәп күренеш, — диләр. Шулайдыр.

Нихәл итәсең — үзем дә гаҗәпләнәм. Көндәлекләр язып барылмаган, күренекле әдип яки сәнгатькяр белән очрашуга эш планы үтәү дип кенә каралган.

Бик үкенсәм дә, «узган эш кире кайтмый, үкен син, үл, ела»...

Ә очрашуларның хәтердә калганнары гына да бер калын китаплык булыр иде...

Әйтик, Мирсәй Әмирнең «Саф күңел» романы буенча телевизион спектакль әзерләгәндә әдипнең өендәге бәхәсләр; Фатих Хөснинең «Язмыш

шуклыгы»н куйганда: «Яңа әсәр язам, дип искесен ботарларга рөхсәтем юк», — дип аның киреләнүе, тынычлангач: «Маташтырып карагыз, ни-нәрсә чыгарырсыз икән», — дип ризалашуы; Атилла Расих, Әхсән Баян, Шәриф Хөсәенов, Әхмәт Ерикәй, Әмирхан Еники, Хәсән Туфан әсәрләре буенча телевидение яисә радиоспектакльләр әзерләгән вакыттагы сөйләшүләр күңелдә якты эз калдырсалар да, әңгәмәләрнең эчтәлеге хәтердә сакланмаган.

Шул эчтәлеге онытылган сөйләшүләрдән — Мөдәррис Әгъләмов һәм Хәсән Туфан белән очрашу хатирәсе. Мин аны «Зәгъфәрән» дип атарга булдым…

Безнең телевидение ихтыярына Мәскәүдән бер кварталга 30 минутлык кинотасма бирелә иде. Ул «киновставка» дип атала. Ягъни, студиядән күрсәтелүче спектакльләргә кирәкле (студиядән «живьем» күрсәтеп булмаган) эпизодларны кинога төшереп кушу — күрсәтү өчен

(әйтик, пароходта, самолетта яисә атта). Без шул тасманы план бүлегенә «спектакль өчен кирәкле эпизод төшердек» дигән ялган отчет биреп, үзебезгә мөһим, кирәкле булган нәрсәләргә файдалана идек. Хәзер шул «киновставкалар» — бүген иң кадерле истәлекләр. Җитмешенче еллар ахырында (булса кирәк) 30 минутлык кинотасманы Хәсән Туфанны Аккош күле дачасында каләмдәшләре белән бергә төшерергә дип бардык. Алдан хәбәрләшмәгәч, безне көтеп торучы юк иде. Ярый әле Мөдәррис Әгъләмовның анда яткан чагы икән. Ул ярдәм итте: Хәсән абыйлар урманга кереп киттеләр, кулларында көрәк иде, озак тормаслар, чәчәк казып алуга чыгалар алар, — диде.

— Букетны казып алынган чәчәкләрдән ясыйлармыни? — дигәч, Мөдәррис:

— Букет түгел — түтәл, — дип төзәтте.

Баксаң-күрсәң, Хәсән ага сирәк очрый торган чәчәкләрне яратып үстерә икән, аерым түтәле дә бар икән.

— Кунак килгәч, буш җибәрү килешмәсә дә, запасым юк, егетләр, гаеп итмәгез, — диде Мөдәррис. — Нәби абыйның «үзе куйганы» була торган иде дә, ул да бүген монда түгел — Казанда, кичкә килә.

Телеоператор Искәндәр Шәмсетдинов:

— Хәсән абыйда булыр әле, кыенсынмасаң, чакырып кил, — дип шаяртмакчы булды.

Мөдәррис бу сүздән соң чын-чынлап үртәлеп:

— Аның алдында бу турыда сүз чыгарсагыз, Аккош күленә юлыгыз киселер, — диде дә урманга кереп китте.

Бераз вакыт аңгы-миңге килеп вакыт уздыруга, кояштай балкып, Хәсән абый белән Мөнҗия апа күренде. Аларга утынлык чыбык-чабык кочаклаган Мөдәррис ияргән иде. Без шунда ук кинокамераны эшкә җикмәк булдык. Мөдәррис кочагындагы утынны «ялт» итеп читкә атты.

— Нигә ташлыйсың? Болай «образный»рак ич! — дидем мин.

— Татар язучыларының газы беткән икән димәсеннәр, болай да юкны бар итеп сөйлиләр.

Без кинога төшерүне дәвам иттердек. Сүз, әлбәттә, алар казып алып чыккан үсемлек — үлән турында барды.

— Хәсән абый, бу корыган үлән сабагын ташлап, кулыңа ромашка чәчәге тотмыйсыңмы? Зәвыклы да, матуррак та булыр иде.

— Бу «корыган үлән сабагы» дигәнең — минем күптән эзләгән гөлем ул. Урман эчендәге аланга ничек, каян килеп эләккәндер, ничек мин аның чәчәк аткан чагын күрмәгәнмендер — анысы башка мәсьәлә, бүген аны очратуым абага чәчәге атуны күрүдән кыйммәтрәктер.

— Аның суганын ашарга ярыймы соң? — диде Искәндәр ага Шәмсетдинов.

Хәсән абыйның бу сорауга рәнҗегәнен тасвирларга тел байлыгым җитмәс. Мөнҗия апа аны «җитте, киттек» дигәндәй култыклап алуы күз алдымда.

— Туктагыз инде, китмәгез, үлән турында бер-ике сүз әйтегез, зинһар, нәрсәгә файдасы бар төнәтмәсенең? Томауданмы, ашказаны капризланганда эчәләрме?

— Эчмиләр! Иснилəр! Хушбуй ясаганда катыштыралар аны. Кәнфит, прәнник пешергәндә тәм өчен өстиләр! Чөнки... чөнки зәгъферән бу. Бездә үсә торганнарының исе-тәме ничектер, минем гомерем узган теге якларда моны җыеп әптиккә бирсәң, алмашка кыйммәтле дару бирәләр иде... Хәсән абый, кызганнан-кыза барып, зәгъферәнне мактады.

— Сез аның чәчәк аткан вакытында аппаратыгызны алып килегез, сабагында озак утырмый ул — тиз шиңә, иң кыйммәтле серкәсе «пестигендә» генә була. Шул нәрсәсе өчен аны җыялар... Ә сез суганын ашарга җыенасыз... Тамак колы булмыйк инде, җегетләр...

Мөдәррис шунда, безне якламакчы булып, нидер әйткән иде, Хәсән абый сүз агышын кинәт шигърияткә күчерде:

— Үләннәр дә күп, аларның чәчәкләре дә төрле-төрле. Шигырь язучылар да күп, шигырьләре дә чыга килә. Әмма һәр шигырь язган кеше шагыйрь булмаган кебек, һәр шигырь — әсәр түгел. Шигырь әсәрләндерергә тиеш. Чәчәкләргә килгәндә дә шулай — әсәрләндерергә тиеш: матурлыгы белән, исе, тәме белән.Зәгъферәнгә Ходай һәммәсен биргән. Гомерен генә кыска иткән. Иртән чәчәк атса, кичкә коела.

Шуннан соң Хәсән абый, ачылып китеп, хәзерге шагыйрьләр иҗатына кагылып, фикерләре белән уртаклашты, әйтеп узганымча, мин ул фикерләрне теркәп куймаганмын. Шунысы гына уелып хәтердә калган:

— Менә безнең Мөдәррис тә, Зөлфәт тә, Кадыйр да *(Кадыйр Сибгатуллин. — **Ред.**)* зәгъферәнгә тиңләрлекләр. Шигырьләре матур да, соклангыч та. Һәркайсының үз бизәге, үз төсе.

Мөдәрриснең тыйнаклык күрсәтүе булдымы, шаяртуымы:

— Бизәкле, исле-төсле шигырь язудан ярый әле безне Хәсән абый саклый. Шигырьнең шигырь генә булганы яхшы! — диде дә китәргә рөхсәт сорады.

Ул киткәч, без әле Хәсән абыйларда чәй эчеп, әңгәмә корып утырдык. Шул арада дачага башка әдипләр дә килделәр. Җомга көн иде. Барысын да кинога төшереп, монтажлап студиянең фильмотекасына тапшырдым. Күп күрсәтелде алар.

Төрле әдәби тапшыруларда шул кинокадрларны ваклап-өзгәләп куллану очракларының шаһиты булдым. Хәсән Туфанның 100 еллыгы уңае белән үзем төшергән шул кинокадрларны эзләтсәм дә, аларны таба алмадылар, «юк», диделәр.

Гамьсезлек нәтиҗәсендә юкка чыкканмы, көнчелектәнме? Әллә икесе дә бармы? Бүген миннән бер редакциядә:

— Хәсән Туфан белән Мөдәррис Әгъләмовның фоторәсеме юкмы? — дип сорадылар.

— Юк! — дип әйтә алмыйм, чөнки кинога төшерүем факт. Ул инде мең фото дигән сүз. «Бар», дияр идем — кайдалыгын белмим. Бәлки, кемдер киләчәк өчен яшереп асрыйдыр?! Шул көн истәлеге итеп, Хәсән абыйда чәй эчеп чыккач очраткан язучылар белән бергә төшкән «үзешчән» фотоны гына тәкъдим итә алам. Хәсән абый: «Зәгъферәнне утыртасым бар», — дип,

безнең белән бергә сурәткә төшмәде. Мөдәрриснең әллә инде китүе чын иде, әллә тыйнаклыгы муллыктан булдымы — яңа килгән әдипләр янына чыкмады. Бүген үзем Хәсән абый яшенә җитеп килгәндә ул утырткан зәгъферәнне барып күрәсем килә, һаман юл төшми. Түтәле исәнме икән?

Ниһаять, «җай чыгарып, юл төшереп» бардым мәрхүм шагыйребезнең эзләре сакланырга тиешле «Аккош күле» дачасына… Тик… Хәсән абыйның йортын да, ул утырткан күпьеллык чәчәкләр түтәлен дә тапмадым.

Әдипләр дачасындагы ике шагыйрь йорты утырган урынны берләштереп, анда зур, мәһабәт йорт салып куйганнар, йозак элгәннәр…

— Кем йорты бу? — дип сораган идем, каравылчы:

— Хуҗасыныкы! — диде дә, өстәмә сораулар бирелүдән качып, китәргә ашыкты. «Озак юанмагыз, шәхси милек!» дигәне соңгы сүзе булып, «Ни белән юанырга?» — дигән сорау һавада эленеп калды.

Юансак та, классик шагыйребез Хәсән Туфан фатихасы белән иҗат итүче шагыйрьләребез булудан һәм аларның шигъри түтәлләрендә зәгъферәннәр чәчәк атуына өметләнүдән генә юанырбыздыр, ахры.

11 ноябрь, 2015 ел ■

Кайтаваз

«Безнең мирас»ның быелгы август санында, «Муса Җәлилнең яңа табылган шигырьләре» искәрмәсе белән, Гобәйдулла абзый Салихов (элеккеге легиончы) Седльце концлагеренда күчереп алган алты шигырь укучылар хөкеменә тапшырылган иде.

ҖӘЛИЛНЕКЕМЕ СОҢ АЛАР?

Азат Сөнкишев

Җәлилнең 1942 елда Седльцеда әсир төшүе турында бернинди чыганакта да искәртелми. Ә менә икенче бер патриот-язучы — Абдулла Алишның бирелә газап чигүе берничә хатирәдә телгә алына, ул гына да түгел, әдип **«Тормыштан хроникалар»** дигән язмасында бу хакта үзе белдерә. Г.Кадыйров истәлекләренә караганда, Җәлил белән Вустрау лагеренда очрашырга берничә ай кала ук, ягъни 1942 елның көзендә, Алиш шигъри тәлгәшләр язган, тоткынлыктан качу турында хыялланган; аның күңел җимешләре, аеруча **«Туган илем — Идел-Урал»** шигыре (**«Алиш абый җырлары»** исеме астында) әсирләр арасында бик популяр булган. Кайбер тоткыннар (Г.Кадыйров, Н.Терегулов, Т.Гыйммранов) Алишның ул чор шигъриятен үз дәфтәрләренә күчереп, соңрак туган илгә алып кайткан. **Газыйм Кадыйров, Нигъмәт Терегулов** күчергән шигырьләрнең байтагы патриот-әдипнең җыентыкларында дөнья күрде инде, калганнары Рафаэль абый Мостафинның **«Җәлилчеләр»** китабында (1988) **«Алишка нисбәт ителгән шигырьләр»** дигән искәрмә белән басылып чыкты. Күп тикшеренүләр һәм стилистик анализлардан соң әзтабар-язучы бу әсәрләрнең авторын тәгаен ачыклады һәм алар 2008 елда чыккан ике томлыкка һич шик-шөбһәсез Алиш шигырьләре буларак кертелде. Шунысы кызык: араларында Гобәйдулла абзый күчереп кайткан ике шигырь дә бар! **«Почта юлын һәр көн саен таптыйм...»** дип башланганы — китаптагы нөсхә белән сүзгә-сүз диярлек тәңгәл килә! **«Туган ил сулары»** исемлесе **«Идел буе»** шигыренә гаҗәеп рәвештә аваздаш... Бу шигырьне фәкать Идел-Кама буенда үскән кеше — Абдулла Алиш кына яза ала! **Рафаэль Мостафин** күрсәткәнчә, шигырь моңарчы Җәлилнеке дип уйланылган...

Тагын бер нәрсә бар: Гобәйдулла абзый күчереп кайткан шигырьләрнең икесендә автор *уллары* турында яза. **«Дустыма»** шигырендә *«Әткәй-әнкәй, диеп иркә күздән/ Улларыбыз күзгә бакканда...»*, **«Сөйгән дустыма»** шигырендә *«Улларымның гүзәл анасы...»* дип басым ясап әйтелгән. Билгеле ки, Җәлилнең бер Альберт улы гына булган, ә менә Абдулла Алишның ике дәвамчысы калган — Алмаз, Айваз, бу — әдәбиятны беркадәр белгән һәркем өчен мәгълүм. Алишның әсирлектә иҗат ителгән, горурлык хисләре белән тулы **«Ике улым бар»** исемле шигыре дә күпләргә таныштыр. Ул улларын өзелеп яраткан. Алишның соңгы, хушлашу хатында: *«Сезнең барыгызны да кысып, кысып үбәм. Бигрәк тә Алмазымны һәм Айвазымны. Аларны укытырга тырышыгыз»*, — диелгән...

Ягъни, Гобәйдулла абзыйның бу шигырьләрне Седльце концлагереннан күчереп алып кайтуы һичнинди шикшөбһә уятмый. Ләкин Җәлилнекеме соң алар?



Алишевлар гаиләсе. Сулдан: Абдулла, Айваз, Алмаз, Рокыя. 1941 ел

Кабатлап әйтәм: бу вакыт, ягъни 1942 елның көзендә, Җәлил Седльце лагеренда булмаган! Югыйсә, алар Алиш белән очрашмый калмас, бу факт берәр шигырьдә яисә берәр хатирәдә, истәлектә телгә алынмый калмас иде!

Уйлавымча, төрле сәбәпләр аркасында, Гобәйдулла абзый Алишны Җәлил дип бутаган, шул рәвешле ялгышкан, Алиш шигырьләрен «Җәлилнеке» дип күчереп кайткан!

Рафаэль Мостафинның «Җәлилчеләр» китабыннан күренгәнчә (**«Ниндидер билгесез бер шагыйрь»**, 1988 ел, 197-201 битләр), мондый ук буталчык баштарак та булган икән. Элекке легиончы, Эстәрлетамак шәһәрендә яшәп, шунда дөньядан кичкән **Тәлгат Гыйммранов** Едлинода чакта Берлиннан ниндидер бер кешенең килеп йөрүе, легиончылар яшәгән баракларда булуы, кемнәрнедер күреп сөйләшүе, әсәрләр укуы, дәфтәренең бараклар буенча кулдан-кулга йөрүе, кайбер әсирләрнең, шул исәптән үзенең дә, аларны күчереп алуы турында хәбәр итә. Соңыннан, Җәлил исеме бөтен дөньяга шаулый башлагач, байтагы «Җәлилнеке» дип матбугатта чыга. Монда Тәлгат абзыйның гаебе юк:


Советский Союз | Sowet Union
г. Казань | Stadt Kasan
ул. Дзержинского 18/19, кв-1 | Dzerschinski Str. 18/19
Тюльпановой Рукие | Stile №1 Tulpanowa
Rukia

Моя дорогая подруга жизни, любимая мать, мои дорогие дети, родные и друзья! Шлю Вам, быть может последний, свой пламенный привет.

Я, Алишев Абдулла Бареевич, писатель А. Алиш, красноармеец 1001 стрелкового полка будучи в окружении, попал в плен 12-X-41 г. под Брянским. Путешествуя по различным лагерям подконец попал в Чехословакию, где работал на заводе шлифовальщиком. В конце 1942 г в лагере близ Берлина встретил поэтов: Мусу Жалиля, Р. Саттара (из газеты «Кз. Әшьләр») В августе 1943 г. был арестован по обвинению в распространении листовок среди татарских военно пленных, так наз. легионеров со мною арестованы были следующие лица
1. Муса Жалиль, поэт из Казани,
2. Гариф Шабаев - фин. работник из Ташкента
3 Сайфуль Мулюков - зам. наркома торговли Узб.
4. Фуат Булатов - инженер из Казани
5. Ахмет Симаев - журналист из Москвы
и человек 20-25 из легиона.
Мы просидели полгода в Берлинской тюрьме. Суд должен состояться 7-II-44 г. в Дрездене. Пришель боролся и ушел Такова уж наша видно судьба мы остаемся до последнего вздоха верными нашему народу. Ах, как хочется жить, увидеть Вас, мои дорогие, и рассказать все пережитое (Р. Саттар в июне 43 г. сбежал, его судьба неизвестна) Много написанных и обдуманных вещей уходят с нами в забытье
Целую всех крепко, крепко (особенно моего Алмаза и Айваза, постарайтесь дать им образование. Прощайте Ваш верный сын.
28-I-44 супруг и друг: А. Алиш

Абдулла Алишның Берлин төрмәсендә язган хушлашу хаты

«Башта өйрәнергә, яхшылап ачыкларга кирәк әле!» — дип торуына кармастан, сенсация артыннан куучы журналист халкы, *«Җәлилнең яңа шигырьләре»* дип, аларны тизрәк газеталарга бирергә ашыга. Шул рәвешле, Т.Гыймранов дәфтәрендәге берничә шигырь, аерым алганда **«Иркәм хаты»**, **«Идел буе»**, **«Минем антым»**, **«Ана уйлары»** үзгә автор исеме белән дөнья күрә, тикшерә башлагач кына дөресе — шигырьләрнең Абдулла Алишныкы булуы, кайберләренең **«Идел-Урал»** газетасында басылуы да ачыклана. Имзасы «А.А.» яки «Галиша» дип куелган. Рафаэль Мостафин Тәлгат Гыймрановтан татар легионына һәм шигырьләргә кагылышлы бик мөһим мәгълүматлар алып кала. *«Ул больницада ятуына карамастан, без бер сәгать чамасы сөйләшеп утырдык,* — дип яза бу хакта Рафаэль Мостафин. — *Тәлгат, нигездә, элек сөйләгәннәрен кабатлады. Шуннан соң мин аның каршына җәлилчеләрнең фоторәсемнәрен китереп салдым. Алиш рәсемен күрү белән ул сискәнеп китте:*

— Менә шушы кеше... Нәкъ үзе... Минем белән аралашкан шагыйрь... Әйе, әйе, рәсемен күрсәткән булсалар, әллә кайчан ук таныган булыр идем. Димәк, «ниндидер билгесез шагыйрь» Абдулла Алиш булып чыкты».

Иманым камил, Гобәйдулла абзый үзе исән чакта кемдер аның каршына Алиш рәсемен китереп куйса, ул да сискәнеп китеп:

— Менә шушы кеше... Нәкъ үзе... Шуның шигырьләрен Седльце концлагеренда күчереп алдым, — дияр иде...

«Алиш шигырьләре Муса Җәлилнең шул чорда язган шигырьләре белән гаҗәеп дәрәҗәдә аваздаш, — диелгән Рафаэль Мостафинның китабында. *— Алар икесе дә җиңү көне килеренә ышанган һәм шул көнне аз гына булса да якынайту өчен кулларыннан килгәннең барысын да эшләгән...»*

21 август 2015 ел

Абдулла Алиш
КӨТМӘ ИНДЕ, КӨТМӘ...

(Әнигә багышлыйм)

Ана үрдәк бәбкәләре белән,
Ә син ялгыз үзең барасың,
Син көнләшеп аның бәхетеннән,
Моңсу гына озатып каласың.

Кайда китте синең балаларың?
Арыслан күк батыр улларың?
Өмет белән һаман күзәтәсең,
Кайтырлар, дип, киткән юлларын.

Былтыр койган алма кakларын син,
Чикләвекләр җыеп киптереп:
— Аларга! — дип, һаман саклыйсыңмы
Сагыш белән көтеп, тилмереп.

Төшләреңдә һаман алар белән,
Көндезләрен укып хатларын,
Теткәләнгән кәгазь битләренең
Һәрбер сүзен инде ятладың.

Язлар килер чәчәк исе бөркеп,
Сыерчыклар кире кайтырлар,
Яңарырлар шунда йөрәгеңдәге
Бертуктаусыз янган кайгылар.

Бал кортлары очар, күбәләкләр
Берсен-берсе куышып уйнарлар,
Чәчәкләргә күмелеп торсалар да,
Куандырмас сине тугайлар.

Җир тетрәгән давыл уты, бәлки,
Карлар белән эреп югалыр,
Дөнья тынып калыр. Йөрәкләрдә
Кавышу хисе кабат кузгалыр.

Өчесенең берсе кайтмасмы, дип
Син көтәрсең һаман аларны,
Ишек каккан саен кочакларга
Әзерләнеп сөйгән балаңны.

Көтмә инде, көтмә, изге карчык,
Җир куенында ята улларың,
Чәчәкләргә биреп, илгә булган
Мәхәббәтле керсез уйларын. ■

«ЭЛЕК ДӘРЕСЛӘРДӘ УКУ ШИГЫРЬ ӘЙТҮ БЕЛӘН БАШЛАНА ИДЕ...»

Бер бәйләм беркетмә

12 сентябрь, 1969 ел.

Татарстан Язучылар союзының гомуми җыелышы

Катнашалар: 84 кеше.

Килмәгәннәр: 31 кеше. Шулардан 22сенең сәбәпләре җитди.

Җыелышны алып бара — **Ибраһим Гази.**

Көн тәртибе:

1. Балалар әдәбиятының бүгенге торышы.

2. РСФСР язучыларының III съездына делегатлар сайлау.

Президиум:

Идарә составы һәм КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире иптәш **М.М.Мусин** (*Мөдәррис Муса улы Мусин, 1923-1994, культура бүлеге мөдире булып 1969-1984 елларда эшли. —* ***Л.Л.***).

Беркетмәләр язарга **Марс Шабаев** белән **Рәдиф Гатауллин (Гаташ)** билгеләнә.

Беренче көн тәртибе:

Балалар прозасы турында сүз **Шамил Рәкыйповка** бирелә (аның докладын аерым теркәлә*).

Балалар поэзиясе буенча сүз **Шәүкәт Галиевкә** бирелә (докладын аерым теркәлә).

Балалар драматургиясе турында сүз

Язучыларның чираттагы җыелышыннан соң.
Рәсемдә: утырганнар – Нәби Дәүли (сулдан беренче), Нәкый Исәнбәт (уңнан бишенче), Хәсән Туфан (уңнан дүртенче); икенче рәттә – Галимҗан Латыйп (уңнан алтынчы), Зәки Нури (уңнан җиденче) һәм башкалар. Гыйнвар, 1966 ел

* Ш.Рәкыйповның әлеге чыгышы язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасында (1970) басылган булган. Редакция аны журналның киләсе санында тәкъдим итәргә ниятли.

Ибраһим Гази

Бату Мулюков



Рабит Батулла

Туфан Миңнуллинга бирелә (докладды аерым теркәлә).

Балалар поэзиясе буенча сүз **Разил Вәлиевкә** бирелә (докладды аерым теркәлә).

Нәниләр әдәбияты турында сүз **Хәмзә Зариповның** докладын уку өчен **Вакыйф Нуруллинга** бирелә (доклад аерым теркәлә).

Фикер алышулар:

Бату Мулюков (Бату Гатаулла улы Мөлеков, 1928-1999, композитор). Иптәшләр, докладларыгызны дикъкать белән тыңладым. Бик көчле бара. Мин фәкать музыка өлкәсенә тукталам. Үткән ел балаларга музыкаль тәрбия бирү турында махсус доклад булды безнең съездда. Дмитрий Кабалевский чыкты. Балаларның тиешенчә җырламавы турында сүз барды. Бездә дә шул ук хәл бит, иптәшләр. Мәктәп җырласа, халык җырлый. Ә без моның белән мактана алмыйбыз. Җыр укытучыларыбыз аз. Музыкаль тәрбиягә игътибар җитми. Нота белән эш итә белүче кадрлар юк дәрәҗәсендә. Бездә музыка күп языла. Балалар өчен пластинкалар чыгару теләге белән мин җырларны барладым. Тема ярлылыгы: шаян песи, маэмай, бишек җырлары… Баланың эчке тормышын чагылдыру җитми. Шагыйрьләребез яңарак темалар тапсыннар иде һәм баланың яшь аермаларын искә алсагыз иде. Патриотик җырлар, шаян такмаклар кирәк. Ансамбль өчен язасы иде. Безнең композиторларга балалар өчен язу бурычы куелды. Әйдәгез, бергәләп эшлик. Бәлки конкурс тәкъдим итәргә кирәктер? Культура министрлыгы уйласа икән. Бергә иҗади дуслыкта эшләсәк иде, иптәшләр!

Роберт Батуллин (Рабит Батулла, 1938). Биредә әйтелгән сүзләрем докладлар тәэсирендә туды. Менә Бату Мулюков иптәшкә сюжетлар: Алиш — «Үрдәк», Тукай — «Мияубикә», Такташ — «Тәүфыйклы песи», Илдар Юзеев — «Соңгы сынау». Мәһабәт әйберләр тудырып булыр иде. Төрле шагыйрьләр, язучылар бар. Тираж кимүнең сәбәбе — язучыларның авылга сирәк чыгуында, дип әйтте Шамил Рәкыйпов. Алай гынамы соң? Мәктәпләрнең язмышы борчымый безне. Ә бит безнең язмыш — киләчәк кулында, киләчәк язмыш — безнең кулда. Яшьләргә ышанмау, өлкәннәрдән соң талантлы яшьләр килми, дип уйлаучыларыбыз да юк түгел. Поэзиядә Хәсән Туфан, Сибгат Хәким яшьләрне кайгырткан кебек, прозада да булса икән шундыйлар! Чит өлкәләрдә яшәүче кадрлар белән эшләмибез. Ә кирәк иде. Драматургия… без бит тулысы белән үзешчәннәр өчен язабыз. Ә театр юк. Без яшь буынны тәрбиялибез. Ә бит борчылу җитми. Кырынды *(Әгерҗе районындагы авыл. — **Л.Л.**)*

мәктәбе китапханәсе янды, җибәрик китапларыбызны!

Тормышчанлык, дибез. Тавык та — тормыш. Ләкин аны өстәлгә «потрохалары» белән кертмибез. Китаплар да шулай бит! *(Чыгышын канатлы сүзләр белән тәмамлый.)*

Фирдәвес Болгарская *(Фирдәвес Хәмит кызы Болгарская, 1919-2004, журналист, педагог, тәрҗемәче, Татарстан китап нәшриятында уку-укыту бүлеге мөдире булып озак еллар эшли, ире — композитор Әнвәр Бакиров, әнисе — артистка Гөлсем Болгарская. — **Л.Л.**)*. Докладлар бик тирән, төпле, җанлы. Бигрәк тә Шәүкәт Галиев дәреслекләр хакында бик белеп сөйләде. Рәхмәт аның тәнкыйтенә. Андагы шаблоннарга безнең үзебезнең дә эчебез поша. Ни кызганыч, язучылар дәреслекләр өчен язмый, безгә ярдәм итми. Бәлки дәреслек төзүдә катнашу кирәктер. Программа темасына язылган әйберләр таба алмыйбыз. *(Дәреслекләр турында конкрет сөйли һәм булышуны сорый.)*

Ренат Харисов *(Ренат Харис, 1941, «чыгышы аерым бирелә», диелгән. Кызганыч, ул чыгышны табып булмады. — **Л.Л.**).*

Баян Гыйззәт (Фәтхелбаян Нурлыгаян улы Гыйззәтуллин, 1918-1991, театр белгече, тәнкыйтьче). Балалар театры мәсьәләсе турында берничә сүз. Башка жанрларны читкә какмый гына театрны алыйк. РСФСРда бердәнбер балалар театры Чуашстанда. Һәм аклана икән финанс ягыннан да. Бездә дә булса икән ул. Театр училищебыз да бар. Артистлары да табылыр иде. Балалар театры мәсьәләсен Союз яңадан күтәрә, дип карарга кертик.

Икенче мәсьәлә. Кинофильмнар мәсьәләсе. Сценаристлар юк, дигән сылтау белән сузылып килә. Язарга теләгән иптәшләр язсын. Союз бу эш белән шөгыльләнсен.

Баян Гыйззәт чыгышыннан соң тәнәфес игълан ителә.

Язучылар кабат җыелгач, **Идрис Туктар** (Идрис Ильяс улы Туктаров, 1896-1982, язучы, тәрҗемәче) сүз ала. Үз чыгышында ул Разил Вәлиев чыгышындагы күп нәрсәләр, җөмләдән, Галимҗан Латыйпка карата булган тәнкыйть белән килешмәвен әйтеп узды. Шулай ук ул яшьләргә һәм бүген каралган мәсьәләләргә кагылышлы нәрсәгә — үз-үзеңне тәрбияләргә кирәклегенә басым ясады; бу мәсьәләгә ачыклык кертү максатыннан Ковалевның «Үз-үзеңне тәрбияләү» исемле китабын *(А. Г. Ковалев. Самовоспитание школьников. — Москва: Просвещение, 1967. — 159 с. — **Л.Л.**)* мисалга китерде. Балаларда чын кешелек сыйфатларын тәрбияләүдә язучыларның һәм педагогларның алда торган әһәмиятле бурычларына тукталып үтте.

Яшь язучы, «Ялкын» журналы редакторы **Роза Хафизова** (Роза Сәет кызы Хафизова, 1929-2005) үз чыгышында бүгенге җыелышның файдалы икәнен әйтеп уза; күптән түгел булып узган, язучыларның балалар әдәбиятында катнашуы турындагы ачык партия җыелышын искә ала. *«Бу җыентыктан алган сабакка «Ялкын» һәм «Яшь ленинчы» кушылды, педагогика һәм әдәбият берлеге үсә төште кебек»*, — ди. Моңа каршы килгән факт итеп, Хафизова «Яшь ленинчы» газетасында басылган «Карун һәм Сандугач» (Рөстәм Мингалимов әсәре) әкиятен тәнкыйтьләде. «*Мәгариф министрлыгы да язучылар белән элемтәдә булырга тиеш. Нәниләр өчен махсус журнал кирәк. Журнал таралачак, Мәгариф министрлыгы хуплаган хәлдә. «Октябрь баласы»ның кабат туучы яхшы булыр иде»*.

Шулай ук Хафизова китап сату мәсьәләсенә, бигрәк тә нәниләр өчен китап сатуның зәвык белән оештырылмауга тукталды, махсус витрина, сайлау өчен мөмкинлекләр булдырылып,

нәниләр китапларын сатуда яңалыклар булырга тиешлегенә басым ясады.

Шагыйрь **Галимҗан Латыйп** (Галимҗан Шакирҗан улы Латыйпов, 1912-1986) исә бу җыелыш, докладлар, алардагы мәсьәләләрнең дөрес куелу-куелмауга тукталды. Яшьләр ясаган докладлар — бүгенге, шулай ук үткән ел йомгакларына багышланганнары белән кушылмавын әйтеп, аларда объективлык җитмәвенә тукталды. Мисалга, Разил Вәлиевнең докладын алып, шартлы әдәпсезлектә гаепләде; шулай ук докладларда макталып телгә алынган Шәүкәт Галиевнең кайбер шигырьләрен тәнкыйть итте.

Классик язучыбыз **Нәкый** ага **Исәнбәт** (Әхмәтнәкый Сираҗетдин улы Закиров, 1899-1992) сүз алып, әүвәл китаплар сату мәсьәләсенә тукталды; китап һәм бизәлеш тәңгәллеге булмауны әйтеп, үрнәккә Украина, Молдавия һ.б. республикаларда басылган китапларны китерде. Шулай ук элек чыккан, үзебезнең матур эшләнешле китаплардан Тукайның «Юаныч» китабын сурәтләде: матур эчтәлек, матур форма!

Балалар әдәбияты һәм тәнкыйть мәсьәләсенә кагылып, Нәкый ага кимчелекле яклардан берсе итеп, әдәби тәрбиянең җитмәвен әйтте. «Элек дәресләрдә уку шигырь әйтү белән башлана иде; җыр милли иде. Укучыда шигырьгә карата зәвык үсә иде. Ә хәзер? Мәсәлән, Латвиядә әдәбиятның иң күп таралган төре — шигырь. Бездә алай түгел. Үз телебез артыкланды.

Язучы һәм нәшрият мәсьәләләренә тукталып, Н.Исәнбәт нәшриятның балалар өчен китаплар чыгаруда җитәрлек эшләмәвен дәлилләп, үз китаплары язмышы турында сөйләде. Шулай ук электән балалар әдәбиятына күп көч куйган Гали Рәхим (1892-1943), Зыя Ярмәки (1887-1965), Фәхрелислам Агиев (1887-1938), Миргазиз Укмасый (1884-1948), Х.Сәлимовларның китаплары басылмавын әйтеп, *мирас мәсьәләсенә* ишарә итте. Дәреслекләрдә начар шигырьләрнең булуын аяныч хәл икәнен әйтеп, язучыларны бу эшкә җитди карарга чакырды.

Нәниләр өчен журнал һәм балалар театры мәсьәләләренә кушылып, Нәкый ага Исәнбәт бу мәсьәләдә активлыкка чакырды, конкрет эшләргә юл күрсәтте.

Шагыйрь **Зәки Нури** (Зәки Шәрәфетдин улы Нуретдинов, 1921-1994) җыелыш дәвамында тәкдим ителгәннәрдән чыгып, төзелгән карарларны укый:

1) Н.Крупская исемендәге премия — балалар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләр өчен бүләк оештыру мәсьәләсен конкрет куярга;

2) Газеталар белән эшне ныгытырга.

Йомгаклау сүзе белән Язучылар союзы председателе **Ибраһим Гази** (Ибраһим Зарифулла улы Мингазиев, 1907-1971) чыкты:

— Җыелыш дәвамында шул сизелә: моннан соң, бүген кабул ителгән карарлардан башлап, җитешсезлекләр булмас кебек. Үзебезгә күбрәк эшләргә, оештырырга кирәк. Материал, тема күп. Мәсәлән, Девятаев турында ник язмыйбыз? Нефть темасы... Ә нәрсәбез бар бу турыда балалар өчен? Балыкчылар, спортчылар. Әйтик, Рәшит Нәҗметдинов...

Шулай ук И.Гази яшь буынны тәрбияләүнең әһәмиятенә басым ясап, дәреслекләр мәсьәләсенә туктала. Үзебездән күбрәк игътибар сорала, ди.

Балалар өчен журнал, театр буенча тәкъдим-фикерләргә кушыла. Ахырда, мәктәпләр — уку, русча-татарча багланышлар һәм мәктәпләр мәсьәләсенә ныграк кагылып үтә.

Иң соңыннан беренче көн тәртибе куйган мәсьәләләр буенча КПСС өлкә комитеты вәкиле иптәш **М.М.Мусин** чыгыш ясый:

— Беренче: журнал мәсьәләсендә



Нәби Дәүли

Идрис Туктар

Зәки Нури

иптәшләр белән риза. Обкомда каралган, әмма... кәгазь мәсьәләсе ни дияр? Катгый карар юк. Башка журналлар буенча да сүз кирәк: «Казан утлары»ның күләме артты, инде «Совет мәктәбе», «Чаян» һ.б. турында уйларга кирәк.

Икенче: китап тарату, Таткниготорг, нәшрият, сәүдә оешмалары белән бергә бу эшне яхшыртырга кирәк.

Өченче: театр мәсьәләсендә дә килешәм. Обкомда бу мәсьәлә дә каралган. Хәл ителер, дип ышаныйк.

Түбән Камага да театр кирәк. Күчмә театр мәсьәләсе дә җитди.

Пластинкалар (тәлинкәләр — балалар өчен шигырь-җыр-әкият һ.б. белән) мәсьәләсен һәм шуңа охшашлыларны хәл итү мөмкин булыр.

Балалар әдәбияты секциясенең эшен — вәкаләтен зурайтуны — Язучылар союзында хәл итәрсез.

М.Мусин җыелыштан риза булуын, докладлар белән килешүен әйтә, кайбер мәсьәләләрдә тәнкыйте дә бар: мәсәлән, чыгышларда лениниана мәсьәләсенә азрак тукталдылар һ.б.

Беренче көн тәртибе шуның белән тәмам.

Икенче көн тәртибе: РСФСР язучыларының III съездына делегатлар сайлау. Партбюро исемлек игълан итә. (Исемлек аерым, партгруппа җыелышы беркетмәсендә теркәлгән, шулай ук сайлау комиссиясе беркетмәсендә дә бар). Исемлекне тикшерү вакытында түбәндәге тәкъдимнәр булды:

Хәсән Туфан Шәүкәт Галиевне дә исемлеккә кертергә тәкъдим итте.

Нәби Дәүли сайланачак иптәшләрнең үз эшләренә җитди карауларын сорый, исемлеккә Мөхәммәт Садрины да теркәүне сорый.

Ренат Харисовны исемлектә калдыру мәсьәләсендә М.Садри, Н.Дәүли каршы чыгыш ясый. Х.Туфан, С.Хәким, Р.Гатауллиннар яклап чыга. Ике каршы тавыш белән Р.Харисов исемлектә кала. М.Садри кертелми. Башка иптәшләр тавышка кую вакытында каршылыксыз үтә.

Яшерен тавыш белән сайлауга булышлык һәм нәтиҗәләрне саклау өчен комиссия сайлана: Ә.Маликов, З.Шаһиморатов, Ю.Белостоцкий.

Бюллетеньнәр таратыла.

Сайлау комиссиясе нәтиҗәләрне игълан итә. *(Санау комиссиясенең делегатлар сайлау буенча беркетмәсе аерым теркәлә. Кызганыч, ул беркетмә сакланмаган. — **Л.Л.**)*.

Җыелыш председателе: (И.Гази)
Беркетмә язучылар: (М.Шабаев)
(Р.Гатауллин)

*Беркетмәне **Ләбиб Лерон** укыды*

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

ГАЙНАНОВ РАШАТ РӘШИТ улы (1925-1990), әдәбият галиме, текстолог, журналист, тәнкыйтьче, тәрҗемәче. Г.Тукай иҗаты буенча фәнни эзләнүләрне узган гасырның илленче елларыннан башлый. Т. әсәрләренең Икенче дүрттомлыгын (1975-1977) һәм биштомлыгын (1985-1986) төзи. XX йөз башында нәшер ителгән газета-журналлардагы тәхәллүсләрне, имзасыз шигырь һәм мәкаләләрне җентекләп тикшерү, шагыйрьнең архивта сакланган язмаларын, замандашларының истәлекләрен өйрәнү, чагыштыру кебек киң планлы эш нәтиҗәсендә Т.ның 30га якын яшерен имзасын ачыклый. «Хәсрәт», «Шәкерт угы», «Җен», «Тәртә башы», «Мәҗнүн», «Дугъры», «Салам Торхан», «Догачы», «Адвокат», «Мәкәрҗдә булучы», «Бән», «Мөсафир» — шундыйлардан.

Г.Р. Икенче дүрттомлыкта аңа кадәрге басмаларда киткән байтак хаталарны төзәтә, әсәрләрнең язылу һәм басылу хронологиясен күпкә дөресли. Т.ныкы икәнлеге фәнни нигездә исбатланган 30лап шигырь, 20 мәкалә, 11 хат өстәлүе дә Икенче дүрттомлыкның кыйммәтен арттыра. Текстолог моңарчы Т.ныкы саналган «Казаннан Думага телеграм», «Корымлы мунчалар», «Нәҗип Ломовой шигырьләре», »Яңа әсәрләр тирәсендә», «Хәйран булып калдык», «Татар мәҗлесе» исемле фельетоннарны төшереп калдыра, аларның башка авторларныкы икәнлеген ачыклый. Г.Р.ның гомере буе җыйган материаллары үзләре генә дә бу юлы Г.Тукай әсәрләрен биш томнан чыгару ихтыяҗын тудыра. Биштомлыкта текстолог башка басмаларда булмаган 120дән артык әсәр урнаштыра.

Икенче дүртомлыкта ук Г.Р. башка халыкларның — рус, украин, белорус, казакъ, үзбәк, азәрбәйҗан һ.б. тәҗрибәсен өйрәнеп, текстология фәненең таләпләренә туры китереп, татар филологиясендә беренче буларак, классикларның томнарын төзүнең, искәрмәләр һәм аңлатмалар язуның системасын — концепциясен төзи. Мондый эшләрне башкару бүген дә шушы үрнәктә тормышка ашырыла.

Биштомлыкның фәнни аппараты тагын да киңәйтелгән. Искәрмә-аңлатмалар күләм ягыннан үзләре бер томны тәшкил итә. Ул татар әдәбияты тарихы, теориясе, фәлсәфәсе мәгълүматлары тупланган кече энциклопедияне хәтерләтә. Искәрмәләрнең

«Мөтәшагыйрьгә», «Җавап», «Васыятем», «Кызык гашыйк» һ.б. әсәрләргә багышланганнары мөстәкыйль фәнни мәкалә буларак карала ала. Әйтик, «Җавап» шигыренең архивта кульязмасы сакланмаган, кемгә төбәп язылганлыгы, датасы исбатланмаган иде, текстолог аның З. Бәширигә нисбәт ителгәнлеген раслый. «Китмибез!» шигыренең язылу сәбәбен ачыклауны, фәнни бәяләүне дә Г.Р. башкарды.

Т. үзе исән вакытта чыккан 33 китап, газета-журналлар, совет чорында басылган аерым җыентыклар, төрле басмалар, шагыйрьнең архивы — биштомлыкка керткәндә төзүче һәр әсәрне шушы басмалардан тикшереп, чагыштырып чыга, әсәрнең язылу вакыты, кайчан, кайда басылганлыгын һәм бу томга нинди чыганактан алынганын әйтеп бара. Болар басманың фәннилеген камилләштергән.

Дүрттомлыкта һәм биштомлыкта Т. әсәрләрендә телгә алынган реаль шәхесләр турындагы мәгълүматлар да күп. 1956 елгы басмада булмаган алтмышка якын исем «Искәрмә һәм аңлатмалар»га кертелә. Кырыклап шәхес турында өр-яңа яисә тулыландырылган мәгълүмат бирелә, һәркайсының туган, үлгән еллары ачыклана. Т.ның чәчмә мирасында мәдрәсәләрдә дәреслек хезмәтен үтәгән яисә бүтәнчә кулланылышта булган иске китаплар телгә алына. 1956 елгы басмада аларның күбесе аңлатмасыз калган. Г.Р. исә, күп китапларның үзләрен күздән кичереп яисә ышанычлы чыганакларга таянып, аларның эчтәлек һәм формалары турында мәгълүмат бирә.

Г.Р. 12 шигырьне Т.ныкы булуы ихтимал, дип бирә. Чыннан да, аларны стильләре, темалары, эчтәлекләре буенча Т.ныкы, дияргә нигез бар. Икенче Дүрттомлыкка кертелгән Т.ныкы булуы ихтимал, дип бирелгән шигырьләрнең алтысы, ягъни «Сәгадәт юк...», «Руслар эш күрәләр...», «Бунларның берсе — үз анасы...», «Аһ идәрсә...», «Сәнгә хезмәтдер...» дип башланганнары һәм «Әйтәсем килә» шигыре соңгы басмада тәгаен Т.ныкы дип шикләнмичә тәкъдим ителә. Икенче дүрттомлыкта Т.ныкы булуы мөмкин дип урнаштырылган өч шигырь, киресенчә, бу юлы бөтенләй төшерелгән, чөнки аларның бүтән чыганактан булуы тәмам ачыкланып җиткән.

Шулай итеп, дүрттомлык һәм биштомлыкта Т. текстларының фәнни дөреслегенә ирешү юнәлешендә Г.Р. зур эш башкарган. Томнарда моңа кадәр чыккан басмаларда булмаган 170кә якын әсәр кертелгән. Томнарны укучыга Т.ны тагын да ныграк ачу мөмкинлеген бирә торган җентекле, системалы, зур күләмдә искәрмә һәм аңлатмалар белән тәэмин иткән. Г.Р. үзенең эшчәнлеге белән татар филологиясендә текстология фәнен югары баскычка күтәрә.

Фоат Галимуллин ■

Әсәр.: Гайнанов Р. Билгесезлектән — яңа томга // Социалистик Татарстан. 1976. 20 май. Гайнанов Р. Аның мирасыннан // Социалистик Татарстан. 1971. 25 апрель.

Әдәб.: Хәким С. Тукайны укыйм // Социалистик Татарстан. 1975. 28 декабрь. Галимуллин Ф. Һаман да якыная // Социалистик Татарстан. 1984. 12 октябрь. Урманчеев Ф. Кадерлерәк була бара // Казан утлары. 1987. №4. Б.161-165. Исламов Р. Тукай текстологы — Р. Р. Гайнанов // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. — Казан: 1997. Б.115-120.

НУГАЙБӘКЛӘР ШӘҖӘРӘСЕ

Роберт Зарипов

Авылларыбыз тарихын язганда, Азнакай төбәгенә бәйләнешләре булган байтак нәсел агачлары белән танышырга һәм аларны җентекләп өйрәнергә насыйп булды. Әйтик, бүгенге көндә киң таралган Нугайбәковлар фамилиясен йөртүче кешеләрне кайларда гына очратырга туры килми. Нугайбәк нәселен өйрәнү нәтиҗәсендә, Азнакай районындагы иң борынгы Урсай авылы тарихы язылып, 1998 елда «Еллар авазы» исемендә китап булып чыкты.

Урсайның кеше исеменнән барлыкка килүен исбатлый алдык. Кирәкле дәлилләр Нугайбәков Мәрданша шәҗәрәсеннән табылды.

1930 елда Мәрданша Нугайбәков бу шәҗәрәне Мөхәммәтхафиз Габделфатыйх ахун Нугайбәковтан язып ала. Анда түбәндәге насел агачы китерелган иде: Габделфатыйх — Хәлил Мулла улы, Хәлиулла мулла — Шәмсетдин улы, Шәмсетдин — Нугайбәк улы, Нугайбәк — Хәсән улы, Хәсән — Урсай улы, Урсай (авылга нигез салучы) — Җыеш улы, Җыеш — Исәнгол улы, Исәнгол — Сарыбай улы, Сарыбай — Бүләк улы, Бүләк — Аккүз улы, Аккүз — Арслан улы, Арслан — Алгынчы улы, Алгынчы — Куганчы улы, Куганчы — Гирәет улы, Гирәет би (бәй) исә чыгышы буенча Нугай урдасыннан кабилә башлыгы була.

Тарихчы-галим Марсель Әхмәтҗановка мөрәҗәгать итик. *«Уникенче дәрәҗәдәге Нугайбәк бине Хәсән угыллары мондыйлар: Күрмәкәй, Ярмөхәммәт, Шаммас, Сәлташ, Шәмсетдин, Габделваһап. Унөченче дәрәҗәдәге Күрмәкәй (Хөрмәкәй) бине Нугайбәк углы Урсай авылындагы Шаһингәрәй (Шәнгәрәй) кантун. Шәмсетдин бине Нугайбәк Урсай авылында булып, углы Хәлил мулла дигән кеше. Ярмөхәммәт бине Нугайбәк углы Чаллыда, Галибай хәзрәт. Ярмөхәммәт Биби исемендәге кызы Кичүчат авылында Нәҗметдин бине Фәсхетдин никахында иде».*

Автор мондый искәрмә бирә: *«Гирәет (Кирәет) би шәҗәрәсенең берничә күчермәсе Татарстанның Азнакай төбәгендә табылды. Гирәет би нәселе монда күбрәк Нугайбәк нәселе буларак атаклы. Нугайбәк Хәсәнов XVIII гасырның икенче яртысында Урсай һәм Чалпы авылларында яшәгән, Пугачёв кузгалышында халык ягыннан торып көрәшкән, хөкемгә эләгеп, старшина атлы Хәсән ярдәме белән котылган (1802 елда Чалпы авылында үлгән, кабер ташы сакланган). Бу шәҗәрәнең күчермәсе Урсай урта мәктәбенең тарихи төбәк музеенда саклана.*

Бу кабиләнең табыну хайваны — бүре, тамгасы — «күз», нәсел агачы — юкә, ә кошлардан — каз. Нугай урдасының барлык кабилә башлыклары би (бәй) титуллы булган. Гирей (Кирей) исеме хөрмәтләп «сез» дип әйткәндә «ят», «ют» кушымчасы белән яңгыраган (монгол телендә күплек берәмлеген аңлата).

Гирәет би Имән-калада (булачак Уфа) яши. Бу кала нугай намест-

Урсай мәчете

XIV гасыр эпиграфик һәйкәле – кабер ташы – Урсай авылы музеенда

Мамонт сөяге калдыклары

Урсай авылы музеендагы экспонатлар

нигының кышкы рәсми резиденциясе булган. Хронологик тәртиптә Җангурча, Алчачыр, Мамай, Хакназар, Исмәгыйль, Әхмәтгәрәй, Динбай, Сәитәхмәт, Канай, Килмөхәммәт наместниклар булса, шулардан Әхмәтгәрәй һәм Хакназар — Чыңгыз нәселеннән, ә калганнары Алтын Урда идарәчесе — төрки Идегәй токымыннан».

УРСАЙ АВЫЛЫ

● Тарихи чыганаклар фаразлаганча, 1698 елда Гирәет би нәселеннән булган Урсай атлы кеше авылга беренче нигез ташын салган.

● Урсай авылы Анакай шәһәреннән 31 км төньяктарак, Ык елгасы буенда урнашкан. Авылга якын тимер юллар

Ютазы белән Бөгелмәдә — 65-83 км ераклыкта. Чаллыга — 190, башкалабыз Казанга — 360, Уфага — 320 километр. Халкы кырчылык, игенчелек белән шөгыльләнә, нефть тармагында эшли. Авылда мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, мәчет бар. 1860 елларда халкы башкорт-вотчинникларга, типтәрләргә, дәүләт крәстияннары катламына бүленә. XX гасыр башында 3 мәчет, 2 мәктәп, су тегермәне була. Авылның гомуми җир мәйданы 7165 дисәтинә тәшкил итә. 1920 елга кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Тымытык волстена керә. 1930 елдан — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 елның 10 августыннан — Тымытык, 1931 елның 20 октябреннән — Азнакай, 1935 елның 10 февраленнән — Тымытык, 1958 елның 16 июленнән — Азнакай, 1963 елның 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 елның 12 гыйнварыннан Азнакай районында. Халык саны: 1795 елда — 186 ир-ат, 1816 елда — 349 ир-ат, 1834 елда — 235 ир-ат, 1859 елда — 874 кеше, 1889 елда — 1619, 1897 елда — 1833, 1910 елда — 2407, 1920 елда — 2185, 1926 елда — 1789, 1938 елда — 1652, 1949 елда — 1174, 1958 елда — 1166, 1970 елда — 1329, 1979 елда — 1005, 1989 елда — 775, 2002 елда — 740, 2010 елда — 753, 2013 елда — 764 кеше.

● Урсай авылында туган күренекле шәхесләр: шагыйрь Илдус Гыйләҗев (1946), сәяси фәннәр докторы, галим Назиф Мириханов (1952), композитор Әнвәр Шәрәфиев (1935), укытучы-шагыйрә Тәкыя Шәрипова (1922-2013), төбәкне өйрәнүче Роберт Зарипов (1944-2013) һ.б.

● Азнакай районындагы татар эпиграфик сәнгатенә караган кабер ташларын беренчеләрдән булып күренекле галим Һарун Йосыпов өйрәнә башлый. Ул Урсай авылы янындагы XIY гасырга караган ташларны тикшерә (галимнең әлеге тикшеренүләренең нәтиҗәсе булган хезмәт бүгенгәчә басылмаган).

● Урсай авылының истәлекле урыннары: Кызыл яр, Умарталык күле, Аркылы тал, Мунчала күле, Кәҗә сукмагы, Кара яр күле, Таштоба күле, Тегермән алды, Чыршылы күл, Кашлак тавы, Коелы чокыр, Түгәрәк каенлык, Мирсәет култыгы, Миңгерә тау, Сукаеш буе һ.б.

БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫ БӘЕТЕ

Дүрт ел буе сугыштык,
«Ватан» өчен тырыштык,
Нәтиҗәсе шул булды:
кулсыз-аяксыз кайттык.

Дүрт ел буе сугыштык,
кемнәр өчен тырыштык,
Германнар — дошман,
диеп каныбызны коештык.

Сарык көтүе кебек
сугышка алып керделәр,
Немец булгач офицерлар,
безне пленга бирделәр.

Мең ярымга якын
солдат мылтыкларын ташлады,
Кайберләре арадан:
«Давай мир!» — ди башлады.

Өч көннән соң хәбәр килде,
Николай төшкән икән,
Безнең башны ашаганда
авызы пешкән икән.

Герман белән безнең солдат
кочаклашып яттылар,
Йөзе кара Николайны
казаматка яптылар.

Николай ята казаматта,
тимер аның койкасы,
Бу хурлыкка төшкәнлектән
һич тә юктыр йокысы.

*(Урсай авылы кешесе **Миңнулла Нәбиуллиннан** 1983 елда язып алынган.)*

«Татарлардан калган – дәүләтләр...»

Илдус Гыйләҗев

ТУГАН ҖИР

И туган тел, и матур тел.
Г.Тукай

И туган җир, и матур җир,
Кендек каным тамган җир.
Атам-анам гомер иткән,
Бабамнардан калган җир.

Суларында коендырган,
Туендырган җайлы җир.
Иген уңган, җәнлек тулган,
Кара һәм ак майлы җир.

Татар җанлы вә иманлы
Оныкларга калыр җир.
...Бөтен гөнаһларым белән
Куенына алыр җир!

БАСКЫННАР КАГЫЙДӘСЕ

Ил чикләрен сакларга да,
Амбразура капларга да,
Балта, чүкеч сапларга да,
Көчсезләрне якларга да
Татар кирәк.

Шахталарга төшәргә дә,
Девон нефтен тишәргә дә,
Сазлыкка юл түшәргә дә,
Себерләргә күчәргә дә
Татар кирәк.
Рейхстагка менәргә дә,
Моабитларда үләргә дә,
Ил әҗәтен түләргә дә,
Илне данга күмәргә дә
Татар кирәк!

...Бүләк булгән җирдә генә
Татар сирәк.

МАКТАНЫРЛЫК ТА ШУЛ

Хәрәкәттә булган һәммәсе дә.
Вакытында — үтеп барышлый.
Орышканнар... кемдер алга киткән,

Хәлсезләре бөлгән — карышмый.
Исән әле һаман чегәннәрдә
Күчеп йөри торган гадәтләр.
...Кемнәрдәндер калган учак көле,
Татарлардан калган — дәүләтләр...

ТАТАРСЫЗ БУЛАМЫ СОҢ?..

Без килгәнбез Тибет якларыннан,
Татар даны шуннан таралган.
Күпме халыкларны берләштергән,
Дуслык милләте, дип дан алган!

Тарих буйлап кире чигенсәгез,
Шанлы уй-хисләргә батарсыз.
Туфан суы калкыр...
Кеше кабат үрчер!
Яши алмас мәңге татарсыз!..

Редакциядән: *Азнакай районы Урсай авылы тумасы, Һ.Такташ, М.Хәсәнов, Р.Төхфәтуллин исемендәге әдәби премияләр лауреаты, күренекле шагыйрь* ***Илдус Сабир улы ГЫЙЛӘҖЕВ****не гомер бәйрәме — күркәм юбилее белән ихлас котлыйбыз. Аңа яңадан-яңа иҗади уңышлар, саулык-сәламәтлек, гаилә бәхете телибез!* ■

КӨМЕШ КҮЗЛЕ ЧИШМӘЛӘР...

Илдар Кыямов

(Татарстанның Чирмешән районы, Кара Чишмә авылындагы чишмәләр тарихы)

Кара чишмә (Идегәй чишмәсе). Риваять буенча, бабаларыбыз килеп, иң әүвәл эзләп тапкан чишмә. Авыл читендәрәк булгач, «Оч кизләү, Аръяк чишмәсе» дип тә хәтерлиләр аны. Бик озак еллар буралы чишмә булып челтерәп аккан. 1967 елда кырыен бетонлап, «кайчылар» утыртып, башын шифер белән япканнар иде. 2004 елда, өмә ясап, ул янә төзәтелде, башына ай куелды. 2012 елда авылдашыбыз Камилә Арсланова өй артларындагы бу чыганакны яңадан төзәттереп, янына төшәргә җайлы булсын өчен, таш түшәттерде. Суы бик мул, тәмле. Улагында хатын-кызлар кер чайкый, көзге өмәләрдә каз чайкый, зур мал суйгач, эчәк юа иде. Моннан тыш, элек заманда егетләрнең кыз күзли торган урыны — үзенә күрә «табигый клуб» та булган әле ул чишмәләр. Егетләр ат эчергәндә, кызлар да, сәбәп табып, шунда төшү җаен эзләгән. Кисмәк тулы су булуына карамастан, чиләкләрен бакчага бушата да «суга китә». Очрашалар. Кыз яшереп кенә егеткә кулъяулык бирә, егет конфет, чикләвек ише тәм-том суза. Шул рәвешле мәхәббәттә аңлашканнар.

Озак еллар авыл мәктәбендә химия укыткан Мәхмүт абый Җиһаншин 2005 елда һәр чишмәнең суын алып, «Татарстангеология» гидрохимик лабораториясенә анализга җибәргән. Авыл-

Кара чишмә. 1970 еллар азагы

Егетләр ат эчергәндә, кызлар да, сәбәп табып, шунда төшү җаен эзләгән. Кисмәк тулы су булуына карамастан, чиләкләрен бакчага бушата да «суга китә». Очрашалар. Кыз яшереп кенә егеткә кулъяулык бирә, егет конфет, чикләвек ише тәм-том суза. Шул рәвешле мәхәббәттә аңлашканнар.

Чишмәнең бүгенге күренеше

дагы һәр чыганакның да минераль матдәләргә бай, йомшак сулы булуы ачыкланган. Ә Кара чишмәнеке исә, «кабатланмас (уникаль) су», мондый су бүгенге көндә сирәк очрый, дигән нәтиҗә чыгарган белгечләр. Чыннан да, суы бик сыйфатлы. Мунча керсәң, юынып туеп булмый, чәйгә утырсаң, шәрәфәтле ләззәте изрәтерлек!

Партизан урамы чишмәсе. Заманында аның суын җирдәге уемнан чүмеч белән генә сөзеп тутырганнар. Бу чишмә XX гасырның 20 нче елларында гына казылган булса кирәк, чөнки 1910 елгы земство язуларында зур чишмәләр генә телгә алына. Әлеге чишмәне шушы авылда яшәгән Гайфетдин Монасыйпов яки аның атасы Монасыйп бабай казып чыгарган булуы ихтимал. «Утаудан кайтышлый, шуннан су эчеп, битләрне юып ял итә идек, Чатлауга эшкә барышлый да су тутырып китәләр иде», — дип искә ала хәзерге өлкәннәр. Мин аның тактадан капкачлы баз авызы сыман эшләп куелган вакытын хәтерлим әле. Аны Әнвәр абый ясаган булган. Чишмәгә такта дүрткел (коробка) төшереп, кош-корт, хайваннар пычратмасын өчен өстен томалап, капкач та куелган иде. Партизан урамы тулысынча шуннан су алып яшәде, балалары исә шундагы чирәмдә уйнап үсте. Хәзер урам бетте, әмма чишмә яши! Әнвәр абый нигезен карап торучы Мохтар Әскәров чыганакны да игътибарсыз калдырмый икән. Рәхмәт аңа! Авылга Әнвәр абыйның улы Фәндәс кайткач, Мохтар белән бу чишмәгә тимер мичкә төшергәннәр. Инешне мул суы белән сөендереп тора туган авылның бәрәкәтле чишмәкәе...

Атау чишмәсе. XX гасыр башларында матур гына имән бурасы булганлыгы билгеле. Соңрак биегәйтеп,

бурап, идәннәр җәеп эшләгәннәр. Шул тирәдә яшәгән кызлар бурасын юып, чистартып торган. Җитмешенче еллар башында, бурасы черегәч, кое сыман итебрәк киң авызлы торба утырталар. Ләкин, балалар төшеп китүеннән шикләнеп, 1973 елда каяндыр кайтартылган зур тимер чан төбе белән каплыйлар. (Аның диаметры 4-5 метр бар.) Колхоз тимерчелегендә эретеп ябыштырып, Сәет Мозаффаров аның өстенә тимер ишек ясата. Мөхәррәм Гомәр улы Җиһаншин депутат булган еллар, аның да булышлыгы тия, шул тирәдәге халык та хәлдән килгәнчә булыша. Чулпан Халиков трактор белән өстерәтеп төшкәч, Атау урамы кешеләре, җыйнаулашып, ломнар, тәртәләр белән этеп-төртеп дигәндәй, әлеге чанны урнаштыра. (Ул чакта авылда кран юк әле). Бураны эчтә калдыралар, аннары гына эчкә кереп чистартып чыгаралар. Халык, насослар салып, тау түбәсендәге йортларына су кертә. Шушы тимер резервуар әле дә бар. Өстендәге ишеген ачып, кизләүнең хәлен белергә мөмкин, торбадан мул һәм тәмле суы ага.

Сәмигыл чишмәсе. «Сәмуг чишмәсе» дигән варианты да бар. «Шәфыйков Габделхаклар бабасының чишмәсе» дип тә атады аны аксакаллар. Авылның метрикә кенәгәләрендә чыннан да Сәмигыл исемле ике кеше теркәлгән. Берсе — Морадъяр улы. Ул 1810 еллар тирәсендә туган кеше. Икенчесе — Сәмигыл Сәлимҗан улы. «1862 елның 26 декабрендә туган», диелә. Чишмәне шул Сәмигылларның икесенең берсе чыгарган булуы мөмкин, карап торганлыгы да хак. Бу кизләүне «Хөсәен бабай чишмәсе» дә диләр бит әле. Хөсәен Садыйков, безгә якынрак заманда яшәп, колхозлашу елларында гына вафат булган. Ул Сәмигыл чишмәсен карап, төзәтеп торганга ошый, шуңа күрә, чыганакны берара «Хөсәен бабай чишмәсе» дип йөрткәннәрдер. Бусы бик ихтимал. Халык хәзер башлыча «Сәмигыл чишмәсе» дип сөйләшә. Бөек Ватан сугышы елларыннан соң әлеге чишмә өстендә агачтан эшләнгән гап-гади куыш кына бар иде, дип искә ала өлкәннәр. Шул инеш буенда яшәп алган Әхмәдулла абый Мәсләховның олы улы тугач, аңа шушы чишмә хөрмәтенә Сәмигулла дип исем куштыралар. Күкертле булгангамы, су алучылар бүген юк диярлек. Галимов Шәүкәт абзыйлар анда өсте ябулы торба утырткан. Ул бүген дә тора, тик су чыгуы гына кимегән. Һәркемнең өенә су кергәнлектән, чыганакларның да ихтыяҗы азая шул…

Урта кизләүгә, куәтле җир асты ташкыны булып, Кыркәминкәдән зур тармак килә дә авыл буйлап төрле чишмә юлларына бүленә. Мишәрдә «чишмә»не кизләү дип йөртәләр. «Кизләү» (гизләү) тамак төбе белән җырлауны да аңлата әле.

1942 елның 17 маенда Сәгъди бабай Сәфәргалиев район газетасына чишмә янын цементлап ясар өчен ташчы эзләп белдерү биргән. Гата Зәйнапов бригадасы бу чишмәне төзәткән. Шул ремонттан соң анда ике чан торган. Бер чаннан су ургылып чыгып, өсте каплаулы агач улаклар буйлап төп чишмәгә (икенче чанга) бара. Анысыннан да өч-дүрт улак көйләнгән. Хатын-кыз халкы чишмә буенда озак тормасын, чират көтеп вакыт үткәрмәсен өчен шулай ясаганнар. Улакларның дүртесе дә буш булмаса, кемнең кере чистарак, шул чишмәгә якын җирдә юа, палас чистартучы, мал эчәге юучылар исә, су агып киткән якка — улак башынарак күчә инде. Кышкы салкыннарда су агызып ала торган урын бозланып ката. Андый вакытта көянтәгә чиләкне элеп, суны төп чаннан чумырып аласың. Шулай чиләге ычкынып йә аягы бозга таеп, тирән чишмә эченә төшеп киткән кызлар да булгалаган. Юеш кием белән салкында тышка үрмәләве дә җиңел түгел. Андый чакларда олы апа-җиңгиләр ярдәмгә килгән. Батучы-

Уңда аягүрә – авыл чишмәләрен төзәтеп, карап торган сугыш ветераны Габдрахман Мортазин (1909-1964)

ны иң кырый өйгә алып кереп, коры киемнәр кидереп җылытырга ашыкканнар.

Алтмышынчы елларда чишмәләрне Габдрахман абзый Мортазин карап һәм чистартып торган. «Авыл советы кушуы буенча эшләсә дә, «Аллаһы ризалыгы өчен булсын!» — дип эшкә керешер иде, аннан соң да карап торды әле ул аны», — дип искә ала кызы Минниса апа Җәләева. Ләгәнгә измә ясап, ерганакларын казып, нигезен ташлар белән катырып, Габдрахман абзый өч чишмәне дә (Кара чишмә, Урта кизләү, Сай елганы) берүзе рәткә китереп чыккан. Шул хәлендә Урта Кизләү 1995 елга кадәр торды әле. Аны авыл халкы шул елны яхшылап төзекләндерде. Эшмәкәр Ирек Габдрахманов корылма башын ябарга яхшы калай биргән. Авыл яшьләре, чишмә тирәсенә вак таш түшәп, тирә-ягына агач утыртты. 2003 елда «Татойлгаз» җәмгыяте нефтьчеләре бүгенге хәленә китереп төзәтте. Авылның югарыдагы су манарасына да, Түбәночка да шуннан торба сузып, насос салдылар, өйләрне чишмә суы белән тәэмин иттеләр. Элегрәк ул чишмә тирәләре ачык иде, хәзер кәҗә-сарык йөрмәү сәбәпле, куак баскан. Тирә-юне бик матур.

Кизләү тирәсендәрәк **Зөбәйдә чишмәсе** дә булган әле. Акылга чамалырак Зөбәйдә исемле кыз бала шунда коенгач, авыл халкы берара ул чишмәне әлеге кыз исеме белән атап йөрткән. Хәзерге көндә бу тарихны хәтерләүче дә юк инде. Миңа Фәхирә апа Шәйхатова сөйләгән иде.

Челтер чишмә бик матур тавыш чыгарып ага. Аны Әхсән Вәлиев ачкан. Елга буенда ук саркып-агып ята. «Бүген дә чишмә исән, гамәлдә», — ди Рөстәм Вәлиев. Башта бу чыганакны Әхсән абый табып, шифер белән көйләп куйган, аннан торба салып төзәткән. Соңгы елларда Рөстәм хәзрәт аны казып тирәнәйтергә ниятли, ләкин берничә көрәк тирәнлектә казыгач, сазлыклы җир ишелә башлый. Шуннан соң ул бетон коршаулар сала. Тирәнлеге бер метрга җыеладыр. Җир өстеннән аз гына калкып торган коршаудан матур булып челтерәп аккан су Кара чишмә елгасына кушыла. Шул тирәдәге урамда үскән Гаҗилә Сәхәбиева: «Без үскәндә чишмә тирәләре, Кара чишмә елгасының ул төшләре искиткеч матур, чиста иде. Мал-туар да күп. Алар бөтен чүп үләнен кырып-ашап барганга күрә чиста булдымы икән әллә?» — дип искә ала. Кызыклы гына күзәтү: авылдагы барлык чишмәләрне бер сызык белән

Кизләү чишмәсе

тоташтырсаң, Ачылык башыннан килүче юнәлешкә перпендикуляр тагын бер сызык хасил булыр иде. Кыркәминкә ягыннан әйтерсең лә куәтле торба сузылган һәм ул авыл буйлап вак чишмәләргә бүлгәләнгән. Табигый су артериясе чыннан да шулайрак урнашкан ахрысы.

Мәссаров Фазыйл абый чишмәсе. Моны Фазыйл чишмәсе дисәң дә, Ситдыйк бабай чишмәсе дисәң дә була. Ул Фазыйл абыйның бакча ягында, өеннән 30-40 метрлар астарак, Лотфулла бабай межасы тирәли типкән. Суы көмеш кебек чиста, тәмле дә, йомшак та. Астагы якта яшәүче Әһлүковлар, Идиятов Әмин абзыйлар һәм башка тирә-күршеләр дә шуннан су ала торган булган. Үзе чишмә, үзе кое дисәң дә була бу чыганакны. Фазыйл абый анда бер метр диаметрлы торба төшергән, тирәнлеге — ике метр. Яхшы итеп капкач ясаган, артык су китәр өчен уемы да бар, үлән арасында челтерәп ята. «Элек үзем тездән суга кереп басып чистарта идем, мин белгәндә анда бура тора иде. Коры елларны насос батырып, бәрәңге, суганнарны сугарам, суы җитә», — ди Фазыйл абый.

Ситдыйк бабай заманыннан бирле бар икән инде бу чишмә. Әлеге нигездә Ситдыйк бабай (1860 елгы) яшәгән.

Сай елга чишмәсе. Бик мул ташкын булып чыкмаса да, матур, күптәнге чыганак. Чыккан урыны сазлыклы. «Ул урында берничә чыганак саркый иде, яр ишелү аркасында, томаланып беттеләр. Ә чишмә үзе без бала вакытта куашна* сыман эче куыш агачтан әмәлләнгән иде», — дип искә ала шул тирәләрдә үскән Мәмдүха апа Халикова. 1980 елларда исә Сай елганың «күзен» такталар белән томалап торалар иде. Бала-чага, мал-туар кермәсен өчен кырые да тотылган, шул чишмә күзенә бишпочмаклы таш торбалар сузылган иде. Чишмәнең кырые дүртпочмаклап бетонланган, өсте шифер белән ябылган хәлдә тора — суның агып килгәнен карарга тәрәзе дә эшләнгән иде. Әнигә ияреп төшкәч, кер чайкаганда шул куышка кереп тау астыннан мул булып көмеш су саркыганын сокланып карап тора идем. Шәрига апа Таһирова сүзләренә караганда, безнең авыл көмеш ятмалары өстендә утыра. Шуңа да чишмәләрнең суы тәмле һәм саф! Су белән ияреп чыккан ком да карасу төсле бит. Бусы да көмеш барлыгын күрсәтә, ди Шәрига апа. Көмеш азотлы кушылмалар белән реакциягә керә ала. Бу бик мөмкин: чишмәгә яңгыр сулары белән бергә грунт аша азотлы ашлама эләгү ихтимал бит. Ә ашламаларны җитәрлек кулландык инде. Чишмәнең исеменә килгәндә,

* Куашна — агач кисмәк.

беренче мәгънәсе — «сай», чыннан да, бу чишмәбез ургылып акмый. Икенче мәгънәсенә килгәндә, «сай» — төрки халыкларда үзе дә чишмә, елга дигән сүз. Болай уйлаганда, безнең очракта «чишмә елгасы» дигән аңлатма килеп чыга. «Сад-бакча» дип сөйләшкән кебек әлеге атама да мишәр җирлегендә килешле яңгырый.

Сай елга чишмәсенең өстендә тау сыман калкулык бар. Ул ярыйсы ук текә булгач, кыш көннәрендә чана шуа идек. Тау башыннан кирпеч сугу өчен балчык алына торган чокырлар эзенә кадәр шуып төшәсең. Чанасы булмаган балалар ашлама пакетына утырып шуа, үзенә юаныч таба, бик кызык була торган иде. Хәтта Урталык балалары да Сай елгага шуарга килә иде.

2008 елда авыл советы көче белән чишмәнең тирә-ягын төзекләндерделәр. Кырыйлары тимер рәшәткә белән матурлап тотып алынды, улаклары, култыксалы баскычлары затлы итеп эшләнде, хәтта күшәк-чатыр да бар. Ләкин эре-эре ташлар салудан чишмәнең юлы буталгандырмы — суы кими төште, кирәксез җиргә саркып, сазлык хасил булды. Халиков Мәхмүт һәм Илалов Рәфыйк абыйлар урманнан алып кайтып агачлар утырткан.

Сай елгадан авылга таба ике як тау битендә көтү туплана торган урын бар. Халиков Мәхмүт абыйлар ягында сыер көтүе, Хәйдәров Хәсәнҗан абыйлар ягында сарык көтүе җыела иде. Бөтен халык малларын куып озатып бетергәч, көтүчеләр шуннан йә авыл буйлап, йә Сай елга астыннан буага таба көтүне кырга алып китә. Сай елга өстендәрәк Харис абый Хөснуллин, үз каршысында урын тарлыктан, утын бушатып яра, кайбер елларны шунда әрдәнә өеп куя торган иде.

Хәниф бабай чишмәсе. Оч әрәмәдә чишмәләр бик күп. Әйтик, Илалов Рәфыйк абыйның бакча башындагы койма буенда ук җирне казып агач куашна утыртылган иде. Мин белгән 1980 елларда куашналар исән, тик аларга дуен утырган, суы юк иде инде. Хәзер агачы да череп беткән. Ә менә шуннан бераз астарак үскән зур тал агачы төбендә дә шундый ук кисмәк урнаштырылган һәм суы да бар иде! Чиләк белән тыгылырлык түгел түгелен — мичкәсе таррак, ә чүмеч белән рәхәтләнеп тутырырга мөмкин иде. Тал әле дә тора, чишмәнең агач кисмәге череп беткәч, Габделәхәт абзый метрдан артык диаметрдагы бетон коршау утырткан, чыганак әле дә исән. Бу чишмәләрнең икесен дә, XX гасыр башларында, Хәниф бабай Ситдыйков (1884 елгы) чыгарган булган.

Безнең авыл көмеш ятмалары өстендә утыра. Шуңа да чишмәләрнең суы тәмле һәм саф!

Саимә чишмәсе. Саимә апа Мортазина 1990 еллар тирәсендә ачкан иде. Сай елгадан төньяктарак, сарык көтүе җыела торган сөзәклектә. Аңа бетон цилиндр төшерделәр. Берара суы кимеп торды. 2012 елда Фәгыйлә Хәсәнҗан кызы Сибгатуллина аны тирәнәйтеп, чистартып, суырткыч салып, яңадан гамәлгә куйган.

Мортазин Нуриман абый чишмәсе. Үз бакча башында казып, 1981 елларда чыгарган иде. Ул анда тимер мичкә утыртты. Бик мул булып, кайнап-кайнап, чип-чиста суы чыгып тора иде. «Мин бераз ялгыш эшләгәнмен, — ди Нуриман абый, — тора-бара сазлыклы җир тимер кисмәкне суырып алды, сеңдерде. Шуның аркасында, чишмәмнең чыганагы да томаланды бугай…» Бакчасы кырыенда Тирән елга ягында ул соңрак тагын бер чишмә ачкан иде. Анысына машина баллоннары салган булганнар. Суы гөрләп чыгып тора, яшелчә сугарырга бик уңайлы икән. Авылыбыз гаҗәеп безнең — тау түбәсендә дә чишмәләре бар аның!

Хөсәен бабай (Зөбәеров) чишмәсе. Хәзерге (яңа) буа астында калган.

«Бик саф сулы иде. Әрмәгә коенырга төшкәндә шунда тукталып су эчә идек», — ди Әгъләметдин абый Сәрвәров. Хөсәен бабай аны көтү көткәндә казып чыгарган булган.

Зөләйха әби чишмәсе Фәнис Идиятовларның бакча башындагы тал астыннан саркыган. Чиләк куеп агызырлык чокыры булган. «Ташлар арасыннан мөлдер-мөлдер агып торучы кечкенә генә чишмә иде», — ди өлкәннәр. 1975 елларда суы киткән, корыган. Бу чыганакны Зөләйха Фәхретдинова (1854-1939) ачкан булган. Чишмәсе корыса да, аның исеме сакланып калган.

Ачы(к)лык чишмәсе. Авылдан 400 метрлар үткәч, Түбән Кәминкәгә илтүче асфальт буйлап сул кулда юлга орынып ук торучы чишмә. Ул Сары суга коя. Биредә көтүчеләр, юлаучылар су алган. XX гасыр башларында ул чишмәне Борһан бабай Сәрвәров (1905-1965) карап-чистартып торган, диләр. 1976 елларда анда кыр станы иде. Мөхтәрәмә апа белән Бари абзый Таһировлар махсус көйләнгән казаннарда игенчеләр өчен аш пешерде. 2008 елда авылдашыбыз, Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Минсәгыйрь Гайсә улы Нуретдиновның ярдәме һәм үтенече буенча, чишмәгә заманчалап «Ямашнефть» эшчеләре тарафыннан реконструкция ясалды. Бетон коршаулар төшерелде, баскычлар, беседкалар (күшәк-чатыр) эшләнде, затлы агачлар утыртылды. Хәзер ул **«Гайсә чишмәсе»** дип атала. Суының составы да ачыкланган. Анда хлорид — 51,8 мг/л, сульфат — 78 мг/л, катылыгы исә — 9,6 икән. Тик чыганакның күзенә зыян тидеме — су килүе нык кимеде. Бу чишмә янында 2013 елда авыл сабан туен уздырдылар.

Саҗидә әби чишмәсе. Кыркәминкәгә барганда, Коры елга башында кала. Моны ачкан авылдашыбыз — Саҗидә Гафиулла кызы. Баһманов Харис абзыйның әбисе була. Ул шушы тирә-

«Гайсә чишмәсе»н ачу. Алгы планда: Чирмешән районы башкарма комитеты рәисе Ә.С.Мөгыйзов (сулда) һәм җирле үзидарә рәисе А.И.Әһлүков. 2008 ел

ләрдә урак урганда җирне казып карагач, су чыккан. Шунда иске куашна алып барып утырткан. Чумырып алыр өчен бик җайлы чишмә барлыкка килгән. Ул тарафта, гомумән, кыркапкадан соң бакчалар китә торган булган. Дым якын, уйсу-сазлыклы җирләр күп. Кырга барып эшләүчеләр, Коры елгага барган авылдашлар анда туктапып бит-кулларын юып сафланган, сусавын баскан. Соңрак әлеге чишмәне казый-казый, бура төшереп, кое ясаганнар. Узган гасырның 70 нчы елларында коега өч-дүрт дуңгыз төшеп баткач, ул коены колхоз күмдергән. Коеның ихтыяҗы да беткән булган.

Китапны язу барышында Минзәлә өязе земствосының да су чыганакларын кайгыртып яшәгәненә инандым, шуны күрсәтүче документларга юлыктым. Коелар һәм чишмәләр янгын чыга калса, сүндерү максатыннан да бик кирәк була, әлбәттә. Моннан тыш, 1911 елда безнең якларда холера (үләт чире) таралгач, санитария статистикасы вәкилләре белән өяз табиблары авыл саен йөреп сулыкларны барлап, чисталыгын тикшереп чыга. Өязенең земство землемеры А.В.Сергеев сулыкларның схемасын бушлай сызып бирә (анда һәр чыганак күрсәтелгән була). Муллаларга, мөгаллимнәргә брошюралар өләшенә, чисталык саклау буенча киңәшләр, таләпләр әйтелә. Губерна идарәсе дә суы юк авылларда чишмә чыгару, йә гамәлдәге коеларны чистарту, булмаган очракта, яңаларын казыту мәсьәләсен кузгата. Кое казуны махсус командировкаланган әһелләр күзәтүендә алып бару зарур икәнлеге әйтелә. Коелар да, чишмәләр дә чиста тотылырга, буралары җир өстеннән ким дигәндә 1 аршын калкып торырга, черегән буралар кичекмәстән яңасына алмаштырылырга тиешлеге җиткерелә. Әлеге комиссия безнең авылда да булып киткән. Алар менә нәрсәләр күзәткәннәр. «Сборник постановлений Мензелинского уездного земского собрания. Уфа. 1912г.» дип исемләнгән китапның «Доклад к вопросу о сельском водоснабжении в Мензелинском уезде» дигән язмасында бик тәфсилле итеп безнең су чыганаклары телгә алына: *«Вдали от рек и речек в Ерсубайкинской волости расположены 3 селения, а именно Кителга, Чёрный Ключ и Тойметкино. Удовлетворительные родники имеются в пяти селениях: Чув. Серенькино, Клементейкино, Ерсубайкино, Кителга, Чёрный Ключ. В деревне Чёрный Ключ из четырёх родников один вполне благоустроен, другой имеет деревянный сруб, но без желоба, а третий имеет только ямку откуда воду черпают ковшом».* (Күрсәтелгән хезмәтнең 408 нче бите.) Биредә «яхшы эшләнгән» дигәндә Кизләү, «агач буралы» дигәндә Кара чишмә, ә чүмеч белән су ала торганы Сай елга күздә тотыла булса кирәк. Нәтиҗә ясап, бездәге дүрт чишмәнең өчесен төзекләндерергә дигән карар чыгарылган. Шул ук докладның 419 нчы битендә болай диелә: *«Деревня Чёрный Ключ Ерсубайкинской волости. 1396 жителей. 4 родника, 2 колодца, водой которых не пользуются. Реки нет, один из четырёх родников вполне благоустроен, остальные 3 имеют деревянные срубы с желобами, под которые можно подвозить бочку, но срубы не покрыты».* Һәрбер чишмәне рәткә китерү, ул чор курсы буенча, 150 сумга төшкән. Әлеге документта әйтелгән ике коеның берсе Сорур әбиләр каршындагы, берсе исә Мәссаров Фазыл абый каршындагы кое булса кирәк, чөнки башкалары Совет чорында казылган…

Редакциядән:

Журналыбызның узган елгы 11 нче санында танылган журналист, төбәкне өйрәнүче Илдар Кыямовның «Арт капкадан кергәндә…» исемле язмасы «Татар гаме» сәхифәсендә дөнья күргән иде. Безгә мәгълүм булганча, ул үзенең туган авылы турында китап әзерли. Авторның әлеге китапта чыгачак чираттагы язмасын — Кара Чишмә авылы чишмәләре хакындагысын — «Табигый мирас» сәхифәсенә тәгаенләдек. ■

Кояш кына күктә мәңге йөзәр...

Рүзәл Мөхәммәтша

Үлемнән курка икән, димәк, бу кеше инде яшәми дигән сүз.
Иоһанн Зейме

Соклангыч, билгеле: яңа дәфтәр сыман ак сәхифәләрдән генә гыйбарәт сабый хәтеренә сеңеп калган вакыйгалар, истәлекләр, детальләр кешене гомере буе озата бара. Иртән нинди көнгә аяк басуыңны хәтерләмәгәндә дә, әниеңнең яратып башкарган җырын, беренче тапкыр курка-поса, ютәлли-пырхылдый тәмәке тартуыңны, ике йорт аша гына яшәгән кояш йөзле кызга әүвәлге кат «яратам» дип пышылдавыңны һичкайчан онытмыйсың.

Беренче сыйныфта укыганда безнең бүлмәдә ике җитди, әмма мөлаем абыйның сурәте эленеп тора иде. Соңрак аларның «китап язучы» Габдулла Тукай белән Муса Җәлил булуы ачыкланды. Күпмедер вакыттан, мөгаллимнәребез ярдәме илә дүрт урынлы саннарны баганалап кушарга-алырга маһирлангач, мин баягы портретлар астындагы «мисаллар»да коточкыч тупас хата җибәрелүен шәйләдем: 1886-1913; 1906-1944. Киресенчә тиеш ләбаса! Мең сигез йөз сиксән алтыдан мең тугыз йөз унөчне алып булмый! Мең тугыз йөз алтыдан мең тугыз йөз кырык дүртне дә! Ялгыш бу! Хәер, тиз арада ачышымның әллә нәрсә булмавы ачыкланды. Ләкин җаваптан канәгатьләнер урынга, үзем тапкан бихәбәрлек сазлыгына ныграк бата бардым: абыйның түбәтәйлесе ничек егерме җиде яшьтә үлгән соң? Авырыпмы? Алайса, егерме җиде яшьтә ничек авырып үләргә мөмкин? Минем сиксән яшьлек исән-имин бабам бар бит әле. Ә икенчесе ничек үлгән? Сугыштамы? Фашистлар башын кискәннәрме? Нәрсәгә? Ни өчен? Ник? Минем сугыштан исән-имин кайткан сиксән яшьлек бабам бар бит әле…

Үлем — искитмәле күренеш ул… Аның турында күпме фәлсәфә куертырга мөмкин! Әҗәлне санитар дип атасаң ярый; Робин Гуд белән чагыштырсаң була — байларны-ярлыларны тигезли, дибез бит; аннан куркырга мөмкин, аны көтәргә… Якынайтырга. Бусыннан Аллаһ аерата сакласын, билгеле. Ерагайтып карарга: дөрес тукланырга,

Кара тәнлеләрнең граждан хокуклары өчен көрәшкән Мартин Лютер Кингның кабере. Ташта «Ирекле, ирекле, ниһаять, ирекле!» дип язылган

аракы эчмәскә, физкультура ясарга. Әмма Яшәеш тә гаҗәпсетү осталыгы мәсьәләсендә «көндәш»еннән һич калышмый шул: машиналар тыз да быз сызгырышкан урамны тиешсез урыннан җәт кенә кистереп үтәм дигәндә аның, ягъни Яшәешнең, кайвакыт күз ачып йомган арада Үлемгә әверелгәнен сизмисең дә...

Бакыйлыкка кичү, теге яисә бу кешенең «икс» сәгатенә ничек, ни халәттә килүе, ул мәлне ничек кабул итүе байтак затларны кызыксындырадыр, дип гөманлыйм. Тарихи шәхесләрнең, сәясәттә, әдәбиятта, сәнгатьтә тирән эз калдырган бөекләрнең үлеме — бигрәк тә.

Беркем мәңгелек түгел.

Кеше туганнан бирле үлә башлый...

Берәр сәнгатькяр (шагыйрь, рәссам һ.б.) турында «фәлән елда фәлән төбәкнең фәлән авылында фәлән һөнәр иясе гаиләсендә фәләненче бала булып дөньяга килде» дип тезеп китү, килешегез, туу турында коточкыч зур мәгълүмат бирә. Артыгы кирәкми дә. Юк та ул — артыгы. Чөнки җиһанга килү могҗизасы, гадәттә, бөртөсле кылына. Кайбер физиологик аермалыкларны хисапламаганда, әлбәттә — мәсәлән, арт белән туучылар бар, ярып алынганнар... Калганнар җиһанга игезәкләр сыман бер рәвешле килгән.

Ә үле-ем... Үлем йөз төрле. Мең төрле. Аннан да күбрәк төрле. Һәркемнең үлеме индивидуаль. Һәркем үзенчә генә үлә... Яңадан ки, кайбер гадәттән тыш очракларны (төркем-төркем агулау, төркем-төркем җәзалап үтерү һ.б.) исәпләмәгәндә.

Урысларның Мәскәүдә басылган «Жизнь и смерть знаменитых людей» китабы бар. Фәкыйрегез аны бик тәмләп, озаклап, ләззәтләнеп укып чыкты. Күпме ныклык, күпме йомшаклык, күпме гаҗизлек, күпме гыйбрәт ярылып ята анда! Әйтик, кансыз император данын алган Нерон бугазланыр алдыннан «Нинди бөек артист үлә!» — ди. Димәк, ул гомер буе үзенең «шагыйрьлеге», «җыручылыгы» белән горурланып яшәгән, шушы уй аның туң бәгырен җылыткан, таш күңелен йомшарткан. «Нинди бөек илбашы китә», — димәгән бит! Илне канга батырган, миллионлаган кешеләрнең, халык кадәр халыкларның каргышын күтәреп яшәгән, җиһанны дер калтыратып тоткан Иосиф Сталин соңгы минутларын үз юеше, үз пычрагы өстендә аунап уздыра — Лаврентий Берия, юлбашчы янына килгәч, күпмедер вакыт демонстратив төстә борынын каплап тора да, «Хрусталёв, машину!» дип тизрәк чыгып китә. Американың егерме бишенче президенты Уильям Мак-Кинли, үтерүчесенең сакчылар тарафыннан кыйналуын күреп, соңгы сулуында «бурзайлары»н тыярга ашыга: «Саграк кыланыгыз, егетләр!» — ди. Махатма Ганди җан кыючысына сүз катмый, куәт-дәрманы җитми, куллары белән генә «мин аны кичерәм» дип ишарәләргә өлгерә... Бу юлларны укыганда йөрәгегез куырылып-куырылып алмыймы?

Нишләп безгә дә шундыйрак эш башкарып карамаска әле? Горурланыр затларыбыз юкмы әллә? Аларны тикшергән, өйрәнгән галимнәребез юкмы? Истәлекләр юкмы? Фаҗигале үлемнәребез юкмы? Бар! Бик бар! Муса Җәлилнең хөкем карарын көтеп утырган хәлдә, әсирлектә күпме әсәр иҗат ителгәнен санаганнан соң, «Моабит дәфтәрләре»нә: «Ләкин кая языйм? Үзем белән бергә үләләр...» — дип теркәвен искә төшерик. «Үзем дә алар белән бергә үләм», — дип искәртүнең мәгънәсе төбе-тамырыннан үзгә, сизсәгез. Мәгъсүм Хуҗин турында хатирәләр китабының карламасын укып хәйран калган идем. Мөхтәрәм язучы үлем түшәгенә яткач та дус-ишләрен борчырга, куркытырга теләми, алардан чирен яшерә. Вафатына бер көн кала кайсыдыр кем шылтырата аңа. Хикәяче сер бирми: «Әйбәт, укыйм әле... Яхшы, булды...» «Идел» журналының иске төпләмәләрен барлаганда шуны белдем — Саҗидә апа Сөләйманова иң мәгълүм, иң танылган шигырен әҗәлнең салкын сулышын тоеп, тәкъдир биргән соңгы атналарын санап (һәм шуны белеп!) яшәгәндә язган икән, тетрәнмичә кара:

Гомер озын дисәм, рас булырмы,
Сиздерми дә узды, дисәмме?
Күп тә түгел, гомер, аз да түгел,
Бер икәнсең, —
Тормыш, исәнме!

Бәй, үлеме белән дә күренеклеләребез дөрес яшәү өлгесен күрсәтергә теләгән түгелме соң? Безгә, исәннәргә, аларның үлеменнән дә сабак алырга кирәкмиме икән?

...Шундый уйларга бирелеп, «Безнең мирас» яңа сәхифә башлап карарга ният кылды әле. Ни булып бетәр? Аллаһ кына белә. Бердәнбер теләк, хәтта гозер дисәк тә ярый: галим-голәмә, архивчылар, язучы-шагыйрьләр, музейчылар, китапханәчеләр, студентлар, журнал укучылар бу эштә теләктәшлек күрсәтсә иде!

Бүген исә Һади Такташны соңгы юлга озатабыз...

ҺАДИ ТАКТАШ (1901-1931)

Сүзне шуннан башлыйк: вафатына ел кала Һади Такташ башына салкын тидереп бик каты хасталап ята.

1931 елның җылыга туймаган көзге бер көнендә шагыйрь дусты Гомәр Гали белән мунчага бара. Юынып чыккач, суык сыра алып эчәләр. Юеш чәчле килеш яланбаш йөргән Һади өенә кайта да авырып урынга егыла. «Соңгы авыруының катлаулануы булды булса кирәк, — дип искә ала шагыйрьнең хатыны Гөлчирә Мансурова-Такташева». Сырхаулап ятканда, дусты янына Гадел Кутуй килә. Такташ аның тавышын таный, ләкин үзе янына кертмәскә куша. Бу детальне истә калдырыйк та, **Газиз Иделле** хатирәләренә мөрәҗәгать итик: «Гомәргә *(язучы, тәнкыйтьче Гомәр Гали. — **Р.М.**)* бик таныш йортның икенче катына мендек. Ул саклык белән генә ишеккә кагылды. Бераздан ачылып киткән ишектән күп төннәр йокысыз үткәргәне күренеп торган ак, ябык чырайлы, арыган моңсу күзле Гөлчирә ханым чыкты. Ничектер сагаеп калдык.

— Әйдә, узыгыз, — диде ул тонык тавыш белән.

Такташ яткан бүлмәгә кердек. Караватта сузылып яткан гәүдә бар, ләкин бу — Такташ түгел, без белгән Такташ түгел...

Тасвирлавы кыен... Ябыккан, саргайган йөз... Ястыкка сеңгән һәм ничектер кечерәеп калган башы гел дерелдәп тора. Күзләре ачык, әмма беркемне танымый... Бөтен гәүдәсе бизгәк тоткан сыман калтырана.

Мин телсез-аңсыз калдым. Тик Гомәр генә үзен тыныч тотарга тырышты. Аның монда беренче керүе, Такташны шундый хәлендә беренче күрүе генә түгел иде, ахры. <...>

Такташ 21 ноябрьдә тимгелле тиф белән авырый башлаган һәм авыру үзәге ми шешүгә әйләнгәнлеге безгә консилиум нәтиҗәләреннән дә билгеле иде[1].

Икенче көнне иртән иртүк, әле урыннан да тормаган идек, ишек шакыдылар. <...> Такташның энесе — төсе киткән Габит килеп керде һәм: «Такташ үлде!» — дип әйтүе белән елап ук җибәрде.

Үлем 1931 елның 8 декабрь көнне иртәнге 6 сәгать 30 минутта килгән иде...

Бер көннән бөтен халык Такташны газета битләрендә кара рамкаларда күреп тетрәнде. Бик күп оешмаларның кара сызыкларга төренгән кайгы белдерүләре күңелләрне сыкратты...

...Инде соңгы чаралар... Күмү чаралары... Комиссияләр: җәмәгать комиссиясе, күмү эшләрен башкару комиссиясе, әдәби архивын барлау комиссиясе... Бу комиссияләр составында — Гомәр Гали, Кави Нәҗми, Әхмәт Исхак, Якуб Чанышев, Кәрим Тинчурин, Мирсәй Әмир, Абдулла Гомәр, Фатих Сәйфи-Казанлы, Закир Гали, Габит Такташ...

[1] Һади Такташ менингиттан үлгән, дигән фараз да яши.

**Шагыйрьнең
соңгы фотосы.
1931 ел**

Мәрхүмнең мәете Мәдәният йортының[2] ак залына урнаштырылды. Бик күп чәчәкләр, веноклар… Партия, хөкүмәт, әдәбият, сәнгать вәкилләре, эшчеләр, кызылармеецлар, пионерлар, туганнары, дуслары туктаусыз алмашынып почет каравылында басып торалар… Зур оркестрның матәм маршы яңгырый…

Сөекле шагыйре белән соңгы тапкыр саубуллашырга килгән халык агымы ике көн буе төнге 12гә кадәр өзлексез дәвам итте. Аларның саны 10 меңнән артты. Язучыларның күбесе гел шул залда, Такташ янында булдылар. <…>

Ирек мәйданында соңгы саубуллашу — кайгы митингысы үткәрелү билгеләнгән иде. Шуның өчен анда махсус трибуна төзеп куелган.

Табутны алып чыгу җиңел булмады. Бөтен Островский урамын халык дулкыны баскан. Бер-беренә сыланып, кысыла-кысыла шулкадәр тыгыз булып килеп тәрәлгәннәр ки, хәтта ишекне ачарлык та түгел. Юл бирүне сорап мөрәҗәгать итү-үтенүләр дә нәтиҗәсез калды. Атлы милиция чакыртылды. Аларга да бу эш җиңел булмады. Тәрәзәләрдән күзәтеп торабыз: берничә атлы милиция халыкны бик саклык белән генә, әкертен генә ерып килә, әмма ат алдында юл азрак ачылгандай була да шунда ук ябыла бара. Шулай шактый вакыт тырышкач, табутны алып чыгу өчен кечерәк мәйдан ачылды…

Табутны Такташның туганнары, дуслары, җитәкче оешмалар вәкилләре, язучылар, журналистлар, кызылармеецлар Островский урамыннан Ирек мәйданына кадәр чиратлашып күтәреп алып бардылар».

Әмирхан Еникигә сүз бирик: «Менә стеналары гарәп стилендәге нәкыш белән бизәлгән тар, озын гына зал. Уртасында озынча өстәл, өстәл тирәсендә кара каймалы кызыл табут. Табутта Такташ ята. Сап-сары йөз, очлаеп киткән борын, күзләре йомык. <…>

Шагыйрь белән хушлашу туктатылган, залда язучылар да Такташның якыннары гына калган иде. Почет каравылы да тора иде әле. Менә тагын каравылны алыштырдылар. Кемдер миңа да басарга кушты. (Язучылар барысы да үз нәүбәтләрен үткәргәннәр күрәсең инде.) Мин шагыйрьнең баш очына бастым, һәм безне бүтән алыштыручы булмады, шул сәбәпле шактый озак басып торырга туры килде. Соңгы әзерлек, соңгы минутлар!.. Мәетне фоторәсемгә төшерү башланды. Фотограф, ялгышмасам, газет-журналларда бик күптән эшләп килгән чүл гарәбедәй кара-көрән Солтан абзый *(Мөхәммәт Солтан — фотограф, журналист. — **Р.М.**)* иде. Башта ул табут янында шагыйрьнең иң якыннарын — хатынын, сеңелесе белән энесен төшерергә җыенды. Үзенчә аларны табутның бер ягына тезеп бастырды, ләкин төшереп алырга өлгермичә калды; нәкъ шул мизгелдә хәсрәттән бик бетеренгән Гөлчирә ханым, үксеп, Такташның күкрәгенә капланды, һәм бу хәл берничә мәртәбә кабатланды. Ә мин табутның икенче ягында гына басып торам — аз гына селкенергә, кыймылдарга да ярамый. Иреннәр тыелгысыз дерелди, яшьләрем менә-менә бәреп чыкмакчы, белмим, ничек кенә чыдап калганмындыр инде… Солтан абзый да шактый җәфаланды, шулай да ул үзенә кирәк мизгелне тотып, ахырда төшереп алды.

Бу эш беткәч, табут янына язучылар тезелде. Алар шактый ишле иде. Солтан абзый язучылар белән эшен тиз бетерде. Шуннан соң кешеләр таралды, без дә, ниһаять, каравыл постын калдырдык… Табут яныннан тик Гөлчирә ханым гына китмәде. Ул миңгерәүләнер дәрәҗәгә җиткән иде шикелле… Миңа, соңыннан күп җеназаларны күреп үткәргән кешегә, мәет өстендә Гөлчирә ханым кебек шул кадәр авыр газап кичергән икенче берәүне күрергә туры килмәде дисәм, һич тә хата булмас.

[2] Бу бинада (Островский урамы, 10) хәзер Казан Яшь тамашачылар театры урнашкан.

Һади Такташ табуты

Әйткәнемчә, бирегә мәрхүмнең замандашлары барысы да диярлек җыелган, тик алар арасында Кутуй гына юк иде. Табут янында да күренмәде ул. Хәер, килмичә каламы сон?! Кутуй үзенең Такташын озатырга килмәсен, имеш! Кем ышаныр моңа?!

Күмү комиссиясе членнары үзара күмү мәрасиме хакында киңәшләшкән чакта ишек төбеннән аның соңгы вакытларда «югалып» торган ачык тавышы ишетелде:

— Иптәшләр, рөхсәт итегез әле миңа да бер сүз әйтергә!

Түрдәгеләр барысы да бу көтмәгән тавышка борылып карадылар һәм кайберәүләр аптырап, кайберәүләр исә уңайсызланып, бер мәлгә ни әйтергә белмичә тынып калдылар. Ахырда комиссия членнарыннан берсе, ялгышмасам Закир Гали, артык гаҗәпләнүдән булса кирәк, суза төшеп:

— Ку-туй?! — дип куйды, аннары кинәт кызып: — Каян килеп кердең әле син, кем чакырды? Такташка синең бернинди дә мөнәсәбәтең юк, хәзер үк чыгып кит! — диде.

Кутуй тагын нидер әйтергә омтылып карады, ләкин аңа авыз ачарга да ирек бирмәделәр. Бу юлы инде берничә кеше, кайсы ачуланып, кайсы үтенгәндәй итеп, чыгып китәргә куштылар. Шуннан соң Кутуйның тавышы ишетелмәде, чыгып китте булса кирәк, хәер, мин артыма борылып карарга ничектер җөрьәт итә алмадым.

Инде хәзерге укучыларның исләре китеп: «Бу ни эш? Кутуйга ни булган? Сәбәп нәрсәдә соң?» — дип сораулары бик табигый. Кыска гына итеп әйткәндә, эш менә нәрсәдән гыйбарәт. Шул елларда әдәбият дөньясында шау-шу куптарган «җидегәнчеләр» дигән бер төркем язучылар «фаш ителде». Менә шуларның берсе һәм иң күренеклесе Гадел Кутуй икән. Әлбәттә, бу сенсация иде. Саф күңелле, намуслы Такташ мәрхүм кичәге дустының «юлдан язуына» чынлап ышанган булса

кирәк, «җидегәнчелек» фаш ителгәннән соң бер шагыйрьгә җавап итеп язган шигырендә[3] ул Кутуйга шактый ямьсез исем тагып уза.

Әйтергә кирәк, Һади Такташның җеназа мәрасиме моңарчы күз күрмәгән дәрәҗәдә зур матәм белән узды. Декабрь көне шактый салкын булуга карамастан, халык урамны бөтен иңе белән тутырып, язгы ташудай агылып барды. Бигрәк тә укучы яшьләр, студентлар күп иде. Такташ аларның иң сөекле шагыйре иде ул заманда.

Матәм митингысы Ирек мәйданында үткәрелде. Кемнәрнең нәрсә сөйләгәнен хәтерләү мөмкин түгел хәзер, тик гарнизон начальнигы Якуб Чанышевның гына бик ялкынлы нотык тотуы ничектер истә калган. Митингтан соң күмү мәрасиме Арча кырына таба юнәлде. *(Риза Ишморат истәлеге буенча, шагыйрьне соңгы юлга Салих Сәйдәшнең «Сакай маршы» озата. —* ***Р.М.****).*


Свидетельство о смерти № 4736 / 2678

Выдано в том, что Такташ Хади Хайруллович умер(-ла) в 1937 году 8 числа декабря месяца, о чем в книге записей актов гражданского состояния о смерти за 1937 год 8 числа декабря месяца произведена соответствующая запись.

Место смерти: Город Казань

Особые отметки: от сыпного тифа

М. П. Делопроизводитель



Шагыйрьнең үлеме турында таныклык

Такташка әзерләнгән кабер хәзерге Горький исемендәге ял паркы эчендәге зиратта иде — табутны иңнән төшермичә җәяүләп кенә шунда илттеләр. Анда да кемнәрдер нотык тотты. Ә кабер күмелеп беткәч, Якуб Чанышев китергән гарнизон солдатлары, берничә тапкыр мылтыктан атып, шагыйрьгә соңгы хөрмәт салюты бирделәр».

Рүзәл Мөхәммәтша *әзерләде.*

Әдәбият

1. Һади Такташ турында истәлекләр. Төзүчеләре Н.Юзиев, Н.Садыйкова. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980.

[3] Һади Такташның ул шигыре «С.Баттал иптәшнең ТАППка язган шигырь-хатына җавап» дип атала. Такташ анда Кутуйны сыйнфый дошман лагерена күчкән кеше санап, шактый каты кагылып уза.

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

НАРУЧАТ (НАРОВЧАТ) БӘКЛЕГЕ — XIII-XV гасырларда Алтын Урданың административ-территориаль өлкәсе, *Мукшы олысы* («Татар энциклопедия сүзлеге»ндә — *«Мукша олысы»*). Хәзерге Пенза өлкәсенең Кармалы авылы тирәләренә туры килә. Биредә Наручат (Наровчат) авылыннан ерак та түгел Мукшы шәһәре торган. Анда 1313-1367 елларда акча да сукканнар. Җир астыннан табылган акчаларны (һәм бизәнгечләрне) җирле халык «нурчатлар» дип атый. Тәңкәләр озынча формада булулары белән аерылып тора. 1360 елларда Мукшы олысын Тагай бәк басып ала һәм олыс яртылаш мөстәкыйльлеккә ирешә. 1367 елда аны Мамай гаскәре яулый. Тора-бара Наручат олысы таркалып, XV гасырда урыс дәүләте кулына төшә.

Наручат бәклеге халкы татар милләтен формалаштыруда катнашкан.

НӘБИЙЙУЛЬ-ӨММИЙИ *г.* — Өмми пәйгамбәр, ягъни укырга-язарга өйрәнмәгән пәйгамбәр. Мөхәммәд Пәйгамбәргә (с.г.с.) карата кулланылса да, хәзерге тикшеренүләр бу мәсьәләне кистереп хәл итми. Чөнки, мәсәлән, «Пәрдә» (7) сүрәсенең 157 нче һәм 159 нчы аятьләрендә әйтелгән *«Укый-яза белмәгән рәсүлебез — Мөхәммәд»*, *«Аллаһуга һәм укый-яза белмәгән Рәсүленә ышаныгыз!»* сүзләрен *«укый-яза белмәгәннәр Рәсүле»* дип тә тәрҗемә кылырга бик ярый. «Җомга» (62) сүрәсенең 2 нче аяте «Ногмани тәфсире»ндә түбәндәгечә бирелә: «Ул — Аллаһ укый-яза белми торган кавем эченнән үзләре кебек укый-яза белмәгән кешене — Мөхәммәдне дөньяның барча кешеләренә Рәсүл итеп җибәрде». Ләкин Мәүлана Мөхәммәд Гали тәрҗемәсендә бу урын *«наданнар арасында тәрбияләнгән Илче»* рәвешендә яңгырый. Аять Рабит Батулла тәрҗемәсендә дә шуңа охшаш мәгънәгә ия. Кыскасы, күп кенә галимнәр Коръәннең үзендә бу хакта аермачык мәгълүмат юк, дип исәпли. Өстәвенә, беренче вәхиләр назил булган вакытта хәреф танымаган Пәйгамбәрнең соңыннан язу-сызуга өйрәнүе дә мөмкин хәл ич.

НИКОЛАЙ МӘЙДАНЫ (НИКОЛАЕВСКАЯ ПЛОЩАДЬ) *тар.* — Иске Казандагы мәйдан исеме. Хәзер анда Бутлеров скверы урнашкан («Ленин бакчасы» дип тә йөртелде). XVIII гасырның сиксәненче елларына кадәр биредә тимерче алачыклары торган, алар уртадагы сазлык тирәсендә дүртпочмаклап тезелгән булган. Шуңа күрә «шакшы, баткак һәм сасы» бу төш

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

Тимерчелек мәйданы дип аталган. Тимерчелек мәйданын Балык базарыннан Нечаев тавы аерып торган, бу төштә *Рыбнорядский урамы* бик тараеп, тротуарга урын да калмаган. Язларын таудан агып төшкән былчырак урамны үтеп йөргесез иткәнгә, XIX гасырның кырыгынчы елларында Тимерчелек мәйданын тәртипкә китергәннәр, сазлыкны күмгәннәр (күрәсең, балчыкны Нечаев тавыннан алганнар), юлга таш түшәгәннәр һәм анда барлыкка килгән зур мәйданга *Николай мәйданы* исеме биргәннәр. Биредә крәстиәннәр утын саткан, җәен-көзен җиләк-җимеш сәүдәсе гөрләгән. Яңа ел алдыннан чыршылар сату оештырылган. Мәйданда такта балаган корылып, шәһәр хакимияте аны ил буйлап йөри торган төрле труппаларга арендага биргән. Балаган ярлылар өчен күңел ачу урыны булган.

XIX гасырның сиксәненче елларында Нечаев тавын җимерткәннәр һәм Рыбнорядская урамы Николай мәйданына кушылган.

1890 елда Бөтенроссия фәннисәнага күргәзмәсе вакытында мәйданда павильоннар корылган. Күргәзмә тәмамлангач, биредә шәһәр скверы ясалган, агачлар утыртылган һәм мәйдан уртасында фонтан эшли башлаган.

НИКРУТ — Урыс һәм поляк телләре аркылы алманчадан кергән сүз. Урысча формасы — *рекрут.* Мәгънәсе — армиягә яңа алынган яшь кеше *(новобранец)*. Россия армиясендә бу атама 1705-1874 елларда йөргән, ләкин никрут сүзе татарда XX гасырның беренче яртысында да еш очрый иде әле. Татар теле диалектында никерт сүзе дә сакланган. //*Никерт булыб йөриләр ийе урам буйда әрмийәгә китәр нимәләр.*

Фарсы телендә рекрут — *сэрбаз-э-җәдид.*

НОГЫТ КАРАУ — Керәшеннәрдә ногыт борчагы белән күрәзәлек итү. Максим Глухов, чыганакларга таянып, мондый күрәзәлек *«кузаклыларның элеп куелган җиңел әйберләрне үзенә тартуына (? — **А.Т.**) нигезләнгән»,* дип аңлата. Соңыннан ногыт борчакларын башка орлыклар, хәтта ипи йомшагы белән алмаштыра башлаганнар. //*Ногыт салу — Себер татарларында комалак салу, рәмел салу.* Күрәзәлек итү өчен шундый кырык бер ногыт (яки таш) алынган.

Ногыт борынгы урыс теленә *нохоть* рәвешендә кергән. Охшаш сүз чуаш, коми, мариларда да бар. Бу исә ногыт салуның бик күп халыкларда таралган булуын күрсәтә.

НОКРАТ — **1.** Болгар чорында сугылган көмеш акча. XVII-XVIII гасырларда татарларда 1 нократ 1/100 сумга яки 2 тәңкәгә тигез булган. 2. Болгар-татарда *Вятка* елгасының исеме *(Нократ Иделе)*. Марилар Вятканы Ноуград вич дип атыйлар, ягъни алар телендә гидроним Новгород шәһәре атамасыннан алынган. Язучы Нурихан Фәттах бу фикер белән килешми, *Нократ/Нукрат* атамасын җиңел генә *нук* һәм *рат* иҗекләренә тарката да, аларны борынгы Мисыр аллалары һәм патшалары исеме белән бәйләп куя. Моны без язучының уңышсыз этимологик тәҗрибәләре исәбенә кертәбез.

Нократ авылындагы (Киров өлкәсе) зиратта 1522 елда куелган кабер ташы бар. ■

һәр милли тел - шул халык күңеленең көзгесе ул. Телдә халыкның ерак гасырлардан килгән, формалашкан тәҗрибәсе, холкы-фигыле, дөньяга, кешегә, хезмәткә карашы гына түгел, аның мәхәббәт, гаилә, әхлакый сафлык хакында язылмаган кануннары чагылган. Милли телгә, милли мәдәнияткә хөрмәтнең кимүе халыкның гасырлардан килгән зәвык һәм әхлак традицияләренең бетәшүенә китерә башлады.

РАЯлашмагыз!

Әбрар Кәримуллин
(1925-2000)

Үз анасын яратмаган кеше башка аналарны да ярата алмый. Үз туган теленә хөрмәте аз булган кешенең башка телләргә дә хөрмәте зур булмый. Үз туган теленә хөрмәте булмаган кешенең үз ата-анасына, үз халкының әхлак нормаларына, халкының сәнгатенә, тарихына да хөрмәте булмый. Үз милли телен хөрмәт итмәгән кешедән мин интернационалист чыгуына да ышанмыйм. Милли нигилизм нигезендә вак, түбән хисләр, эгоизм, рухи, тарихи наданлык ята. Мондый кешеләргә үз шәхси мәнфәгатьләреннән тыш берни кирәк түгел — тел дә, гореф-гадәт тә…

Милли телләрне бары бер тел белән алыштыру тенденциясе дә әнә шул шәхес культы, торгынлык чорында бик нык пропагандалана башлады. Табигатьтә бер генә төр үләннең, бер генә төр җәнлекнең дә югалуы — кешелек өчен кайтарып булмас зур югалту. Теге яки бу телнең югалуына юл кую — гайре табигый хәл. Халыкларның, кешеләрнең киләчәге төрлелеккә бәйләнгән. Менә шуннан чыгып рус язучысы Василий Белов: *«Мин бер генә төрле аш ашый торган, бер генә телдә сөйләшә торган дөньяда тормас идем,тора да алмас идем»,* — ди.

Туган телгә игътибар һәр өлкәдә, һәр урында, һәр коллективта алып барылырга тиеш. «Туган телеңне ярат» дип, коры сүз белән генә аңа мәхәббәт тудырып булмый. Бу өлкәдә нәрсәләр эшләргә кирәклеге турында, моның өчен нинди юллар барлыгын мин тулысынча күз алдына да китерә алмыйм.

Туган телне — әткәм-әнкәм теле, ана теле, ди халык. Туган телгә мәхәббәт балада бишектән үк тәрбияләнә башларга тиеш. Улыгыз, кызыгызның туган тел-

не яратуы, яхшы белүе, аналар, сезнең өстегездә. Бу — туган телне өйрәнүдә, баланың теле ачылуда беренче этап, төп этап. Кызганыч, хәзер аналарның күбесе бала тәрбиясенә азрак вакыт бирә башлады, әби кешеләр дә бала карарга, аларга әкиятләр сөйләп телләрен ачарга ашыгып тормыйлар. Кече яшьтән үк сабыйны балалар бакчасына бирәләр, анда алар рус телендә генә тәрбия алалар.

Туган телгә хөрмәт тәрбияләүдә, аны яхшы белүдә милли мәктәпнең роле никадәр зур булуы турында сөйләп тә торасы юк. Ләкин менә ул милли мәктәпләр бездә нык кими башлады. Татар балаларына милли телне рус мәктәпләрендә факультатив итеп кенә укыту аның абруен бик төшерә. Милли мәктәпләрдә иң беренче чиратта милли тел төп тел булып укытылырга тиеш.

Туган телгә хөрмәт тәрбияләүдә вак нәрсәләр юк. Әйтик, төрле белдерүләрне татар телендә дә кертү, урамнардагы һәр элмә тактаны ике телдә язарга, татар телендә чыга торган газета-журналларны киоскларга күбрәк бирергә кирәк.

Миңа республикабызның тулысынча татарлардан торган авылларында бары тик рус телендә генә язылган элмә такталар, шигарьләрне, белдерүләрне күреп шаккатырга туры килгәне бар. Бу урындагы җитәкчеләр инициативасы белән генә эшләнә бит. Янәсе, менә күрәсезме, ул нинди интернационалист! Радиодан, телевидениедән, сәхнәдә татарча концерт бара икән, «интернационалистлар» аны гел рус телендә генә алып барырга тырышалар Яхшылап рус телен белмәгән авыл кешесен ТВ экранында «пупалам»лаштырып сөйләттерү дә телгә хөрмәт җитмәгәнен күрсәтә. Монысына инде журналистлар, телнең матурлыгы сагында торырга тиешле кешеләр гаепле.

Безнең телебез исемнәргә гаять бай. Үз исемеңә хөрмәт — шулай ук үз телеңә, үз мәдәниятенә хөрмәт дигән сүз. Ләкин безнең татар кызлары авылдан шәһәргә килеп җитмиләр, Рәисә, Равилә, Рәмзия, Раушания, Рамилә, Рәшидә, Рәхилә — барысы да «Рая»га әйләнәләр дә куялар. Менә шушы раялашкан, фаялашкан кызлардан үз балаларында туган телгә ихтирам тәрбияләүне көтү шиклерәк шул.

Телебезгә хөрмәтне үстерү өчен туган телебездә басма сүзнең киңрәк таралуы, радио, телевидениенең иртәдән кичкә хәтле нигездә туган телдә алып барылуы кирәк.

Туган телгә хөрмәт тәрбияләү өчен халыкның үз тарихын да яхшы белүе зарури. Тарихи аңсыз халыкның үткәненә хөрмәте була алмый, димәк, аның теленә дә. Ә халкыбызның тарихы тиешенчә өйрәнелмәгән, аның батыр уллары, зыялылары турында без бик аз беләбез. Халыкның бөеклеге — аның уллары, кызларының хезмәтендә.

Халкыбызның килеп чыгышы турында фәндә, әдәбиятта ялгыш теорияләр яшәп килә, кайчагында радио, телевидение, матбугатта, татарлар алар — монгол басып алучыларның калдыгы, дигән фикер ишетелгәли. Хәтта татар телен белүче татарлар арасында да, без — монголлар калдыгы, дигән караш яшәп килә. Ә рус һәм башка халыкларның абсолют күпчелеге безне нәкъ менә шулай саный да.

Чын-чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, диләр. Бик ныклап керешкәндә, туган телебезгә хөрмәтне үстерү, татар мәктәпләренең дәрәҗәсен күтәрү җәһәтеннән уңышларга ирешү мөмкин эш. Бу өлкәдә коры шигарьләр генә ярдәм итмәячәк. Телнең абруен күтәрү өчен, аның тормыштагы кулланылышына да киң юллар ачарга кирәк.

1987 ел

Татарстан радиосының «Тел күрке — сүз»
тапшыруына нигезләп, басмага
***Рөстәм Акъегет** әзерләде.* ■

КӨЗГЕ

(ТР Милли музее фондларыннан)

Беренче көзгеләрне Һиндстан, Мисыр осталары эшләгән. Аны ясаганда көмеш һәм бронза кулланылган. Көзгеләрне эшләү серен Венеция осталары 200 елдан артык беркемгә дә ачмаган.

Көзгеләр формалары һәм эшләнү материалы белән аерыла. Иң беренче эш итеп, көзгенең нигезе нинди булуына игътибар итәләр. Ул алюминий, көмеш, алтын, палладий, хром, никель булырга мөмкин. Иң яхшысы — көмеш нигезле көзге.

Татарстарн Республикасының Милли музеенда төрле көзгеләр саклана. Алар арасында Җүчи Олысында ясалган XIII-XIV гасырларга нисбәтле бронза көзгеләр бар. Шулай ук XVIII-XIX йөз интерьерлары арасында да көзге-тумбалар, көзге-шифоньерлар игътибарга лаек.

Гүзәлия Җәләлева *әзерләде.*

قوياش

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның гыйнвар ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Эшлекле юлдаш

Идарәбезгә шушы исемдә кесә календаре тапшырылды. Баширләре — Камил Бәширов вә Г.Гобәйдуллиннар. Бу «Юлдаш» иң башта бәйрәмнәр вә мәхкәмәсез көннәр белән башланып китеп, календарь кыйсеме, иң зарур справкалар, җәгърафи вә тарихи мәгълүмат, тыйбби ярдәмнәр, хатирә дәфтәре вә башкалар белән тәкмил [тәмам] ителгән. Әсәр матур гына басылган. Бәһасе 25 т.

Кояш. — 1916. — №885. — 1 янв.

Матбугат бәйрәме

Идел буенда әүвәл гәзитә чыккан көнгә инде ун ел тулып узган булса да, Казандагы матбугат даирәләренең үзара мөзакәрәләреннән [фикер алышуыннан] соң юбилей көнен мәүлид бәйрәме көнендә ясарга карар бирелгән иде. Шул карар буенча, Идел буе матбугаты үзенең унъеллык бәйрәмен бу көн итәдер.

Мөселман китапханәсе

Мөселман китапханәсенең юбилей мәрасимендә бирелгән хисапка караганда, мөселман китапханәсенең унъеллык дәвамында мондый хәлләр булып үткән. Һади әфәнде Максуди аерым китапханә ачуга мөсагадә ителүенә [мөмкинлек бирелүенә] күңеле өметсез калганлыктан, мөселманнар өчен шәһәр китапханәсе шөгъбәсе ачарга уйлап, 1904 нче елда шәһәр управасына гариза белән мөрәҗәгать иткән. Шәһәр думасы 1905 нче елның 8 нче февралендәге мәҗлесендә китапханә шөгъбәсе ачарга карар биреп, китапханәне башлап җибәрергә 590 сум, 1906 нчы ел мәсарифына [чыгымына] 1340 сум сәрмая [акча] билгеләгән. 1906 нче елның 2 нче гыйнварында китапханә рәсми сурәттә ачылган. Хәзерге көндә китапханә 3500дән артык җилд [том] китапка малик [ия] булып, 15кә кадәр газета вә журналлар даими алынып тормактадыр.

Кояш. — 1916. — №887. — 5 янв.

Умартачылык ширкәте

Ишетүебезгә күрә, Казан губернасы өчен умартачылык ширкәте тәэсис итү [оештыру] эше мәйданга чыгарга якынлашкан инде. Гайшә туташ Юнысова тәшәббесе [инициативасы] белән башланган ширкәт өчен устав төзелеп беткән инде. Якын арада мөәссәсәләр [оешмалар] тарафыннан имза куелып, тиешле җиренә тасдыйк итәргә [раслатырга] биреләчәк икән.

Кояш. — 1916. — №888. — 7 янв.

Көнләшкән

Яңа Бистәдә Малый Симбирский урамда 23 яшьлек Төхфәтуллина үзенең иренең урам уртасында 25 яшьлек Шәйхетдинова белән сөйләшеп торганын күргән дә, көнләшеп, йөгереп барып, Шәйхетдинованы бәреп егып кыйный

да башлаган. Ике хатын тырмашып-йолкышып сугыша башлаганнар вә бәйләнешкәннәр. Бу хәлдән хәбәр алган ике городовой килеп җитеп көчкә аера алганнар. Һәр икесе канга буялышып беткәнгә, иң элек һәр икесе больницага алынып кителеп тыйбби ярдәм бирдерелгәннәр. Аннан соң икесе дә полициягә протокол куярга илтелгәннәр.

Кояш. — 1916. — №895. — 15 янв.

Укучы балаларга ярдәм

Шәһәрнең һиммәтле байларыннан Садыйк хаҗи Галикәев һәр елда бер вакытта милли мәктәпләрдә укучы фәкыйрь балаларга күлмәклекләр өләштерә иде. Идарәбезгә хәбәр итүләренә күрә, Садыйк әфәнде бу ел да фәкыйрь балаларга шулай ярдәм иткән: Яңа бистәдә «Әмирхания» кызлар мәктәбендәге шәкертләрдән 143 кызга; мелла Кәшшәф Тәрҗемани мәхәлләсендәге мәктәп шәкертләреннән 92 кызга; Габделкаюм хәзрәт мәхәлләсендәге 51 кызга; Ләбибә ханым мәктәбендәге 136 кызга; Җиһан остазбикә мәктәбендәге 105 кызга; Сара мөгаллимә мәктәбендәге 25 кызга; Ак мәсҗед астындагы фокара [мохтаҗлар] мәктәбендәге 63 ир балага; Вәли Чукин вәкыфы тәрбиясендәге мәктәптәге 18 ир балага — барлыгы 579 кыз һәм 111 ир балага күлмәкләр сәдака иткән. Мондый кыйммәтчелек елда хаҗи әфәнденең фәкыйрь балаларга ярдәм итүе башкаларга да нәмүнә булырлык изге эштер.

Мөселман ханымнарының Думага мөрәҗәгате

Казан мөселман хатын-кызыннан 100 кадәр имза белән шәһәр управасына түбәндәге мәзмунда [эчтәлектә] гариза бирелгән: «Шәһәр идарәи мохтәриясе Иске вә Яңа бистәләрдәге халыкның сәламәтлеген саклау юлында барлыгы бер генә думский врач тота. Ул да Екатеринский урамдагы Симон амбулаториясендер. Бу бистәләр күк зур вә ун меңләп гаиләле бер кыйсемдә бер генә амбулаториянең кифаять итмәгәне [җитмәгәне] табигый. Без рус гласныйларына да, мөселман гласныйларга да бу хакта мөрәҗәгать иткәләп карасак та, тәэссефебезгә каршы, аларның берсе дә бу мәсьәләне әлегә кадәр күтәрмәде. Шунлыктан мөселман хатын-кызлары Думадан үтенәдер: 1) мөселман бистәләрендә яңадан бер думский врач урыны ачуын; 2) бу урынга хәзерге көндә Казанда эш күрмәктә булган врач Суфия Юныс кызы Агиеваны тәгаен итүегезне».

Гариза сахибәләре Суфия ханым Агиеваны ихтияр кылуларына түбәндәге сәбәпләрне күрсәтәләр: 1) рус врачына мөрәҗәгать иткәндә мөселман хатын-кызы максудларын аңлата алмыйлар, әмма Суфия ханым куелса, бу уңайсызлык бетәчәк; 2) искедән килгән горефкә бинаән [нигезләнеп], мөселман хатын-кызлары ир врачка мөрәҗәгать кылудан тартыналар; 3) Суфия ханым ике елдан бирле хезмәт иткәнгә күрә, мөселман хатын-кызларының мәмнүниятен җәлеп итеп өлгергән кеше.

Гариза сахибәләре, Суфия ханымның Пермь губернасы[1] Краснослободскка тәгаен кылынганын хәтергә төшереп, әгәр ул китсә, мөселман хатын-кызларының бердәнбер мөслимә врачтан мәхрүм булачак икәненә дикъкатьне җәлеп иткәннәр.

Кояш. — 1916. — №905. — 28 янв. ■

---

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Бирелә хата киткән булса кирәк, чөнки 1916 елдан Суфия Агиева **Пенза** губернасы Краснослободск өязе Юнә авылында үпкә авыруы белән чирләүче абыйсы Гафур Коләхмәтовны тәбияли.

Көлке куа килә...

ЧЕГӘН КЫЗЫ КОЛХОЗДА

Һади Такташ

Идел тын. Идел ярында, талларга басып, ана сандугачлар, сайрамый гына, Иделдән агып үткән салны карап торалар. Иделнең янында ук «Нәриман» колхозы утырган. Колхозның этләре, урамда чит кешеләр йөремәгәнгә, кемгә өрергә белми эчләре пошып, борыннары кычыткангa аптырап йөриләр. Колхозда эш кайнап торганда эшсез йөрүне килештермәгән кебек, ара-тирә танымаган булып, таныш кешеләргә дә өреп-өреп куйгалыйлар. Күңелсез бит, чын күңелдән өрмәгәч булмый булуын да, тик, юкта — үпкә дә тансык дигәндәй, кычыткан борынны басу өчен ярап куя ул.

Менә урамның әллә кай җирендә Сарыбайның чын күңелдән өрү тавышы ишетелде. Этләр, шатланып, яшь кенә, ялтыр күзле бер сәләмә чегән кызын урап алып талый башладылар. Очтагы йортларның берсеннән бер карчык чыгып, чегән кызын этләрдән аралады. Этләр карчыкның болай кеше эшенә килеп борын тыгуыннан бик недовольный булып, өрә-өрә читкә киттеләр. Чегән кызы, этләрдән арыну белән, карчык янына килеп туктады да, карчыкка карап:

— Давай погадаю, бир кулыңны, бәхетеңне әйтим, — дип кулын сузды.

Ул көнне колхозда эш бик иртә тукталды. Тирес ташып йөрүче атлар вакытсыз эштән туктауны аңламадылар. Алар:

— Әллә колхозда берәр бәйрәм-фәлән булдымы икән? — дип, гаҗәпләнеп калдылар. Колхоз урамында җанлылык башланды:

— Син караттыңмы әле?

— Караттым.

— Нәрсә диде?

— Каян белә, каһәр суккыры, прәме өстенә басып әйтә.

— Шулай шул, малай, минем дә исем китте.

— Әллә җеннәре әйтеп торамы икән үзенә?..

— Чынлап та җеннәре әйтеп тора торгандыр. Юкса, каян белсен…

Ул төнне төн буена колхозда чегән кызы турында сүз барды. Рәтле генә көн күрә башлаган колхозның общий йортында торучы кыска сакаллы агай төн буе йокламый чыкты.

— Хатын, чегән кызы ничек диде… Сиңа ерак сәфәр торамы, ди? Колхоздан чыгарырлар, ахры, моннан китәргә туры килер, ахры. Их, тамак икмәккә туя

башлаган иде… Инде бетте, күрәсең,— дип төн буе ыңгырашып чыкты.

Икенче көнне колхоз членнары эшкә бик ялкауланып кына чыктылар. Чегән кызы бик телчән булмаган күрәсең, барысына да:

— Сәфәр тора, сәфәр, — дигән. Күңелләргә шик салган. Борчу арттырган.

Чегән кызы колхоз председателе Шәмси Мөхетдиновның хатынына да зур бәхетләр вәгъдә иткән. Шуның өчен, иртә тору белән, аның кәефе дә гадәттәгедән әйбәтрәк иде. Самавыр куеп, иртәнге чәйне эчеп бетерим дигәндә генә, аңа ашыгып правление члены Миңнулла агай килеп керде. Ул керүе белән үк:

— Шәмси агай, теге урланган тәгәрмәчләрне чегән кызыннан каратырга онытканбыз, искә дә килмәде бит. Кем урлаганны әйтеп бирер иде, — диде. Шәмси агай аның сөйләп бетергәнен көтмәде.

— Бар тизрәк, атка утырып эзләп кайт үзен! Җир астыннан булса да табарга кирәк. Әйтер ул, белер ул, белми булмас, — диде.

Киттеләр, чегән кызын эзләргә киттеләр, колхозда калган членнары Идел ярына утырып чегән кызын көтә башладылар, араларыннан кемдер:

— Чегән кызы тапмаса, Арча кантонында бер багучы бар, ди, күзгесез карый да, ди, чистый әйтә дә бирә, ди. Шуны чакыртып килергә кирәк, сигез тәгәрмәч уен түгел ул, — диде.

Председатель дә сүзсез калмады, ул Шелангы ягыннан «Нәриман»га таба озаеп килгән юлга карап, үзенең зур сүзен әйтте:

— Ие, шулай итәрбез,— диде.

Правление члены чегән кызын очратмый кайтты. Чегән кызы булмагач, икенче көнне правление членын, багучы карчыкны эзләргә дип, Арча кантонына җибәрделәр. Ул аннан өч көн, өч төн үткәч кенә кире кайтты. Йөргән көннәре эшкә саналды. Юл расходлары түләнде. Ләкин тәгәрмәчләр табылмады.

Беркөнне генә әле мин «Нәриман» колхозы эзләгән чегән кызын Осланда очраттым.

— Погадаю! — ди.

Сорамыйча ук унбиш тиен акча суздым үзенә һәм:

— Чегән кызы, менә сиңа унбиш тиен акча, зинһар, ялганламыйча гына гомереңдә дөрес сүз әйт: кайчан да булса Теньки районы «Нәриман» колхозына Наркомпросның берәр инструкторы килгәне бармы, юкмы? Килмәсә, килерме? Килеп, наданлыкны бетерү мәктәбе ачып эшкә керешерме? — дип сорадым. Чегән кызы:

— Нәрсә? Кем ул? — диде.

Мин аның соравын әллә аңлап, әллә аңламый, «наркомпрос», — дидем.

Чегән кызы «Нәриман» колхозы членнары кебек наркомпрос сүзен беренче мәртәбә ишетте булырга кирәк:

— На просо (ягъни ярмага) не гадаю, — диде.

1929

Хәсән Туфан турында мәзәкләр

З.Хәйруллин шаржы

Хәсән Туфан

ОСТАЗ ЯНЫНДА

Хәсән Туфан каты авырып киткәч, хәл белешергә дип, Илдар Юзеев белән Рәдиф Гаташ хастаханәгә бара. Шагыйрьнең хәлсез, кәефсез кыяфәтен күреп, Илдар Юзеев сорый:

— Хәлләрең ничек, Хәсән абый? — ди.

— Бик әйбәттән түгел! — ди Туфан. — Әле яңа гына синең яңа поэмаңны укыдым. Анда ике урында ритм аксый, иҗекләр артык!

Рәдиф Гаташ авызыннан.
1985 ел, 18 декабрь

БАШМАКЛАР

Бервакыт Хәсән Туфан «Азат хатын» редакциясенә ике төрле башмак киеп килә.

— И-и, Хәсән абый, сезнең аякта сыңар башмаклар бит! — диләр кызлар.

Хәсән Туфан:

— Шәмси Хамматов янына керәсем бар, башмакларны алыштырып килим әле, — дип кайтып китә.

Бераз вакыт узгач, ул тагын редакциягә килеп җитә, аның аякларында тагын ике төрле башмак була. Хәсән абый алыштыруын алыштырган башмакларын, әмма кара урынына — ак, ак урынына карасын киеп килгән икән.

Кояш Тимбикова авызыннан.
1983 ел, 29 ноябрь

ЧЫН ШАГЫЙРЬ

Аккош күлендә яшәгәндә Хәсән Туфан бик канатланып, рухланып Казаннан кайта да Гомәр Бәширов янына керә:

— Гомәр, китап нәшрияты белән договор төзедем! Шигырь китабын чыгарачаклар! — ди.

— Ничә сумга? — дип сорый Гомәр Бәшир.

— Һай, кана, — ди Туфан. — Аны-сын сорарга оныткамын!

Гомәр Бәширов авызыннан.
1985 ел, 20 декабрь

***(Рабит Батулланың** «Тузга язмаган хәлләр» китабыннан.)*

Мирасворд

Азиядәге зур елга

Нурул-лин, Камский

X-XII йөзләрдәге төрки язмаларда мөһер, тамга

Васко … Гама

… карлы-гачы

Беренче татар газетасы

Күрәзәлек, юрау

Алтын Урда чоры шагыйре

Кенәз белән барон ара-сындагы титул

Алтын Урда шәһәре

Силла-бо-тоник шигырь үлчәме

Урта гасыр Шәрык илләрендә башлык, рухани урынбасары

Борынгы Мисыр-да жир Алласы

Рус мәсәлчесе

Көянтәле зур үлчәү (иск.)

Кабыктан ясалган түгәрәк савыт

Аваз, тавыш (иск.)

Француз матема-тигы

Җигелгән атны дирбияла-реннән арындыру

Самавыр төбе, челтәр астында кол җыела торган урын

XIII-XVI йөзләрдә Монгол империясе мәркәзе

Татар-стандагы шәһәр

Борынгы сугыш киеме

Әрмән таулыгы террито-риясендәге борынгы дәүләт

Дәүләт милке

Иван Тургенев повесте

Каплау, томалау

Дагы-станда яшәүче төрки халык

«Сания», «Эшче», «Алтын-чәч»

… Урда

Мәжит …

АКШның Кембридж каласында-гы мәшһүр университет

Очкыч

Әлки рай-онындагы авыл

Нота

Пермь краендагы татарлар күпләп яши тор-ган район

Борынгы Кытайда нәселдән нәселгә кү-чеп килгән титул

Язучы … Садриев

Үлексез шеш

«… Аллага» (Г.Тукай шигыре)

Элекке заманда җан башына тигән җир

Рәис Габдулла төзеде.

12 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: Ильяси, баб, фәза, нисаб, гуаһ, рә, Һади, «Сәйяр», им, Анда, башмак, әдрәс, Онат, Даши, Раев, ефәк, кип, Лев, тәпәч, ички, көшел, Тор, өке, ерак, кое.

Өстән аска: сандал, «Көз», ирән, көре, Сәйдәшев, кеш, фа, «Фидая», илтәбәр, әтәлге, Бәркә, ябага, аса, яса, әле, Ибраһимов, читек, һаман, чор, Кари, «КрАЗ», Җик, псн.

Мәскәү-Казан тимер юлын төзү. 1890 нчы еллар

«Безнең мирас»

елъязмасы /гыйнвар

● **695 ел элек (1321)**

Бөек төрки-татар шагыйре Сәиф Сараи (1321-1396) дөньяга килә.

● **145 ел элек (1871)**

Каюм Насыйри (1825-1902) тарафыннан татар телендә беренче басма календарь чыгарыла.

● **125 ел элек (1891)**

Мәскәү-Казан тимер юлы төзелә башлый.

● **95 ел элек (1921)**

Республика Хәрби Революцион Советы каршындагы Сәяси идарәнең Шәрык бүлеге Казанда «Кызыл дәфтәр» журналы чыгара башлый. Редакторы — Фәтхи Бурнаш. Авторлары: Фатих Әмирхан, Мөхәммәт Гали, Кәрим Әмири, Бари Рәхмәт, Садри Җәләл һ.б.

● **90 ел элек (1926)**

«Безнең юл» журналында Һади Такташның (1901-1931) «Нәни разбойник» шигыре басыла.

● **80 ел элек (1936)**

7 гыйнварда Башкорт дәүләт академия театрында Фәтхи Бурнашның (1898-1942) «Яшь йөрәкләр» пьесасы буенча эшләнгән спектакль премьерасы була.

● **70 ел элек (1946)**

Башкорт дәүләт опера һәм балет театрында Нәҗип Җиһановның (1911-1988) Муса Җәлил (1906-1944) либреттосы буенча «Алтынчәч» операсы куела.

● **50 ел элек (1966)**

Пермь өлкәсенең Барда районында татар әдәбияты атналыгы уза.

● **25 ел элек (1991)**

28 гыйнварда Галиәсгәр Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Гомәр Бәшировка 90 яшь тулуга багышланган юбилей кичәсе була. Әдипнең иҗаты турында Татарстан Министрлар Советы рәисенең беренче урынбасары Мансур Хәсәнов сөйли. Юбилярны Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев, язучы Гариф Ахунов, әдәбият галиме Фоат Галимуллин, якташлары, хезмәт коллективлары, җәмәгатьчелек вәкилләре тәбрикли. ■

Закир Батраев

Закир Солтан улы Батраев 1936 елның 11 октябрендә Үзбәкстанның Бохара шәһәрендә дөньяга килә. Казан сәнгать училищесын (1959), Ташкент театр-сәнгать институтын (1965) тәмамлый.

Закир Батраев — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның һәм Россиянең Рәссамнар берлекләре әгъзасы, профессор. Казанда яши.

Рәссамның әсәрләре Токио, Скота (АКШ), Харбин (Кытай), Ташкент, Сәмәрканд, Бохара, Улан-Удэ калаларының, Төркия, Израиль, Финляндия, Россия, Венгрия һәм Бөекбританиянең шәхси һәм дәүләти тупланмаларында саклана.

Казан университеты.
1977.
Киндер, майлы буяу

Капри утравында.
Италия. 2002.
Киндер, майлы буяу

12+

Тәртип 93.5 FM

ХАЛЫК РАДИОСЫ

халык радиосы - народное радио

реклама

Свидетельство о регистрации СМИ ЭЛ № ТУ 16-01049 от 20.05.2013

Тәртип FM: үз илемдә — үз көем!

«Халкыбызның җыр-моңнарына уралып, эфирга тәртип килде...»

93,5 FM ешлыгы тәүге авазын шулай ирештерде... Өлкән буын яшәешенең аерылгысыз өлеше булса да, хәзерге буынның күбесенә инде исемнәре бөтенләй ят легендар җырчыларыбыз Усман Әлмиев, Фәхри Насретдинов, Рәшит Ваһапов, Җәвәһирә Сәлаховаларның үлемсез җырлары, гармун, курай моңнары FM ешлыгында да матур яңгырый икән ләбаса! Шагыйрь-шагыйрәләребезнең күңел энҗеләре — шигъри тәлгәшләре дә Айрат Арсланов язмаларында, кабатланмас тавышлы Фоат Галимуллин, Наил Дунаев, Фәнис Җиһанша, Гөлчәчәк Хафизовалар укыганда йөрәкнең иң нечкә кылларын тибрәтә. Зыялы шәхесләребез алып баруында «Тузмый торган бүләк», «Тел дигән дәрья бар», «Безнең мирас» кебек тапшырулар халкыбызның бай мирасы, тарихы, гореф-гадәтләре, дине, мәдәнияте турында сөйли.

«Тәртип»не олысы да, кечесе дә тыңлый. Ул позитив радио буларак тәртипкә, яхшы эшләр, изге гамәлләр кылырга, кешеләрне хөрмәт итәргә чакыра.

Безнең Мирас

www.beznenmiras.ru

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132
РОССИЯДӘ – 70275

4 612750 670172

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, Г.Тукай музеендагы киосктан (Г.Тукай ур., 74) , «ТАТМЕДИА» АҖ бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан метросы киоскларыннан сатып алырга мөмкин.

№01 / 2016